
Ә
87

Роберт Әхмәтҗан

# ТАШ АРГАМАК





2
287

**Роберт Әхмәтҗан**

# Таш аргамак



*Шигырьләр, поэмалар, балладалар*

Т 1622660

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 5
Ә 87

**Әхмәтҗан Роберт**

Ә 87 Таш аргамак: Шигырьләр, поэмалар, балладалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 304 б.

Әлеге китапта авторның әле беренче тапкыр бергә тупланган поэмалары һәм балладалары урын алды.

Укучы биредә шулай ук шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында һәм төрле елларда язылган шигъри үрнәкләре белән дә таныша алыр.

ISBN 5-298-04067-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005

## *Мөхтәрәм укучым!*

Син әле ошбу китапның беренче битләрен ачканчы ук, игътибарыңа, автор буларак, кайбер аңлатмаларны җиткерүне кирәк дип саныйм.

Бер уйлаганда, шигърияткә бернинди дә аңлатма-шәрехләүләр кирәк түгел кебек. Чөнки хисси иҗат ул йөрәктән йөрәккә юллана (моннан килеп инде «йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә» дигән канатлы тәгъбир килеп туа). Шулай да...

«Яшьлек поезды» һәм «Тынлык ни сөйли?» дип исемләнгән бүлекләрдә иҗатымның башлангыч чорында яшьлек хыяллары тудырган әсәрләр (әсәрләнүләр!), укучыга аз мәгълүм яисә бөтенләй мәгълүм булмаган шигырьләр урын алды. Алар минем студент елларында ук дөнья күргән тәүге китапчыгым «Егерменче яз»дан (1958) һәм соңрак чыккан яшьлек еллары җыентыклары — «Гасырлар юлы»нан (1960) һәм «Синең кояшың»нан (1962) алынды.

Төрле өслүбтәге шигырьләр, чор-заман фрагментлары, яшьлекнең ихлас тойгылары.

Ә менә поэмалар һәм балладаларның вакыйгалары, инде тарихка әйләнеп, егерменче гасыр офыгына китте. Әмма тарих кабатлана, диләр борынгылар. Бәлки... Ничек кенә булмасын, әлеге әсәрләр минем өчен үзләре иҗат тарихы инде, — аларны минем гомердән аерып булмый, шактый гомерем шуларга багышланган. Миңа алар шул яктан да кыйммәтле.

Минем буын кешеләре, утыз бишенче елгылар, үзгә бер иҗтимагый-социаль сферада — «җиңеп килүче социализм»

мохитендә яшәп иҗат иттеләр. Ирексездән Такташның «Сез бу хатны минем укыганда...» дип башланган шигъри юллары хәтергә киләләр! Бу чорны инде, ул нинди генә булмасын, гомерләрдән кисеп ату мөмкин түгел.

Шул нисбәттән поэмалар арасында «Соңгы гыйнвар» дигәне бүгенге яшь укучыга сәер дә тоелырга мөмкин. Чөнки мин аны безнең чорда «гасырлар кешесе» дип җырланган Ленинга, аның Горкадагы соңгы кышын тасвирлауга багышлаган идем. Моның өчен мин, «Казан утлары»ннан Зәки ага Нури фатихасы белән шунда барып, Көньяк вә Төньяк флигельләрдә япа-ялгыз йөреп, хәтта Ильичның соңгы ятагына ятып карап, Кышкы залдагы юлбашчы коляскасына җәелгән леопард тиресен сыйпап карап, кыскасы, заманның бер фанатигы рәвешле ихлас поэма иҗат иткән идем. Вакытында ул бик җылы кабул ителде, радиода шул поэма буенча гаять уңышлы радиокомпозиция язылды. Аны вакыт-вакыт бүген дә тыңлап куям: заманында бөек Такташның да, хәтта «кабак җырчысы» дип аталган мәшһүр Есениннең да бу темага язган әсәрләре мәгълүм...

«Гасырлар һәм минутлар», «Капитан Земли» һ.б. Әлеге шагыйрьләр бүген исән булсалар, бу әсәрләрен сызып атарлар иде микән, анысын белмим, миңа исә, темасыннан да бигрәк, әсәрнең язылышы, сурәтләү алымнары, художество кыйммәте, һәм, ниһаять, үземнең шул көннәр рухы кадерле. Шунысын да искәртик: андый шәхесләр тарихтан, хәтердән сызылып атыла алмыйлар. Тарих өчен борынгы Римның тираны саналган Нероны да исән, Наполеонның һәм башка күпләрнең дә тарихта үз урыннары бар ич!

СССР таркалып, союздаш республикалар аерым мөстәкыйль дәүләтләргә әверелгәч, чикләр бүленде, һәркем үз капкасын саклый, үз йортына гына хуҗа булып яши башлады, тимер-корыч ишекләр хәттин ашты. «Аерым хуҗалар»га әйләндек! Ә безнең чорда кыйтгаларны, чикләрне белү юк иде, уртак иҗади киңлектә хәл-әхвәлләр белешеп яши идек. Әйтик, 1945 елның 9 августында Япон иленең Хиро-

сима, Нагасаки шәһәрләренә атом бомбасы ташланган икән, ул инде татар шагыйрьләре өчен дә төзәлмәс яра булып кабул ителде.

Минем «Таш елады» балладасы әнә шул фаҗигагә багышланды. Әйтик, Америка агрессорлары Вьетнамның Сонгми авылын тоташ яндырып көл иткән икән, бу безнең йөрәкләрдә дә резонанс тудырмый калмады. Минем «Сонгми» дигән поэмам шуның бер мисалы.

«Йолдызстан» поэмасы кешенең галәмгә тәүге очышы турында иң беренче, бәлки... соңгы поэма буларак та әһәмиятле, дияр идем. Бу да — тарих.

«Уйна, улым!», «Таш аргамак» поэмаларының нигезендә мәңгелек тема — сугыш һәм тынычлык, мәхәббәт һәм әхлак, буыннар бәхәсе проблемасы ята. Әйтергә кирәк, Бөек Ватан сугышының тәгәлләнүенә дә 60 ел! Поэма да шул датага килеп чыга...

«Сәхипҗамал» поэмасын Татар театрының тууына 100 ел тулуга бер шигъри бүләгем булыр дип уйлыйм. Татар театры сәхнәсенең тәүге таң йолдызы мәшһүр Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, аның иҗат офыкларына очышы хакында ул поэма.

«Болгар фрагментлары», «Атлантида» поэмалары татар халкының тарихтагы урынын күзаллауга омтылу рухында иҗат ителгән фараз-поэмалар.


Калганнары, укучым, синең хөкемгә.

*Роберт Әхмәтҗан*
*26 июль, 2003*

* * *

Бу китапның ачтым күпме битен!..
Ничә бит бар тагын — әйтү читен.
Тик әлегә ачкан битләрендә
Ал таң иде офык читләрендә.
Ара-тирә, сөт парлары булып,
Офыклардан карап куйды болыт.
Җылы җилләр исте талгын гына...
Тибрәлдерде җылы агым гына...
Кинәт кенә, җуеп тынычлыкны,
Бер битендә аның сугыш чыкты!
Бер битендә... әйтмим, бигрәк авыр...
Ә шул бите мәңге истә калыр...
Калын булмасын ул, булсын юка,
Буш битләре аның янсын утка.
Юка булсын, миндә тик бер теләк:
Түземсезлек белән көтсен йөрәк
Бит артында нинди бит торганын,
Нинди юллар алда яктырганын...
Ул булмасын, кинәт ачу килеп,
Ялыктырып япкан китап кебек...
Гомерең булсын, кызык җиренә килеп,
Көтмәгәндә беткән әкият кебек.
Түшәгеңнән торып соң кат җилкен:
«Укыйм әле, — диеп, — соңгы битен!..»

# Яшьлек поезды



## *Балачактан килгән шигырь*

Һавада болытлар кабарды
Һәм исте кыйбладан дымсу җил.
Беренче тамчылар төшүен
Көттеләр уҗымнар, бөтен җир...

И бәхет! Шыбырдап, түбәгә
Беренче тамчылар төштеләр.
Күк суын, ширбәткә тиң күреп,
Үләннәр көлешеп эчтеләр!..

*1943*

* * *

Таң кабынды.
Зәңгәр күл табагын
Җилләр инде өреп суыткан.
Посып кына болыт-мендәренә,
Торып килә кояш офыктан...

... Иксез-чиксез яшел киңлекләрнең
Куенында эреп югалдым.
Чиге булмас борма сукмаклардан
Кояшыма карап юл алдым.

*1956*

* * *

Иртә әле,
хатфә үләннәр дә
өлгермәгән чыгын коярга.
Уянганнар
эшчән бал кортлары,
чәчәкләрдән
ширбәт җыярга.

Кош сайрады мактап аяз таңны,
яфракларны нурлар үптеләр:
иркәләнеп,
уйнап тын һавада
күбәләкләр
очып үттеләр.

Карап тордым, газиз туган җирнең
Һәр бизәге өчен куанып.
Ал чәчәккә кунган
Бал кортына
сердәшемдәй
әйттем уйланып:
«Нечкәбилкәй,
эшең бик күп синең,
хезмәтең зур,
үзең кечкенә.
Син чәчәксез,
ә мин туган илсез
яши алмас идек
һич кенә!..»

*1957*

## *Яңгырдан соң*

*(Этюд)*

Юл читендә боек карамага
Салкынча җил китте кагылып.
Теткәләнеп, таулар аръягына
Ак болытлар үтә агылып:

Яшен белән төнен дәһшәт салган
Дивизия гүя кырылган,
Ташлап бөтен яңгыр запасларын,
Кача сыман сугыш кырыннан!..

*1956*

* * *

Йөгереп килдең миңа яз булып,
Кулларыңда чәчәк бәйләме;
Үзең гүя яшьлек бәйрәме.
Җанлы чәчәк, җанлы тадж булып,
Йөгереп килдең миңа яз булып.

Чәчәкләрең, сеңелем, ярыйсы,
Килә йомшак, язгы кар исе...
Онытып бер бөтен дөньясын,
Күзләреңә килә карыйсы, —
Чәчәкләрең, сеңелем, ярыйсы.

Чыгар булса вәгъдәң ялганга,
Сибел, чәчәк, сибел, алданма.
Җилләр иссә, син, дип ымсынып,
Умырзая карар аланга,
Вәгъдәләрең чыкса ялганга...

*1958*

## *Күршем нигезе*

Күрше карчык, моржаң төтенләми,
Алсуланып кояш батканда.
Хат язарга диеп чакырмадың,
Авылыма бу юл кайтканда.

Әле кайчан, яулык читең кабып,
Төбәп миңа яшьле күзләрең,
«Балакайлар, нигә язмыйсыз?!» дип
Тезә идең сагыну сүзләрең...

Яздым, сыздым, күңел хакың өчен, —
Нәрсә әйтсәң, шуны үтәдем...
Бүген исә салкын нигезеңә
Моңсуланып карап үтәмен...

Улларың соң нигә кайтмадылар,
Оялары ник соң оныткан?..
Юлларында уйный тузан гына,
Болыт кына калка офыктан...

Мәрхүм ана, хәзер тынычлангач,
Улларыңны мөмкин көтәргә:
Кайтыр алар ятим калган йортны
Өч читеннән
          өчәү
                    сүтәргә!..

Өч улыңны искә төшердем дә
Хәтерләдем иске зарыңны...
Йөзең итеп
          туфрак үбәр алар, —
Белмәделәр элек хәлеңне...
...Шаулый җилләр,
          җилләр үксетәләр
Нигезеңә үскән әремне!..

*1957*

* * *

Бормаланган урман юлын үткәч,
Колач җәйде яшел болыннар…
Шатлыгымнан әгәр яшем тамса,
Кичерерсез, таныш урыннар.

Искә алып наян балачакны,
Яр читенә килеп туктадым.
Тау битенә шәфәкъ нуры кунып,
Алсулаткан көтү сукмагын.

Су читендә үскән бөдрә таллар,
Тугаеның җикән, камышы,
Ак ташларга бәрелеп, бормаланып
Агып яткан инеш тавышы —

Бар да таныш, якын күңелемә,
Туган җирнең сизәм җылысын.
Чишмәләре тибә йөрәк булып,
Талгын җилләр
гүя сулышы…

*1958*



## *Кар яктысы*

Уйнаклады таңда салкын карлар,
Ак карларда зәңгәр эзләр бар.
«Уф!» дип куя җилләр, ерак китеп, —
Ак карларны эретер сүзләр бар.

Сүзләр йөри синең эзләр буйлап —
Салкын кышлар килде микәнни?
Якты. Салкын. Әллә син түгелме,
Кар яктысы көлде микәнни?..

Бер нәрсәнең сизәм җитмәгәнен, —
Йөзең кайда салкын аллаган?..
Йокысыз төн, елмаюларың бар,
Истәлегем — сиңа ялганган.

Уйлар чәчәк аткан төннәрем бар,
Карга уелып калган эзләрем.
Кар яктысы кебек елмаюың,
Әллә әрнү,
әллә бәхетеңнән
Тоныкланган зәңгәр күзләрең...
Ни әйтсәң дә, һаман сиңа тарта,
Сиңа тарта
зәңгәр эзләрем!

*1958*

## *Язга таба*

Март бураннары ишелде,
Ишелде генә күктән...
Шатлана гүя күк йөзе,
Арынып авыр йөктән.

Сизәр чак житте йөрәкнең
Йөрәккә кушылганын.
Тоясың «котлы булсын!» дип,
Бөреләр пышылдавын.

Шаулы яз, якты мәхәббәт,
Илһамлы кайнар таңнар!..
Туачак бәхетне уйлап,
Жылынып китә жаннар!

Кәрниздә елтыр сөңгеләр
Запаста торган сыман.
Тыныч өйләр дә йөзләрен
Кояшка борган сыман!..

*1957*



## *Яшьлек поезды*

Без кузгалдык изге теләк белән, —
Сугышларсыз юлдан үтәргә.
Вокзалына җидееллыкларның
Кичекмичә килеп җитәргә.

Кочегарың, мичкә күмер ташлап,
Кызу йөртте авыр көрәген.
Ә шагыйрең, кайнар топка итеп,
Җырларына якты
йөрәген!

Каникулда, өйгә кайтмый гына,
Студентлар китте далага.
Зачетлардан шулай турыдан-туры
Имтиханга дәште
Замана...

Яшел вагоннарда чакрымнарны
Җырлап уздык
дөнья җимереп!..
«Кайт, улым!» дип язган ана хаты
Проходнойда ятты
тилмереп.

«Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен.
Өйләнсәң дә, көйләнсәң дә, ахры,
Бер маржага каптың, күрәсең!..»

Ә иртәсен «соңгы хәбәр» төсле
Син чапкансың күрше-тирәгә;
Шат тавыштан таңны уяткансың:
«Минем малай...
чирәм җир-ләр-дә!..»

*1958*



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН



T622660

## *Бер хатирә*

### I

...Салкын җилләр салкын сулый,
салкын утлар селкенә.
Ә ул атлый янәшәмдә,
күбәләктәй җилкенә.
Толымнарына кагылып,
шатлыгыннан җил көлә!..

Дәшми генә шул кызыйның
узып киттек торагын.
(Алып бирер идем аңа
айның көмеш урагын!)

Әйтерсең лә шул төндә мин
планетаны урадым!..

### II

...Дуслар гөрли, менә, илем,
Яңа елга керәсең.
Баер инде яңа җырга
студент хатирәсе...

Ягез, дуслар, пыялалар
мөлдерәп, ташып тора.
Башланмаган яңа бәхет
йөрәкне дәшеп тора!

Киләчәккә яңа юлдан
Яңа ел ашыктыра...

Тышта ап-ак күбәләкләр,
ак бәхетләр җилпенә.
Салкын җилләр салкын сулый,
Салкын утлар селкенә!

*1958*

## *Бер хаттан*

«Күзләр җитте... Нигә хатларың юк? —
Алтынланды башы каенның...
Күзгә каен кебек алтын башым —
Бер билгесе синсез аемның!

Тормышта шул һаман аерылулар.
Каршыласаң бергә иртәне,
Таңда тагын, борма юллар буйлап,
Тибрәлдерә тормыш җилкәне...

Мендәремнән ай да торып китте,
Чулпан чыкты таңын сагынып...
Тышта — давыл,
Тышта — яфрак туза,
Офык яна, ал таң кабынып!..»

*1958*



## *Бодай кыры*

Бу башаклар ни серләшә икән, —
Җир-әнкәйгә рәхмәт, диләрме?
Күңелең кебек ярсу бодай кыры,
Җил шаулата Синең көйләрне!..

Авылым кызы, китәм еракларга, —
Басуларның дәшә бүтәне...
Элеккедәй, озатып, яулык болгап,
Бодай арасыннан
үт әле!

Бодайларың кемне сәламлиләр,
Башакларын сузып югары? —
Миллион куллар гүя
күтәрелгән,
Теләп тук һәм имин илларны!..

*1959*



## *Соңгы карлар*

*(Эскизлар)*

Иртән генә әле сулар чапты,
Эрегән кояш төсле ермаклар,
Сыртларында зәңгәр боз күтәреп,
Таш юллардан чапты уйнаклап...

Ә кичкырын тынып калды сулар,
Телсез калды сайрар кошларым.
Тәрәзәдән инде күреп тордык
Берәм-сәрәм карлар очканын...

Соңгы карлар!
Кышның соңгы сүзе
Ак мамыклар булып тирбәлә.
Болытларны куган җил артыннан
Ап-ак, ап-ак сәлам җибәрә...

Кар суларын куган кояш кебек,
Елмаюга, синең назыңа
Мин күнеккән идем, киртә булып
Каршы төште буран — Языңа...

Төшсен карлар — күкрәр җылы яңгыр,
Кояшның бар чынлап көләсе...
Ә синең бу соңгы карың микән,
Их, беләсе иде, беләсе!..

*1959*

## *Төнбоеклар, тынлык чәчәкләре*

Төнбоеклар, тынлык чәчәкләре,
Йомшак сезгә күлнең күкрәге.
Җылы яңгыр сезне үбә генә
Һәм тибрәтә күкләр күкрәве!

Ерак иде бездән, ерак иде
Сугыш уты өткән иңкүләр.
Сез таңнарга күлеп ачылганда,
Болгандылар ерак тын күлләр...

Мин үзем дә үстем сезнең якта,
Йөгерә-йөгерә йөрдем йомышка.
Кораб иде әле ул чак миңа
Гөрләвектә йөзгән йомычка.

Ерак иде бездән, ерак иде
Сугыш уты өткән иңкүләр.
Сез кояшка күлеп ачылганда,
Болгандылар анда тын күлләр.

Ул таңнарда әткәй аткан туплар
Безнең тынлык өчен күкрәде...
Төнбоеклар,
                    тынлык чәчәкләре,
Йомшак сезгә күлнең күкрәге!..

*1959*



## *Кояшка, кояшка!*

Яз әле ташына,
Яз әле тынгысыз,
Яз әле бетмәгән урнашып.
Тегендә шартлыйлар бөреләр,
Ә монда —
дулкыннар чабыша җырлашып!
Яшел куллардай сузыла яфраклар:
«Кояшка,
кояшка,
кояшка!..»
Торналар быргысы тетрәтә һаваны:
«Язларын — юл башка,
юл башка,
юл башка!..»
Көньякны калдырып,
бу якны сагынып,
Моңлана торналар кәрваны.
(Алар да хөрмәтли беләдер
юл салып иң алда барганны.)
Яз әле ташына,
Мәңгелек яңару,
Мәңгелек юлларда
Яшьлек һәм шаяру!
Кояш чын гашыйк елгага:
омтыла,
Түшәктәй бозларны кузгатып.
Җир кетә кемнедер...
Сөюдән яшәреп,
Әйтерсең туй көтә
кыз-хатын.
Әнә анда, үзәннәр,
чоңгыллар куенында
Сырпалана, тулгана җылы җил...

Мәңгелек юллардан
гомерлек кунагын,
Хыянәтсез язларын
каршылый
Туган Җир!..

*1959*

## *Юат әле*

Каспий артларыннан чыгып,
Кичә генә сулышын өрде болыт, —
Кабарынды дулкыннар...
Сусаган жырын кемнеңдер
Бөтерделәр упкыннар.

Суы белән күбекләнеп ташкан,
Томанланып болытларга ашкан
Киңлекләргә карадым.
Тойдым: ерак, йомшак кулың белән
Болытларны тарадың!

Юат әле сукбай дулкыннарны,
Кагылмасыннар килеп.
Җырың булып нәни йөрәгемә
Сарылмасыннар килеп!

*Әстерхан, 1959*

## *Яз — мәңгелек!*

Күкрәр үлән, гөлләр күзен ачар
Сагынып кайткан язгы көйләрдән.
Буаларын ишеп качкан судай,
Каршы чабар өзелеп сөйгәннәр.

Каршы чабар язлар кочагына,
Яшьлек яшел туен үткәрер;
Якты җырын ак болытка турылап,
Ил авазын тургай күтәрер...

Тагын бөреләр! Бөреләр — котылгысыз,
Тыелгысыз сулар агарлар.
Язда туган һәр ерганак юлын
Олы юлга карап чамалар!

Олы юлга карап, бары алга, —
Юлларда юк артка каерылу.
Язгы сулар куа бер төбәккә, —
Мөмкин түгел безгә аерылу.

Аңлаганга дөнья нинди киң ул,
Яз мәңгелек туй ул лабаса!
Таш өстенә тамган тамчы өчен
Ике чыпчык юкка талаша!

*Әстерхан — Җәмәле, 1959*



## *Бер очрашу*

Ак каштаннар чатырланып үскән якта,
Көньяк күгенә гашыйк булып йөргән чакта,
Аксыл чәчен иңнәрендә иркәләтеп,
Керфекләрен юнәлткән дә бер китапка,
Кыз утыра. Карамый да үткәннәргә.

Ак муенына ара-тирә чәчкә ташлап,
Теләгәнчә тик җил генә иркәләнә.
Китап битенә иркәләнеп өреп китә,
Бәхетеннән диңгез ягына көлеп китә!

Беләсе иде: ниләр укый ул кыз бала,
Бер карашын үткәннәрдән ник кызгана?
Тәвәккәллим, сискәнмәче, әй, кыз бала, —
Фикерләрем эндәшергә җиң сызгана.

Кыз елмайды «Бу синмени?» дигән төсле,
Ә карашы шундый йомшак, шундый көчле!
«Шигырь укыйм. Әйбәт шагыйрь! Гаҗәп шунсы:
Каян алып язган икән минем хисне?!

Шигырь укыйм — коеп яңгыр яуган төсле,
Күкрәүләре ишетелә бик якында...»
Сорадым мин: «Кем шигыре, ниләр яза?»
Күкрәк тутырып көрсенде кыз:
«Яз... хакында...»

Шагыйрь дустым, син түгелме? Нәрсә күрәм!
Кыз кулында очраштым ла исемең белән.
Нихәл итим. Әмәлем юк... Ул — синеке!
Ул кыз, күрсә, сиңа көлеп дәшәр иде...

Көньяк күген иркәләгән күзләрендә
Барын күрдем: хисләреңнән әсир иде!

Хисләреңнән әсир иде ул кыз бала, —
Дус шатлыгын күпсенүдән түгел, түгел, —
Өсләреннән җил йөгергән күл шикелле,
Нәни генә тибрәп китте минем күңел!

Искәрдем мин җирдә көчле шагыйрь барын,
Искәрдем мин аңа гашыйк матур барын.
Мин дә хистән тукый алсам яз гөлләрен,
Тезәр идем матурларын-матурларын!..

Бер теләгем дөрли минем рәхмәт әйтеп
Исемеңә, хисләреңә — барчасына.
Яз сыйдырган шул матурның яшь йөрәген
Салыр идем тәнкыйтьчеләр каршысына!

*Әстерхан – Казан, 1960–1961*

* * *

Бодайларны сөткә туендырып,
Яңгыр килде яшел кырлардан.
Кырлар көткән җылы яңгыр сыман,
Хатың килде
ерак юллардан.

Хатың килде! Озак көткән, җылы,
Куанычлы, күңелең сугарган!..
Сөткә туйган бодай кырларыдай
Күкрәп куйды җаным
шуңарга...

*1959*

* * *

Зәңгәр киңлек — зәңгәр юллар гына,
Акчарлаклар куна маякка.
Ак дулкыннар ярга йөгереп килә,
Ак эт булып сыена аякка.

Күрәсең, ул сыенып ярдәм сорый,
Давыллардан ал, ди, аралап!
Йомшак эзли — бәрелә яр ташына,
Һәм чигенә, сыртын яралап.

Безнең күңел нәкъ шул дулкын инде:
Сыена назга, сыена йомшакка.
Ак дулкындай сүрелеп үксеп китә,
Таш күңелгә бәрелеп шул чакта.

*1960*

* * *

Идел ага, ишетелми, ага тып-тын,
Ә бит юкса төпләрендә кайный упкын...
Турбиннарга киловаттлап салынып куәт
Тирәнлеккә яшереп ага кайнар холкын...

Карыйм да мин киң Иделгә кайчагында
Һәм уйланам: кайда моның сагыш-моңы?
Идел ага, ишетелми тавыш-тыны,
Гөрләвекләр көлешәләр таң ягында!..

*1960*

## *Ак юлларым**

*(Җыр)*

Ап-ак итеп кар яумаса,
Юлларга бурамаса,
Кайтмас идем, ул якларны
Яшьлегем урамаса.

Кайтмас идем ямансулап,
Зәңгәр үрләргә карап.
Әй, ул ашкынган җилләрнең
Шатлыгы бер дә харап!..

Күктән синең карашыңдай
Ягымлылык сирпелде.
Карлар синең көлмәгеңнең
Ак борчагы шикелле.

Ак бәхетләр сибелә кебек,
Сибелә кебек мул булып.
Ак юлларым ак бәхеткә —
Сиңа илткән юл булып.

Сызылып бара, сузылып бара,
Яңа үрләргә карап.
Әй, ул ашкынган җилләрнең
Шатлыгы бер дә харап!..

*1960*

---

* Г.Сәйфуллин көе.

## *Бүгенге көн*

«Бүген» дибез... Аның чиге кайда?
Кайда аны бүлгән киртәләр?
Артка китсәк, — анда кичәге көн,
алга китсәк, — анда Иртәгә!..

Үткәннәрдә бит ул шул ук туфрак,
сулары шул, ләкин болганган;
туган туфрак. Тыныч күкрәүләргә
үләненә чаклы куанган!

Үләненә чаклы — шатлык яше,
якты күзләр чыклы сагыштан!..
Җылы төндә яфрак тибрәнгән төн
«Син — минеке!» дигән тавыштан.

«Син — минеке!» дигән күлләр ята,
бәрелештән соң сусап чөмергән.
«Син — минеке, Тормыш!» диеп, ул чак
араланды Әҗәл
Гомердән...

Без «иртәгә» дибез, нурын сибеп,
төн артында көтеп торганны...
Шушы юлым бара түгелме соң,
кичсәм дә мин кара урманны?

Шул ук юлым карурманнар аша
алга илтә тормыш йөгемне...
Карурмандай еллар кичә-кичә,
киләчәккә бара
Бүгенге!..

*1960*

## *Улларың кайта...*

Теплоходлар кайта дулкын ярып,
Гудоклары җитә болытка.
Ак күлмәген кигән туган калам
Таңнан карый алсу офыкка.

Офыклардан кайта эшелоннар,
Үр менәләр сагыну хакына.
Түзалмыйча,
Юлым яртысыннан
Үрелеп карыйм Казан артына.

Разъездлардан,
Дулкын өсләреннән
Шул якларга юлларым кайта.
Туган җирнең бәхиллеге өчен,
Татарстан,
Улларың кайта...
Төшләремдә хәтта дуслар кулын
Эзли торган кулларым кайта!..

*Әстерхан—Казан, 1960*

## *Син килгән юллар*

Син килгән юлларда — яз бүген,
Күгәрчен юынып кагынган;
Кояшны аз гына шәүләләп,
Иң якты болытлар агылган...

Синең як, синең җыр! Үзеңдәй
Назлана кыргый кыр гөлләре;
Яз керсә, исемеңне сагынып
Мөлдери мәхәббәт күлләре!..

Тургайлар шатланган һавада
Безнең дә шатлыкка урын бар.
Яз керсә, син килгән эзләргә
Яшәреп гөл чигә болыннар.

Син килгән юлларда — яз бүген,
Күгәрчен канаты кагылган...
Яз булып син килгән юлларда
Иң якты җырым бит табылган!..

*1961*



* * *

Тетрәп сүнде учак, җил каршында
Кул күтәрде! Киртә корып та
Гомерен аның йолып калалмадым,
Соңгы тыны ашты болытка.

Туган иде соңгы шырпыдан ул, —
Күзен генә кысты бер мәлгә...
Тойгыларым! Бер минутлык учак!
Язмышыгыз сезнең бер мәллә?

Шигырьләрем! Әллә әзерме сез,
Көн каршында соң кат талпынып,
Калдырырга нәни йөрәгемдә
Туңган планеталар салкынын?..

*1962*

## *Судагы боҗралар*

Идел язы булып үттең син дә,
Зәңгәр күзләр генә балкып калды...
Яр буенда комда эзләр калды,
Ә аларны дулкын юа, юа...

Ә мин ташлар җыям сабый төсле.
(Синең сабыең!)
Су өстенә таңгәл китереп
Очыртам да... Синең эзләр булып
Су-көзгедә кала боҗралар, —
Пунктирлар сызам,
меридианнар...

Тик ул эзләр өзеләләр ярты юлда, —
Өч-дүрт сикерә дә

Идел ташы
суга чума,
Тарала бөҗралар...
Күңелем дулкыннарын
Бөтен киңлекләрдә
тараталар Сиңа —
Сагыну меридианнары!..

*1965*

## *Көлә кызлар!*

Бакчаларда,
Идел буйларында,
сәхнәләрдә яки...
мунчада
көлә кызлар
дөнья яңгыратып,
Кояшка һәм Язга
кул чаба!..

Көлә кызлар —
язгы аваз белән,
бармактан да көлә,
ярыктан...
Дөнья яралганнан бирле гүя
елмаюга алар зарыккан!..

Көлә кызлар...

Тешсез авызын ачып,
чатта басып тора бер әби:
— Нигә көлә алар,
пычак кергән,
әйтерсең лә булган
әллә ни?!

*1966*

## *Инеш*

Ага инеш яшел яр эчендә.
Ике яклап, ерак диңгезгәчә,
озата бара аны яшеллек.
Анда ага таллар, болытлар...

Төнлә,
йолдызларны кочагына алгач,
диңгез куенында
инеш
төш күргәндәй, имеш:
ул һаман да агып ята
туган якта килеш...

Аның нәни буласы,
яшел болынга кайтасы,
күзге булып, күбәләкләрне
чагылдырасы килә!
Печәнчеләр аңа,
нәни булса да,
исеме белән дәшә иделәр!
Диңгезгә ул исемен калдырып керә!

Барыннан да бигрәк
хәтерли ул шуны:
аның күзгесенә иелеп,
болан кызы сыман бер сылу
битен юган иде.
Янып торган битен!
Ә суыннан
килә иде җир җиләге исе —
ул онытмый шуны!
Хәзер
йолдызларны кочагына алып куана ул.

Чөнки
болын өстендә дә шул йолдызлар иде!

Болын уртасыннан инеш ага:
бер очында — диңгез,
бер очында — чишмәләр...
Төннәрен
диңгез куенында
туган ягым җыры ишетелә!..

*1966*

## *Җир китабы*

— Җир китабы буламыни, әти,
анда язган нәрсә хакында?..
— Җир китабы — кызык...
Ярый, улым,
бик телисең икән, йә, тыңла.

Җир ул сиңа — кәгазь китап түгел,
Басу-кырлар — аның битләре.
Җир фәне ул бөтен фәнгә нигез,
киләчәге, аның үткәне
ачык безгә.
Аны китап итеп актаралар
язын сабаннар.
Орлык сикерә кара туфракка!
Бу — яшәүнең башы,
менә шуңа
җир китабы
яздан ачыла.
Иген шыта, иген — яшел нурлар,
җир нурлары

кара туфрактан
күтәреләә яшәү тавышын алып,
кояш җыры яңгырый
кыяктан.
Җилләр исә хәтфә сукмакларда,
ефәк тасма кебек кыякларны
бер үреп тә тагын бер сүтеп.
Әлли-бәлли килә яшел башак
һәм үсә ул имеп
җир сөтен!

Җир китабын укый күкрәүләр.
Күтәрелә тургай кырлар өстенә.
Җир китабын аны, җиң сызганып,
кешеләр яза,
яңгырлар һәм җилләр эчендә.
Орлык белән кара җиргә кергән
өмет шыта монда, зур үсә...
Яшьлек үсә күкрәп буразнада,
буразнада
безнең җыр үсә!

Иң беренче безгә җир китабы
галәмнәргә чаклы юл сызган.
Гаҗәпләнмә, төшенерсең үскәч,
буразнада үсә
йолдызлар!..
Җир китабы, олы мирас булып,
буыннардан күчә буынга.
Тикмәгәме буразналар төшкән
игенченең каты кулына?
Җир китабы ята ачык килеш.
Язучы да, укучы да аны —
игенче.

Тынгы бирми аңа язгы җилдә
басулардан килгән җир исе!
Төшенәсең килсә җир фәненә,
татып кара, әйдә, җир тәмен:
менә сиңа орлык, учыңа сал,
үзең өйрән әле җир фәнен.
Туфракка күм орлык.
Аннан яшел нурдай үрләсен ул,
кыяк чыгарып.
Сакла аны, үстер бураздада
күз нурларың белән сугарып!..

Җир китабын укый бүген тургай,
җир китабын сабан актара...
Язгы юлдан
нәни игенчегә
мин багышлап язган
хат бара!

*1966*

## *Ерактагы дуска*

Бу минутта төрле киңлектә без —
Кабул итәм синнән Кояшны.
Әле ярый Син яшисең җирдә...
Син яшисең.
Моны көн раслый.

Бүген безгә ни ул киңлекләрең,
Давыллы кыр,
Дөм-дөм урманың, —

Безнең белән
бер үк күк астында
Бик сизелә
синең торганың!..

Бар дулкында күңелем — тота сине,
Тоя күңелем,
борчый дәшмәвең...
Бу дөньяның хет кай ноктасында
Бик кирәкле синең
яшәвең!..

*1966*

* * *

Тупыллар килә Иделгә,
карарга дип суга бер!..
Җәй өлгерде! Тирәкләрнең
ашыгуы шуңадыр...

Гомергә суда үз йөзен
күзгедән карамаган
каеннар килә Иделгә,
кайталар карамалар!..

Үскәннәр ерак якларда,
Иделемне ишетеп бары...
Килегез, ком гарәбедәй,
саксаул кунакларым!
Кабул итә Иделем җәе
якынын, еракларын...

*1967*

## *Кызыл чаган*

Керде көз, кызарды чаган
жил-давыллар кочагында.
Шул чагандай дөрләп янам,
янам тормыш учагында!
Байрактай тора рухым,
тора комач чаган кебек.
Җитәмме тормыш артыннан,
үзем юкса чабам кебек.
Кызыктырмый, сикереп узам,
туктаталмый ваклыклар да.
Тик башкаем, шул чагандай,
иелә кайсы вакытларда.
Ул — иелгән байрак түгел,
җилфердәргә тик
җил көтә...
Чаганны — җил,
мине — яшьлек,
балкып туар
Көн җилкетә!..

*1969*

## *Романс*

Кич,
шәүләләр озынайгач,
нәни шигем,
баганадай, юлга ята...

Икеләнү — упкын тора
йөрәгемнең яртысында...
Килер юлың — тып-тын гына
ак каеннар яктысында...

Бүгенге кич безнең өчен
мәңгелектән безгә килгән.
Сагынуларым ташкынына
көймә булып кер син, иркәм.

Йолдыз булып төш син аңа
йә йөзеп йөр яфрак булып.
Давылларымын — җилем тимәс,
Яратырмын саграк булып...

Ак каеннар яктысында
килер юлың тып-тын гына.
Әй, сөекле сының тора
икеләнү упкынында!

*1970*

## *Яңа елга кергәндә*

Игътибар!
Башлардан салыгыз, —
башлана елның
яңа сериясе!

Һәркем елмаеп:
— Яңача башлыйбыз, — диде, —
Яңача.
Башыннан!

Калдырабыз искене — бусагада!
(Әле ярый —
башлануның башлануы бар;
юкса яңаны кайдан башлар идек,
юкса искене кайда ташлар идек
тик күңелдән генә булса да!..)

...Дөньякүләм маскарадтан соң,
салып ташлап иске җиләнен,
иске ел көлә:
— Мин исән!
Мин — сезнең белән.
Сезнең белән, әй чордашлар,
яшәрәм генә мин!..

Яшәрмисезмени сез үзегез
бер минутка гына булса да,
сәгать телләре
бар галәм алдында
уникедә үбешкәндә?
Чор чатында еллар күрешкәндә?!

Бара минем теләкләр дә
сезнең белән алгы көннәргә:
офыкларга тоташып,

чуен каскалар түгел,
тук бодайлар чайкалуын телим.
Ут
үлем сүзен пышылдамасын гөлләргә!
Кырларны шифалы күкрәүләр кабартсын,
болыннарны иңләсен тыныч чалгы!

Һава, күкләр —
шатлык ягы булсын!
Йөрәкләрне чат саен
сагаламасын кайгы!
Корыч шөпшә
кошлар юлын кисмәсен,
бары төклетура
җырлап очсын болын аркылы!
Йолдыз далаларына түргә үтсен
кешеләрнең
игелекле акылы!

Галәмдә түгел, җир-бишектә дә
хыялларның азмы чынга ашасы?!
Кешеләр — кеше булсын!

Бүреләрнең
юашлануын теләмим.
Алар белән чөнки киләчәктә дә
бар әле очрашасы!..

...Циферблатның олы угы
акрын гына
хөкем тарта
иске елга...
Хуш, узган ел!
Җир суы белән тутырып касәләрне
күтәрәбез —
йолдызларга!

*1972*

# ***Кышкы җил***

*(Сонет)*

Кышкы җил дә — шул ук офыклардан,
язгы кояш килгән яклардан.
Кайгым да бит минем синең яктан —
сине көткән ап-ак чатлардан.

Кышкы җил дә шул ук офыклардан —
җылы июнь үткән киңлектән.
Ак карлардай шулай уйнап, күктән
ак хәбәрләр килсен мин көткән.

Кышкы җил дә шул ук офыклардан —
Язларыңа карап син үткән...
Барып җиткәнсеңдер син күптән
Хыял төсле алсу болытларга.
Сине уйлаган моңсу минутларда
гел яз икән җанда нилектән?

*1974*



## *Күңел кыры*

Кайтып китәсе иде ак кырларга,
күкрәк куеп җилле чакрымнарга,
мартның кояшлы кырларына,
басып челтәрле карларына...

Ишетәсе иде килгән кошның
кыймый гына аваз биргәнен,
һәм төшкәнен соңгы кары кышның
әрем сабагыннан тирбәлеп;

күтәп алсын иде яшьлек язың
үр артында калган таңнарда, —
бар гөлләре белән яшел газон
калыккандай кинәт январьда!..

Кайтып китәсе иде ак кырларга,
күзләр белән зәңгәр җил эчеп;
сөюеңне меңгә тапкырларга
шушы дөнья, шушы җир өчен!

Ишетәсе иде яшьлек дусың
март кырыдай балкып көлгәнен.
Һәм төшкәнен соңгы кары кышның
әрем сабагыннан тирбәлеп!

*1968*



## *Диңгез буенда кыз җырлый*

...Тауларга болыт бәрелде, —
Айкалып китте сулар.
Үзгәрде диңгез. Күңелем
Чайпалып китте шуңар...

Үзгәрде диңгез, яшәрде,
Суы зәңгәрдән зәңгәр!
Җитен чәчәге шикелле,
Аннан да зәңгәр...

Әгәр
Учыңа алып карасаң,
Күгәреп китә сыман —
Су булып су да үзгәрә,
Аерсаң
олы судан!..

Мин — Иделнең бер тамчысы,
Диңгезгә карап торам:
Сабырлыкка өйрәт, Диңгез,
Йә... шашып
яратырга!

Мин киләм Синең каршыңа
Бөтен барлыгым белән.
Җирдә минем сагынуга тиң
Сөю барлыгын беләм...

...Диңгез җиле каштаннарның
Чәчләрен тарап тора...
Сабырлыкка өйрәт, Диңгез,
Йә шашып
яратырга!..

*1968*

## *Вундеркинд*

Кеше
гомере буе аласыны
алды да урып-йолкып
бер мизгелдә,
башкаларга инде Парнасыннан
карап ята
әверелеп иң изгегә!..

Исе китми, көнләшми дә
аннан беркем.
Чөнки бөек! Дөнья — иркен!
Үз җырларын үзе тыңлап
туйды бугай —
җиргә төшәргә уйлады
беркөн!

Альбиносны ят иткәндәй,
җирдә
танымады аны… төркем.

Үзенә язган мәдхиясен үзе укып,
биеклеккә менеп китте…
ашты гарешкә!..
Кайгыданмы, әллә шатлыктанмы,
пышылдап калдылар җирдә:
«Фәрештә,
фәрештә,
фәрештә!..»

*1968*

## *Очышка!*

Бар, оч, туган,
син — һава кешесе,
егылма, тотын!
Күккә карап күгәрде күзләр!
Син моны яуладың,
яндырып
сабырлык утын!

Очу — ул бер көнлек, диделәр,
көлделәр
мәңгелек атына
ябышкан агайлар!
Ике кулыңны җәеп
сикердең ярдан, —
төшләреңдә йолдызга
сикерде малайлар!

Очтылар малайлар — хыялда,
төшләрдә.
Ә өндә — әйләнеп
кайттылар галәмнән!
Очу ул — бер көнлек,
купшылар темасы —
шул сүзләр түгелде
скептик каләмнән.

Очыш мәйданында,
күкләргә ыргылып,
ничә мегатонна куәт тора ярсып...
Ычкындыр тезгенен! —
безнең азат гамәл
яңа галәмнәргә
сәлам алып барсын!

Оч, туган, туйганчы,
йолдызлар артына, —
бу хакны яуладың
гасырлар буе!
Оч, әйдә, гали зат,
Икарлар онығы,
кояшлар утына
җиткәнче буең!
Оч, әйдә, сөюдә,
оч, әйдә, җырларда,
өметле язмышта,
бәхетле минутта,
иң якты сәгатьтә,
иң гүзәл сәнгатьтә,
табынып максатка —
иң изге бер утка!

*1968*

## *Июнь иле*

### I

Баш очында — кояш,
җирдә — Июнь иле.
Яфрак арасында
яшелләнә җиле.

Шау чәчәктә юкә,
алкалары — сары.
«Очам!» диеп тора
тузганаклар шары.

Ул су өсте! Тып-тын,
шома көзге генә.
Шуып-шуып үтә
су чебене генә.

Су дөньясы тонык —
күренә чабаклары,
арлы-бирле үтә
кызылканатлары...

Кояш елмаюы —
яшел яр читендә,
балкып тора елга
яшел рам эчендә!

Мин үзем дә шуннан,
Июнь иле ямьле...
Гашыйк балачагым
шунда калды мәңге.

## II

Инде еллар йөге
ике иңне баса...
Мин «А-у!» диеп дәшәм
утыз июнь аша.

«А-у!» дип җавап бирә
усак урманнары,
«А-у!» дип җавап бирә
февраль бураннары.

Флейта көе кебек,
сызып-сызылып кына,
тавыш кайткан сыман,
аннан сүнеп тына.

Урман сәгатьләре
уникене суга.
Гаҗәпләнә бугай
нәни малай шуңа.

Күке тавышларын
бармак бөгеп саный...
Аңа адашса ни...
Минем адаш —
сабый!..

### III

Мин, кайт, диям аңа,
монда иркен, рәхәт!
Кайт син бу елларга
йөгереп кенә җәһәт.

Сугыш
— күптән үлде!
(Син үзең дә белдең:
капка төбәсенә
кызыл яулык элдең!)

Кибетләрдә йөртәм
(ялган сөйләмәмен),
сайла да ал үзең
җаның теләгәнен!

Таяк атың ташла,
уенчыклар — дөнья!
Ул чакта, үч итеп,
бер туйганчы уйна-ау-у!

«А-у!» дип җавап бирә
болын, зәңгәр таулар...
Бер-беренә суза
ал кояшны таңнар...

Бил тиңентен үлән,
күбәләкләр хоры.
Табигатьнең гүя
кияү көткән чоры...

Шау үләннәр кочып,
җәеп ике кулын,
гашыйк күзләр белән
ята
урман
угылы...

Июнь җиле исә,
үләннәрне тарап...
Ята бала чагым,
кошлар юлына карап.

Гаҗәпләнгән күккә,
алмый гүя тын да...
Чакырма да —
кайтмас.
Ул бәхетле —
шунда!

*1971*

## *Камыллар*

*(Вариацияләр)*

### I

Камыллар эчендә рәхәт, тын.
«Сау бул!» диеп баеп барган кояшка,
шәһәр өсләреннән кыйгачлап,
кичке кошлар кайта югартын.
Күк төтеннәр алсулана еракта,
камылларга төшә кичке моң.

### II

Җәен генә тук бодайлар булып
 чыңлый идек без кырларда,
ай-урагын алып килде дә көз —
әверелдек камылларга...
Сыгылсак та — ил кырында,
 бил бирмәдек давылларга.
Без өлгердек бары! Башны салдык
ил өстәле — табыннарга.
Икмәк анасы идек җирдә, —
 басып калдык тамырларда.
Без курайлар инде сары җилгә,
яңгыр-явымнарга...

### III

Күк төтеннәр ягыннан киләм,
шырт камыллар гына бар тирәм.
Тау артында калды туган өй...
Күк төтеннәр ягыннан киләм.

Күңелемдә — яңа туган көй.

*1971*

* * *

Күренмәгән бер кешем бар бу җирдә:
йә ерак ул миңа, йә якын...
Йә кайта ул утлар сүнгәч,
таң җиле шаулаткач усак яфрагын,
тәрәзәгә чиртә... үзе керми,
дәшми-тынмый болыннарга китә...
Ромашкалар арасында йөри,
маймычлы тонык инешкә
коя яр туфрагын.

Китә кереп башы белән яшь арышка.
Күзем ачам:
ә болында —
үлән шавы,
су шавы,
энә караклары камышта...
чабак исе!..

Әрәмәгә керәм аны эзләп,
күләгәсе төшкән инеш суына:
сөяк саплы ак пәкесе белән
мыштым гына
таллар юна...

Төшкә керә: әллә үпкәләгән —
(учына кыскан яшел алмасын)
башын иеп миңа кырын карый.
«Аңларсың,
аңларсың!..»
Дәшче, кешем, миннән нәрсә кирәк?
Бармы бирәчәгем? Алачагың?..

Төн эченнән эзлим аны.
Ерак калган кырлар өстеннән,

нәкъ Җидегәнгә тияр-тимәс,
үтеп китә йолдыз булып...

— Балачагым,
ба-ла-ча-гым!..

*1971*

* * *

Яшел тауга яттым — җир кешесе, —
җитте зимагурлык итүләр!
Биредә — Җәй, җәйчә тормыш яме,
яшел тауда йөри көтүләр...

Ишелеп-ишелеп җирдә үлән шаулый,
җиләк исе килә җилләрдән!
Ачкан гүя дөнья изүләрен,
җиләннәрен җилпеп җибәргән!..

Көтүченең чыбыркысы монда
демагогның төче сүзеннән
реальрәк яңгырый! —
таудан тауга
яңгырап кайта
чыклы эз белән...

Шәһәрләрен ташлап чигендем мин,
чигенмәдем ләкин — җырларда!..
...Баш очымда гына
яшь чикерткә
сыза икән
нинди кылларга?!

Итәгендә аунап яшел тауның
ятам менә
үткән елларда!..

*1972*

## *Зарыктырган яңгыр*

**1**

Исте дә җил, тибрәлде кыр —
туган якның ашлыклары;
какты йөрәккә дулкынлап
арышы, ясмыклары...

Чыкты кыйбладан кабарып
күк болыт ястыклары, —
чәчелде китте җиргә,
и, көмеш тәсбихләре!

Яшьнәп-көлеп йөри күктә
җиһанның чал яшьлекләре!..
Ә без, каләм, шул авазга
тәрәзә ачтык бары!

**2**

Тышта — күкләр зилзиләсе,
яфраклар — пыран-заран!
Баш куйган салкын өлгегә
йодрыктай кызыл яран...
Ява! — күкләрнең рәхмәте,
сүзләре — кәлимәсе...
Шушыдыр Күкләрнең Җиргә
иләһи Поэмасы!..

*1972*

## *Җайдагатлар*

*(«Кичү» циклына)*

Идел-йортның инешләрен ерып,
үзән аша
яшел тауга менә җайдагатлар...
Кылычларын суырып кынысыннан,
тын беткәнче, үбә яшь җайдаклар:
«Туфрак булыйм! —
кочмас Илне җиде ятлар!
А, рух!..»
Тоякларда кайный яшел үлән!
Алда — сулар, алда — кызыл ярлар...
Янып калды җилдә яшь учаклар, —
очкыннары туза — кызыл карлар!
Алып китә алар заман җырын,
Үткән шатлыкларны, сагышларны...
Очып бара җилдә җайдагатлар,
офыкларда — кешнәү тавышлары!..
Яшел ялкын ургый тояклардан,
аякларда зеңли өзәңгеләр!..
Мәңгелекнең бөек суын кичеп,
яшел таудан
                    ак болытка таба
җайдагатлар менә —
узган еллар!..

*1972*



## *Таулар җилли...*

Таулар җилли Кояш асларында,
күккә ашып, күренеп дөньяга.
Коела ком, чатный ташлар гына,
үзәннәргә тулып җил ага.

Җилли таулар, таулар чаларалар,
нурлар туфанында яктырып.
Оча кошлар, күчә заманалар,
таулар кала алга чакырып...

*1973*

## *Юл көндәлегеннән*

Күбәләкләр Днепрга оча,
пыялада җырлый көзге җил:
— Украина!..
Зәңгәр тупылларың!
Йөрәк каны сеңгән изге җир!

Мин үзем дә китеп барам кебек
гарасатлы ерак елларга...

Уйчан гына авышып бара август
кавын исе килгән кырлардан!..

*1974*

## *Сылу суръте*

Иреннәрең — кызыл яфрак,
күтәдер үз җилен!
— Мин бит — Күз инде...
Мин килдем!

Кызыл яфрак тора калтырап:
— Өзсәң өз инде...
Аһ, өзелде!

*1970*

* * *

Ничә чакрым куанычны үттем!
Ун чакрым — җил.
Тик нәрсә ул
ун чакрым җилең! —
ун чакрым җыр,
ун чакрым шатлык аша килдем!

Син — янәшә идең.

*1987*



## *Сигулда усаклары*

Һәрбер ташның монда тарихы бар,
чишмәләрнең — туган еллары.
Нәни җырын Даугавага илтә Кекаваның*
тонык сулары.
Шундый тонык: өстән яфрак йөзсә,
төптән бара аның шәүләсе!..
Юл буена шулай биетеп бара
наратларның зифа гәүдәсен.
Урманнарны урап, ташлар аша
дайна** җырлап ага гөлләргә...
Сигулданың кызыл усаклары
лепердәшеп яна җилләрдә!

Зәңгәр күзле,
саргылт чәчле кыздай
күз сыенды безнең кочакка.
Истәлеккә, күзге учак булып,
өстәлендә янды усаклар!
Аларның мин шунда бер минутка
усак икәнлеген онытып,
яңгырларың күшектергән кулны
усак ялкынында җылыттым...
Дөрләделәр синең усакларың...
дөрләделәр синең усакларың,
пешердәй булып — сузылсаң...
Кичер мине,
тик узышлый гына
синең яшьлегеңдә җылынсам.
Кичер мине.

*1965*

---

* Кекава — Латвиядәге инеш.
** Дайна — латышларның күмәк уен җыры.

## *Ерак бер көзне сагыну*

Өй түремдә алма коела таңда,
дөп-дөп коела чыклы үләнгә!
Мин тагын да синең көзгә кайтам,
сине сагынып кайтам — үткәнгә.

Кайтам синең якты күлләреңә —
йөзә иде кызыл балыклар!..
Латгалия, урман әкиятеңә
син яңадан мине алып бар!

Син яңадан көзге аланнардан
алма җыеп ап-ак итәккә,
Җыр илеңә — якты офыкларга,
болытларга чаклы җитәклә!

Кайтам синең кызгылт көзләреңә.
Хәтерлимсең, безнең ул чакта
кызыл урманнардан Сөю җыры
кергән иде атылып кочакка?!
Шул чаклардан, соңгы мәҗүсидәй,
табынам мин Кызыл Усакка!..

Монда да көз... Алма коела шаулап,
дөп-дөп коела сары үләнгә...
Бу минутта синең елларыңнан
бик еракта инде бу бәндәң!

Еллар аша синең истәлеккә,
җырда янган шушы минутта,
иелә дә
өстәлемә сибелә,
Латгалия,
көзен чәчәк аткан
шомыртлар!..

*1973*

## *Юрмала* җиле*

*Я. Озолиньга*

Февраль наратлары шаулый җилдә,
озын булып сузылып, ап-ак карда
күләгәләр бии! Еракларлан
мин тагын да килдем синең ярга!

Урманында — кояш коридоры,
алып китә безне тагын ерак —
диңгез наратларын урап-урап!
Һәр нараты безгә карый туры!

Янәшәдә дюннар — сары комнар...
Акчарлаклар оча ымсынып,
тик узган җәй бозда калган тынып —
үз сурәтен саклый дулкыннар...

Якында — яз, дустым, яз якында! —
Кояшлы җил шаулый шул хакта...
Диңгез песнәкләре инде хәтта
сөйләшәләр бугай яз хакында.

Нарат башларында: «Цвейке**! Цвейке!» —
Сөйләшәләр кошлар чын латышча,
сөйләшәләр төньяк-көнбатышча.
Миңа шулай тоеладыр, бәлки?!

«Цвейке! Цвейке!» — бу бит синең телдә!
«Сәлам!» диләр язгы ялкыннарга,
туганнарга, ерак якыннарга,
килгәннәргә сәлам безнең илгә!

---

* Юрмала (*латыш.*) — диңгез буе.
** Цвейке (*латыш.*) — рәхмәт.

Сәлам сиңа, җил һәм кояш иле!
Цвейке! Цвейке! — дуслык җилләренә!
Мин йөрмәсәм җырлы илләреңдә,
юрас перле*,
шушы җырым әле тумас иде,
рәхмәт инде!

*1973*

* * *

Мәхәббәт һәм гүзәл җир турында
син җырладың Кояш култыгында.
Мин кушылдым җырга — ике, пар җыр,
акчарлактай, киңлек офыгына
очып китте бездән! Күк диңгездә
ике сулыш калды икебездән:

күк астына китте ике аваз —
диңгезләргә гүя ике гаувас**!

Акчарлактай киттең син күзләргә...
Калдың, җырым,
салкын диңгезләрдә!

*1974*



* Юрас перле (*латыш.*) — диңгез энҗесе.
** Гаувас — водолаз.

## *Тормыш арбасы*

Айларда, әллә кайларда
йөри заман арбасы!
Бу — чик түгел, яңа ярга
яңа юллар ярасы...

Яңгырап барсын чор түренә
кешенең хөр авазы.
Аңа бит, җирне үзгәртеп,
барасы да барасы!

Әле ярый кешегә җирдә
Кеше булып каласы!
...Шыгырдап, сайрап,
дыңгырдап
бара
Тормыш
арбасы...

*1974*



## *Хаттан өзек*

Они бы вилами пришли...

*С. Есенин*

...Мин авылда. Мөхәррирләр ерак, —
Илтәм дисәм яңа шигырьне.
Шунысы да бар: тәнкыйтьче дә ерак.
Янда — әни. (Ул да тидерми!)

Монда июль бара! Яшел мәхшәр!
Этләр өрә, тавык кытаклый.
Шампан кебек кайный монда хисләр,
түгелергә тора, юл тапмый!..

Иҗат хакына, әйе, үз ягымнан
чакырам мин бөтен рухларны.
Дәшәм аннан Шигырь дәрьясына
үз көймәсе белән — Нухларны!..

Самовары инде кайнап тора,
без көтәбез, бәлки, килерләр...
Табасыннан төшкән, кайнар килеш,
мин әнигә... укыйм шигырьләр...

Нәшир дә ул бүген, мөхәррир дә.
Тыңлый, мескен, тыңлый — күпсенми.
Тәнкыйтьче дә... Әмма хәтәр түгел
(үз баласын кем соң киссен ди?!).

Язгы болыт булып үтәр сүзе,
киң күңелле булсаң аз гына...
Ул әрләсен, аның күңеле булсын!..
Ә шигырьләр алар... языла!

*1974*

## *Чалгычылар*

Ак болытлар — һава пакуслары!
Чалгычылар,
җиң сызганып, көн күзендә
чабыгыз, әй!
Сезнең әле җиләк кебек чагыгыз.
Чабыгыз, әй, колачлап бер, илне иңләп,
тауга тиеп кыршалмасын чалгыгыз.

Чабыгыз, —
күк охшасын богылларга, — болыннарга
болыт-болыт
буй-буй юллар салыгыз!
Чабыгыз,
чишеп изү сәдәпләрен, —
онытмагыз
бабайлар гадәтләрен.
Чабыгыз! —
Киек Каз Юллары ятсын
яшел болын күкрәгенә,
таң калсыннар туган як гүзәлләре!
Чабыгыз!
Егылып калсын дошман,
шайтан таяклары,
искелекнең билчәннәре,
киң суласын Хакыйкать үзәннәре, —
чабыгыз!
Чыгарыгыз пакусларны офыклардан
офыкларга,
дан булсын оныкларга, —
яныгыз!..

*1975*

* * *

Болында — богыллар,
болында — бытбылдык...
Богыллар артында
без икәү юк булдык...

Мәтрүшкә исләре
исерткән җәй иде.
Безнеке! — кирәксә,
болынын җәй иде!..

Бытбылдык такмаклый
яшел тау артында
яшьлекнең үзе кук
кыска җәй хакында...

Болында — богыллар,
болында — бытбылдык.
Без ник соң ашыктык,
шул җәйдән
юк булдык?
Болында кайтаваз:
— Быт-былдык! Быт-былдык!..

*1975*



* * *

Күңелемдә тынлык. Бер җил дә юк.
Күлләр тыныч, әрәмәләр...
Сулар тонык! Яктырып ята
төбендәге гәрәбәләр!

Нинди моңсыз табигать бу —
кагылып үтми яфрагына бер уй җиле?!
Карлыгачтай очып керми җитез фикер!
Кая кошлар?
Кая дуслар?
Кая дошман?
Бозлык чорын кичкән сыман,
өнсез ята үзәннәре!

Болытлары ничек чыккан — шулай калган.
Сузылган да тып-тын тора
үлән-чәчкә сабаклары!
Шылт та итми бер кура да —
җил-хәбәрсез тармаклары!..

Нидер тыңлап, киеренке
бар табигать тынга калды.

Бу, мөгаен, минем җанда
давыл алды!..

*1977*



## *Рәхмәтле көн*

...Рәхмәт сәгатьләргә! Искәрттеләр:
шатлык киткән, мине көтмичә...
Рәхмәт Ньютонга!
Хакыйкатьне белеп булмас иде,
алма төшеп,
башым кұпмичә...

Рәхмәт Көнгә!
Кара мәкерeңне кұрмәс идем,
баш очыннан
Кояш ұтмичә!..

*1978*

## *Кунак кыз*

...Мине сеңлесе уятты
җәйге татлы йокыдан:
— Без китәбез апам белән,
чакырды сине, уян!

...Төшемдә мин аны кұреп,
саташып ята идем.
Кұземне ачалмасам да:
«Кайда соң апаң?» — дидем.

Сеңлесе аның аз гына
сипкелле иде, каһәр.
«Кырда көтә. Озатсын, — диде, —
яшь арышларга кадәр».

Арышлар, яшел арышлар —
тургайга диңгез инде! —
Толымнарын озата барам, —
Бәхетем тиңсез иде!..

Алып менә тургай мулдан
җир җырын күкләренә.
Түгә иде моңын гүя яшь арыш төпләренә!

Кунак кызы (килә тоташ
бер җырга әйләнәсе!)
Йөзендә буй-буй күләгә —
арышлар күләгәсе.

Атлыйбыз шулай, сокланып
һаваның сафлыгына.
— Озата бар мине, — ди, — теге
борылышка чаклы гына...

Кунак кызын озата барам,
ул чак ояла идем —
кагылырга да кыймаган
кыюсыз малай идем лә,
кыюсыз малай идем...

Борылышка җитәр-җитмәс,
тып-тын барган җиреннән,
сеңлесеннән артка калып,
үрелде дә...
тыны бетеп,
суырып үпте...
Очып ла китәрдәй булып
карап торды тегермән!..

Калды шунда үсмер чагым,
күмелде арышларга:
чыкмый ул, колак та салмый
«чык!» дигән тавышларга!

Кагылдым шунда яшьлекнең
беренче ялкынына!
Мин — бөтен кеше!
                    Моңарчы
булганмын
ярты гына!..

Барабыз икәү, сокланып
дөньялар сафлыгына:
— Озата барыйм
                    теге ап-ак...
болытка чаклы гына...

Кунак кызы! Яшь күңелемдә
түгел син кунак кына...
Шөкер, әле болыт чигенә —
болытка ерак кына ла,
болытка ерак кына!..

*1978*



## *Уяну*

...Шәһәрдә чүпләр яна —
узган җәйнең үләннәре...
Төшә тургай тирбәлеп,
сайрый яңа шәһәргә
язгы хәбәрләрне!..

Син дә инде ялыктың,
сүрән кышның куеныннан,
тартылып яз утына,
чыктың якты урамга —
нурлы яз туена!

Ялыккандай сөймәгән
ят яр белән яшәүләрдән,
чыктың — күңелең җилбәгәй —
сорый наз һәм азатлык
синең бөтен гәүдәң!

Газонда яна утлар,
сузылып якты болытларга...
Ягасы иде иске
тутыкларын күңелнең
салып шул утларга!

Чүксен иде көлләнеп
шаулап торган көн каршында,
хөрләнеп көлсен күңел,
ягасы иде чыгарып
мәйдан уртасына!

*1972*

* * *

Син — Мәхәббәт республикам минем,
үләндәй ефәк чәчләрең белән;
күкрәү алдыннан тупыллар шаулый
һәм болыт елый
синең яшьләрең белән!

Синдә ул минем тонык елгалар,
төбендә вак ташлар яктырып торган...
Чакыр, суга төш,
алып кер утка, —
барам, Шигърият,
синең артыңнан!..

*1979*

## *Авылда бер көн*

Әби-бабайлары каз көтәләр,
гәпләшәләр тутырып болынны:
«Чыпчык башы чаклы җир җиләге
чиләк тутырып җыйган оныгым...»

«Җир коргаксый, кордаш, яңгыр бездә,
«явым» димиме соң радиолар?»
«Пүчинкәдә кичә болыт төшкән, —
болын буйлап аккан сыерлар!

Ә бездә юк... Әллә халык азды?..
Күкләргә тел тидермәдек тә...
Өмет булып яшьнәп килгән болыт
авышып китте
Тегермәнлеккә!»

Сыңар аяк Гыйният ветеран да
бәбкә саклый ятып-үрмәләп.
«Әй заманнар! Берлиннарны алдык...
Шулай бит, дус, кордаш, Мөбарәк?!»

Ә кордашы аның кырга карый:
«Кая әле бала-чагалар?»
Көтү кайта икән — оныклары
чыр-чу килеп шунда чабалар!

Ут шары да сүрелеп тоныкланды,
шулдыр инде көннең үтүе...
Ниагара шарлавыгы булып
таудан төште
сарык көтүе!

Һәм күпергә керде томырылып! —
бирә алсаң, юлны кал биреп!
Юлына туры килсә, атар иде
плотиналарын каерып!..

Кызгылт тузан очты су буена,
юл өстенә төште күләгә...
Яшь киленнең чишмә сукмагында
зеңләп китте көмеш чиләге!

Йөгерә-атлый, чибәр җилкенчәкләр
су ташыйлар тымызык кич белән.
Һәм кайдадыр җырлый мотор-пычкы,
язылa шигырь
яңа хис белән!..

Ял чатырын тартты авылым күге,
йолдызлары чыкты җемелдәп...
Шаулап куйды чатта зифа таллар,
йомшак җилдә
талгын җилфердәп...

*1975*

## *Күңелсез шигырь*

Телеграмма алгач, кайтты улы:
«Бәхиллеген алып кал тизрәк!»
Ап-ак бәскә төренеп каршылады
Өй түрендә үскән чал тирәк.

Урыныннан торды сырхау ана,
Гадәтенчә ап-ак яулыктан...
Бәйнә-бәйнә сөйләп бирде аннан
Нилэр барын иске сандыкта...

Өлгерде мич, янып мең уйларда,
Тарта-тарта ахак күмерне,
Озайтырга тели аз булса да
Ана янындагы гомерне...

«Тизме-соңмы, бар да китәсе бит
Тарих дигән тирән китапка...»
Янда гына яткан иркә песи
Уйлый бугай бүген шул хакта.

Җете иде әле гөлләр төсе,
Җылы иде бәхет тигездә...
«Хөррият!» дип, ахры, мыштым күсе
Кыштыр-кыштыр килә нигездә...

*1987*



## *Сандугач пластинкада*

Көтмәгәндә генә «музтовар»да
таныдым мин синең авазны.
Кама сандугачы, бүгенгедәй
син сайраган идең ул язны!

Сәүдә бара!
Синең пластинкаң
күпме тираж белән тарала —
сыптыралар гына!
Сатучыга
кул сузылган кая карама!

Безнең менә яфрак чаклы гына
китап чыкса, ул да киштәдә
сатылмыйча ята еллар буе,
киштәләрдә тула дистәгә.

Якташым, дип, бер мактаныр идем,
исемең дә юк бит, ичмасам.
Йолдыз булдың инде!
Ярар иде
безнең якны ташлап очмасаң!

Пластинка —
урман эстрадасы.
Ә син — соло.
Сайрый-сайрый дискы әйләнә.
Исә гүя җылы урман җиле,
хорга кушыла кәккүк:
«Әл-лә-лә!»

Тыныч чакта бу ни!
Сайрый идең
үч иткәндәй сугыш утына.

А, өздергән чакларың бар иде,
туплар ак-ком-па-нементына!

Төн белән таң бергә кушылганда,
үләннәрдә чыклар янганда,
сугыш уты өткән урманнарда
концерт бирдең зәңгәр аланда.

Концерт бирдең бер түләүсез-нисез,
синең җырың яуны җиңеште.
Сандугачым, моңа, бер уйласаң,
бездән сиңа орден тиешле!

Җыр буенча ярыш уздырылса,
Җир шарында барлык кошларга,
булыр иде сиңа Гран-при
кошларара конкурсларда!

Салоннарны, җаным, сөймисең син,
яшәгәнче анда калтырап,
оч иректә!
Сезнең урман белән
гомерлеккә бугай контракт.
Урмандагы чыгышыңны тыңлыйм,
пластинка сайрый кибеттә...
Иҗатыңда шул син
кустарь түгел,
сайрау рәхәт
синең кебеккә!

*1966*



* * *

Кырларда — җил!
Җитен кырларында,
житен диңгезендә бүген — җил...
Җитен җилли!
Зәңгәр дулкыннарда
кыр тургае йөзә...
Туган җир!..

Җитен җилли
офыкларга тулып,
ишелеп-ишелеп кайта юлларга...
Бала тургай. Таныйм!
Ул тумыштан
пропискада
безнең кырларда.

Тугрылыклы.
Нәни метеордай
кыр өстендә риза янарга.
Яшел кыяклардан камылгача
басуда ул,
төшә камылга...

Яшь тургайлар менә —
яңа буын! —
туган ягым күгенә, алмашка.
Күгем тулы тургай!
Яздан — көзгә...
Мөмкин түгел
җырда янмаска!
Карт игенче, соң кат «хуш!» дигәнче,
һаваларга карар иң элек:
зеңләп калыр
гомер иткән дөнья,
күк юлына
биек чөелеп!..

1972

## *Жырың кайтты**

*(Жыр)*

Туган йортның ачык тәрәзәсе
Ишеттерде миңа бер көйне.
Урап-урап Яшьлек урамнарын,
Жырың кайтты миңа беркөнне.

Су буйларын иңләп йөрде жырың,
Чакырды ул яшьлек таңына...
Оныттыйм, дип, еракларга киттем,
Жырың тапты килеп тагын да!

Жыр хакына мин барырга әзер,
Исемеңне сорап еллардан.
Кая барсам, жырың эзләп таба, —
Юк котылу синең моңнардан!

Котылу юк синең моңнардан!

*1984*



* Г.Сәйфуллин һәм Ә.Шәрәфиев көе.

## *«Оныт!» димә...**

*(Җыр)*

Тик бер генә көлеп дәшкән идең,
Истәлеге калды озакка...
Онытканнар инде онытсыннар,
Ә мин риза татлы газапка.

Елмаюың синең балкый һаман
Күзгесендә якты елгаңың.
Онытасым килми, онытасым, —
Синдә минем яшьлек елларым.

Сагышлы моң тулы төннәремдә
Елмаюың синең таң иде...
«Оныт!» димә, зинһар, «Оныт!» димә, —
Җырым булып кына кал инде!..

*1986*



* Ф.Әхмәтов көе.

## *Сандугачны күрдем якыннан*

...Сандугачны күрдем якыннан, —
җәй нурында очып талпынганын!
Күзләрен дә күрдем — ике утны! —
шомырт чәчәкләре артыннан...

Сандугачка — ирек, дөнья имин,
сандугачның җыры, бәхете бар!
Дошман көчләләрен «Нахтигаль!»* дип,
юкка әйтмәгәндер, ихтимал?

И, тын күкләр аны исәр иткән,
сандугачым шаша таллыкта!
Мирәт куаклары арасында,
миннән башка бүтән җан юкта!

Ну сайрады! Урман дер селкенде
моңындагы дәртле ялкыннан!..
Минем дә бит ярышырга исәп, —
күрдем аны бүген —
якыннан!..

Мин җырладым, ә ул тынып калды, —
ташладымы асыл тирәген?
Әйтте бугай: «Шул да җыр булдымы?
Бармы монда синең кирәгең?!»

Серен бирмәс,
утка егылып төшәр, —
биек тотар
моңлы йөрәген!
Сандугачны күрдем якыннан, —
бар дөньясы хәтәр ялкыннан!..

*1987*

---

* Нахтигаль (*нем.*) — сандугач.

## *Сандугач*

И сайрый сары сандугач,
Сызгыра талларымда.
Имәннәрне сыга торган
Көч бардыр җаннарында!

Белсәңче, калтырый икән
Тамагында нинди кыл?
Әсир итте! Нәни кошка
Инде мин дә, син дә кол!

Табыйк без шул сандугачны, —
Талларга күмелгәнме,
Көен яфрактан карыймы
Йә сайрый күңелдәнме?

*1968*

## *Бакый ага Сөембикәсе*

Мин гомерем буе җырладым.

*Бакый Урманче*

Ак дөньяда, өстәп бакыйлыгын,
Бакый ага сынга җан өргән…
Могҗизамы, —
тормыш суты ташып,
Агач тамырлардан йөгергән!
Күзен ачып
йөреп китәсе бар, —
Ул терелгән, оста, терелгән…
Сөембикә булып өлгергән!
Өтергеңне куймый җырлый идең,

Бакый ага,
жырла тагын бер, —
Җанкисәгең Сөембикәңә дә
Үзенең жырын,
чорын сагындыр!
Төрбәсеннән торсын әле ханнар,
Сафа Гәрәй торып утырсын!..
Гүрдән торып, алар ак дөньяны
Яшәү гаме белән тутырсын!

Шатлансыннар күкләр, газиз туфрак, —
Жырласыннар бөтен катламда...
Татар рухы жирдә ятар түгел, —
И, милләтем итсен тантана!

Сөен, бикә!
Син яңадан тудың!
Чорың — ерак, —
Сөен, сөенмә...

Күңелләрдә ап-ак киемнән син,
Тик карадан...
берүк
киенмә!

*2004*



## *Ана арыслан*

Мин мәхәббәт шигырьләре язам,
Мәдхияләр —
хатын-кызларга!
Бөреләрдән яфрак шартлап чыгуын
Күтәп торган
сабырсызларга!..

Мин мәдхия шигырьләре язам
Бөҗәк дөньясына,
этләргә...
Шигырь итәм хәтта
карт маймылның
Утырганын
Сабыеның...
бетен чүпләргә!..

Үлеп сөям ерткыч җанварларны!..
Аеруча...
ана арысланны яратам.
«Төшке ашка... кайсын тотарга?» — дип,
Кырын ятып, хәйлә кора ул...
Аһ, бәгырем,
сабые тырнашканда
И куана,
Елмайгандай карап тора ул!..
Яратудан хәтта ырлап куя:
«Ауга чыгар тиздән үскәне!..»
Җилне исни үрелеп,
күренеп кала
Күпне күргән
азау тешләре!..
...Янәшәдән уза филләр кәтүе,

Узгалыйлар мөгезборыннар...
Сахраларын дер селкетеп торган
Яллы патша —
үз урынында.
Өрекмичә йөрсен газәлләр дә, —
Төшәр тиздән алар юлына...
Ә хәзергә...
Тропикларны тетрәндергән тиран
Яшь аралаш,
сөеп,
Карап ята
нәни улына!..

*2004*

## *Күзгә якты дөнья уртасында*

Ага суда тезелеп сары яфрак,
Калганнары тора талда калтырап:
«Җитәсе бит бу хәл безгә дә...
Без язларын мендек зәңгәр күккә,
Килгән кебек идек мәңгелеккә,
Килер бу мәл, дуслар, сезгә дә,
Күзгә дә...»

Төялеп лә китә матурлыклар,
Ә язларын кире кайтырлыклар
Күзге суга төшә капланып:
«Без кайтырбыз язын бөре булып,
Бүгенгедән эре, тере булып,
Тик кышларын үтик сакланып,
Шатланып!»

Күзгә матур дөнья уртасында
Китәм, диеп, кайчак куркасың да,
Йөрәк-яфрак тора калтырап...
Әллә нигә бөтен фасыллардан
Гүя бөре әле ачылмаган, —
Күз дөньясын сөям катырак, —
Яктырак!

Яшәтә бит безне өмет кенә,
Агымсуда без бит күбек кенә, —
Күтә күзге яфрак хәлләре.
Югыйсә бит кояш яктысында,
Табигатьнең юлым яртысында
Шәм кабызып куйган мәлләре,
Балкып яңа яшәү гамьнәре!

*2004*

## *Соңгы яфрак*

*(Элегия)*

**1**

...Утыра ул карап тәрәзәдән
Күннәр буе — бөкре, чал карчык.
Ни соң күзли сүнә язган караш,
Кайда калган Яшьлек
адашып?

Урамда күз.
Күз, дип саргайган йөз, —
И бу күзе фани заманның!..
Өзелеп төшәр чагы җиткән ләса
Соңгы яфраккае чаганның...

Шул урамнан әллә эзлиме ул
Яшьлегенең ерак шәүләсен?
Искән җилдәй шаулап үткән гомер.
Табалганмы шуның мәгънәсен?..

**2**

Күзнең соңы кергәндә,
кырау ятты үләнгә...
Оча соңгы яфраклар,
Салкын җиргә кунаклый:
Яфрак тамырны каплый,
Яфрак
тамырны
саклый!

Табигать үзен аклый, —
Җәй гомерен йомгаклый...
Җәем инде ерактыр, —
килеп
киткән
кунактыр...
Мин дә китмәм еракка:
охшап соңгы яфракка,
бер
төшәрмен
туфракка...

*2004*

## *Беренче кар*

...Беренче кар әле безнең, беренче кар...
Туйдан чыктык ак иртәдә — беренче пар...
Каеннарда җем-җем итә ап-ак чуклар...
Без яшь чаклар әле бит бу,
без яшь чаклар!..
Аяк асты гүя йомшак ап-ак шафран,
Яфракларны, очмасын дип, ак кар япкан.
Җитәкләшеп килеп чыктык таң каршына.
Аң-таң булып,
яңа гына, балачактан!..

Балачаклар кемнән дә ул калачак ла,
Беренче кар... әле ишеп явачак ла!..
Ява-эри, ява-эри, гүя шикәр...
Ә шулай да...
мәңге истә калачак ла
Беренче кар...

Кайда соң сез, шул ак таңның пакь сүзләре?!
Эзләп йөрим —
кайда безнең беренче кар,
беренче кар?!
...Беренче кар өсләрендә — кош эзләре,
Туй итәләр безнең өчен
чәүкәләр дә вә чыпчыклар.
Беренче кар!..

*2004*

## *Уяну*

*Мөтәдусларга*

Янус кебек гаҗәп дусларым сез,
мин идем бит сезгә тартылган...
Антларыгыз, бөтен хакларыгыз,
«ахирәт дус» дигән чакларыгыз,
кубуга ук табын артыннан,
төтен булып оча, тарала...
миражга тиң ялган хыяллар да
очкан-киткән җилгә... кай ара?..

Мәкер-хәйлә белмәс нарасыйдай
елышканмын сезгә табарак;
«диңгез» дисәм — аквариум икән,
«көймә» дисәм — ярык тагарак,
«шәмдәл» дисәм — тычкан уты гына, —
юлны таптым капшап-кармалап...
Йә, хушыгыз, сезгә үчем дә юк,
тик хаклыкны белдем яңарак.
Соң булса да, уң булсын, дип китим
кояшлырак якка табарак!
Сездә калсын
ярык тагарак...

*1987*

## *Шагыйрь*

Сүз мәгънәсен эзли җирдән, күктән йә таштан,
Сүз газабында көя, яна ул тоташтан!
Сүзләрдән генә торса да гәрчә гомер биштәре —
Таба алмый асылын — туу үлемгә тоташкан!

Инде ачылып китсә дә Иҗатының офыклары,
Чүмечләп эчсә дә гөрләгән суларны,
Ятып чөмерергәдер болытлары белән — дәрьясын, —
Басмыйдыр сусынын дөнья ярсулары?!

Өч көнлек дөньяда — гомерлек мосафир,
Һәр яфрак, агачның сорап ул исемен
Кояшлы аланны кичкәндә, сизми дә
Килеп үк җиткәнен гомере киченең...

Хуш, Кояш, тапшырдым, минем дә баешым,
Син таңда туарсың офыкта яңадан...
Ишетелер шикелле җиһанда тавышым
Минем дә яңадан
Өр-яңа тугандай анадан...

*2004*

## *Иске көйгә*

Юк инде, алмый безне һичнинди модалар,
Язабыз тик үткәннәргә мәдхия-одалар;

Гашыйклар рухына багышлап шигъри намазны
Тотабыз йөрәктә яшьлектән килгән тоньк авазны.

И иркә, садә авазлар киләдер ерак бакчалардан.
Яшьлек бакчалары! Бер тылсым юк инде аны ача торган.

Андый бакчалар юктыр шул Бабилдә* дә Икесуда,
Эзләсәң дә юктыр кыйтгалардан, дүрт шәм тотып ике кулга.

И илаһи гомер! Булсачы әгәр шундый иркең генә:
Шул бакчаңа кунак булып килим бары бер көн генә.

И яшьлек, син бәһасез энҗеләрдән торган таҗсың.
Мә, елларым тавын ал шуның бөртегенә!..

*1985*

---

* Бабил — Вавилон — биредә дөньядагы җиде могҗизаның берсе саналган Семирамидадагы асылмалы бакчага ишарә ителә.

* * *

Үкен, үкен —
инде үтте ул көн,
очты җилгә тотен —
очкан гомер...
Тәңгәл икән барысы —
бергә-бер...

Очкан төтен,
җилгә очкан гомер —
моңлы төшем белән
бермә-бер!

Ни калдырдың?..
И ул гүзәллекләр,
үзәнлекләр —
билдән ак чәчәк!
Ике кулда чайпалдырып савыт,
ак сөлгесен иң өстенә салып,
ни китерә
көткән Киләчәк?..

Ни китерә?
Йә, әйт.
Дүрт күз белән аны
күтәп алып, —
әллә язмыш балы,
әллә... агу, —
күпме икән аңа
бирәчәк?..

*1982*

## *Күләгәләр*

Һәркемнең бар үзенең күләгәсе,
йөргән чакта җирдә гәүдәсе;
кай ишектән керсә, шымчы кебек,
шул тишектән керә — шәүләсе!

Тик күләгә — бездән «акыллырак» —
якынаймый башлап Кояшка:
Кояш алдан булса — артка поса,
арттан бәрсә Кояш — ул башта!

Көн кыскара, ә ул — озыная,
нәфесе зур — Кояш төшәме —
урамнарга озын сузылып ятып,
бездән соң да яшәү исәбе...

Юк, без инде күләгәләр түгел,
күчермәләр түгел —
нөсхәләр!
Күләгәләр — юан...
Ә без — күңел кебек,
йөрәк кылы кебек
нечкәләр!

Күләгәләр булмадык без җирдә,
шәүләләр дә булмыйк
гомергә.
Беренчеләр бит без!
Күләгәләр... әйдә, йөри бирсен,
акыл җыеп
кичке эңгердә!..

*1972*

# *Сабырлык хакында*

«Сабырлыкның төбе — сары алтын»,
шулай дигән минем сабыр халкым, —
уйларымда дөрләсә дә ялкын,
сер бирмәскә иде исәбем...
Уйламаган-көтмәгәндә генә,
максатыма җитмәгәндә генә
тормыш төртте утлы кисәвен...
Сабыр итү иде исәбем!..

Бу — дәфтәрнең башлануы гына,
саф хисләрнең раслануы гына,
җыр туфрагы ашлануы гына
илтер микән көткән максатка?
Максатыңа фәлән чакрым гына,
сабырлык шул килми чакырып кына, —
сабыр итеп булмас, ахры, миңа,
өр-яңа бер гомер башлап та!



## *Шигърияне чакыру*

*Р-гә*

### I

...Сеңелем,
көнлим сине җилдән, —
әйтерсең ул көзге урманнардан —
минем Шигъри Биләмәмнән —
Сине алырга килгән!

Урман куенындамы, —
кем куенында, кем уенда булуың түгел, —
шигъри рухың минем биләмәдә, —
көзге яланнарда
кагыла кылганнарга...

Сөйкемле күләгәңне дә
бирмәс идем беркемгә дә...
Төркем-төркем көлеп үтә асыл затлар,
и йолдызлар! —
Сине генә кертә алмыйм
бер төркемгә дә!..

Сеңелем, кил син
яңгыр пыскыганда,
күке кычкырганда,
урманнарга бергә чыгар булып,
йә буаз болытлар яткан чакта
күк читендә тугарылып,
нәни урманчыдай
учак каршысына бил буып...

Сеңел, төнен кил син,
тәрәзәмә
көзге җил булып!
Һич югында,
тып-тын балкып утыр,
тәрәз төбемдәге гөл булып!

Баш очымда шигъри тәсбих моңы,
шул моңнарга ятыйм күмелеп...
Төн пәрие, йолдыз!
Килер булсаң,
җилләр аша җиткер иң элек...
Шигырьләрем көтә сибелеп!..

## II

Кил, Шигъриям, төнге урамнардан, —
Син бит юлны миңа беләсең.
Назлы яр күк инде хәзер миңа
Сагындырып кына киләсең...

Гомерем буе син канатым булдың,
Хыял илләренә чакырдың.
Яңгыр булып тәрәзәмә чирттең,
Син килүгә өем яктырды!


Искә алып ерак ул елларны,
Җитешкәндә сагынып еларга,
Җиңел кулың белән әле дә мине
Җитәклисең алгы елларга...

Киткән ярлар — китте, оныттылар,
Хәтерләмим мин дә күбесен...
Тик син калдың, тик син, и Шигъриям, —
Онытылыр ярым түгел син!

Җиде төндә торып уйланам мин,
Синең белән калып бергә-бер,
Кояшларың белән син килмәсәң,
Яшәлмәгән, димәк, бу гомер,
Гомерем буе сиңа тугры булдым, —
Син дә китмә инде, и бәгырь!..

*2005*

# Тынлык ни сөйли?



## *Азиядән тавыш килә*

Ут-күзләрдән саклап кына,
Үтеп күп еллар арасын,
Яраларны ялый кояш,
Концлагерьлар ярасын.

Узган сугыш чирләреннән
Теләп вакытсыз сулмаска,
Карт Европа, ярдәм сорап,
Күкрәгеп ача Кояшка.

Азиядән килә Кояш,
Азиядән килә тавыш:
«Исәнме, Европа туташ,
Мә, Кояшны, иске таныш,
Кайтар ләкин тапсыз килеш,
Янгыннарны кичертмичә,
Яңа үлем мәйданының
Күләгәсен төшермичә...»

*1958*

## *Жыр чыкты җирне урарга*

Җил чыкты, такыр юлларда
Томаннар тормасын, дип;
Жыр чыкты җирне урарга,
Хәвефләр булмасын, дип.

«Кем анда, кемнәр көрсенә,
Сагынып имин чагын?
Кем анда таңны күпсенә,
Ут белән уйный тагын?

Кем анда көчләп утырта
Сугышлар арбасына?
Кемнәрне шайтан котырта
Әрвахлар арасына?

Зәйтүннәр үскән җирләрнең
Даулашып имин чагын,
Утларга батыр ирләрнең
Сафлары керә тагын...

Кан кою өчен юлларның
Күп микән тапталасы?» —
Жыр чыкты җирне урарга,
Билгесез — тукталасы.

Җил чыкты, такыр юлларда
Томаннар тормасын, дип.
Жыр чыкты җирне урарга,
Хәвефләр булмасын, дип.

*1954*

## *Ут сәнгате*

Бонн шәһәреннән Бетси ханым «картина»ларын автомат уты белән «иҗат итә»... Көнбатышта «флеймизм» яисә «ут сәнгате» белән шөгыльләнү таралган. Шундый «иҗатчылар»ның берсе дания-ле Энрик Мюнстер...

*Газета хәбәрләре*

Германия төти.
Дрезденда
шыплап тулган
китаплар яна.
Галерея.
Сикстин мадоннасы —
баласына иелгән Ана...
Тор, Рафаэль,
китаплар яна!..
Ишекләре бикле килеш янган
кешеләр төсле дөрли китаплар.
Утопистлар,
реалистлар яна,
ут — сайламый, —
кемне кем тапкан?..
Стенадан Ана мөлдерәп карый:
бу тәмугны җиргә
кем яккан?!

Хәрабәләр,
ахак ялкын аша
рапсодия агыла,
ургыла...
Скрипка елый.
Ялкын бии.
Сугыш өрә
утлы быргыга:
«Трим-там-та!..»

Ут давылы тынды.
Ут — футурист.
Яңа хәрабәләр ясап китте
Европаның полотносына.
Кеше түгел,
тик козгыннар төште
абстракция тантанасына!..

О, никадәр «иҗат итте» алар,
чигәләргә кургаш батырып!..
Материалы — каннан һәм сөяктән,
менә сиңа иҗат,
модерн!

О, никадәр «иҗат итте» Дахау,
Майданекның кара дарлары!
Әле һаман ыңгырашып куя
Заксенхаузен диварлары...
Давыл тынды.

Күрәсезме, кешеләр,
баш очында күпме
таш үскән!..
Давыл тынды.
Ләкин тыныч димә,
Реализм, сак бул, —
фашистлар!
Реализм, җирдә вакыт-даһи
эшләсә дә синең файдаңа,
автоматлар белән иҗат иткән
«модернистлар» калка мәйданга!
Реализм,
сәнгать фашистлары
храмнарга кереп таптана...

Тор, Рафаэль,
Мадоннаңа кара,
күзләреннән тып-тып
кан тама!..

Скрипка.
Рапсодия.
Җилләр.
Җир өстендә —
Язгы тантана!

*1963*

## Җидегән йолдыз

Чатнама кыш, кошлар егылып төшә
очкан килеш. Күздә яшь туңа!
Җидегән йолдыз ул чак балкый иде,
карый идек икәү без шуңа.

Бер тәгамне бишкә бүлеп капкан
ул елларның истә газабы...
Кайгы елгасыдай ул елларның
булмас кебек иде азагы!..

Белмәгәнмен ана йөрәген мин
тагын әле ниләр телгәнен.
Белмәгәнмен әле йолдызларның
кан дәрьясы җирдә күргәнен.

Европаны баскан кан дәрьясы,
абыйларым батты шуңарга...
Әткәемнән кара конверт килде,
мәҗбүр йөрәк шуңа чыдарга...

Бухенвальдта җәллад кеше туный,
Освенцимда — таудай корбаннар...

Сулыш сорап, ачы ыңгырашып
тетрәгәндә җанлы курганнар,
Җидегән йолдыз, елап, йөзен чытып,
болытларга качкан моңаеп.

Яшен сөртеп, анам күктән барын
укыгандыр ул чак, мөгаен.
«Җиде балам — җиде җирдә» диеп,
төннәрендә җиде әйткәндер.
Тәрәзәгә килеп җилләр чиртсә,
чыга иде йөгереп: «Әткәндер».
Күзләренең керсез яктылыгы
йолдызлардан, бәлки, иңгәндер.
Җидегән йолдыз кебек бергә итеп
хыялында безне күргәндер.
Ул сер булып калды.
                    Ә чәчләре
сизелмичә һаман агара...
Элеккечә сабыр, элеккечә
күзләрендә сагыш яңара.

Нигә шулай соң син, газиз ана,
туйгансыңдыр элек елап та?
Җавабыдай анын, җем-җем итеп,
Җидегән йолдыз яна...
                    еракта...

*1958*

## *Тынлык ни сөйли?*

Дөнья тып-тын.
Тыңла, йом күзеңне,
ишетелер үлән үскәне,
Европаның тонык күкрәүләре,
Азиядә яңгыр төшкәне...

Мин: «Тынлыкны тыңла», — дисәм сиңа,
«Нинди телдә сөйли ул?» — дисең.
Чөнки син бит әле җир йөзендә
снарядлар тавышын белмисең.

Тынлык үзе җиңү юлларыннан
туплар тынгач килә дөньяга.
Әйтерсең лә тормыш яңа туа,
әйтерсең лә дөнья —
өр-яңа!..
Соңгы кабат җиңү залпы белән
күккә очкач соңгы кургашын,
окопларда сугыш үлеп кала,
тынлык таба шунда юл башын.
Төшенәсең гүя җилләр теленә,
кырларыннан гөлләр өзгәндә.

Тынлык кайта! Аның белән бергә
сандугачлар күченә үзәнгә!..
Мин: «Тынлыкны тыңла», — дисәм сиңа,
«Төсе бармы,
нинди ул?» — дисең.
Чөнки син бит әле җир йөзендә
хәрабәләр барын белмисең...
Чөнки син бит җиргә тынлык белән
бергә килдең, аның юлдашы.

Тын юллардан, тыныч кырлар буйлап,
сызылып китә якты юл башың...
Атылмасын атом вулканнары
лава булып аяз күгемә.
Пулеметлар — үлем ораторы
сөйләмәсен үлем телендә!
Тынлык тавышын бары тыңлагыз сез,
ишетәсезме, —
пышылдыйлар җилдә бөреләр!
Җилләр җитмәс шундый биеклектән
ул йолдызлар сезгә ни диләр?
Ишетәсезме, —
тып-тын гына
                    зәңгәр үзәннәрдә
ефәк җилләр йөри тулганып.
Тып-тын гына таулар тыңлап тора
сөйләшкәнен төнге елганың...
Ишетәсезме,
шатлык чәчәк ата!
Ишетәсезме,
көннәр йөгерә...
Тып-тын гына җылы җилләр йөри,
планетада
сезгә диган бәхет өлгерә!..

*1974*

## *Тыныч кояш елы*

*(Мәдхия)*

Астрономиядә «тыныч кояш еллары» бар.
Гади күзләргә кояш, билгеле, тыныч күренә.
Җирдәге шартлаулар да аның төсен бозмый кебек...

Әйбәт бу ел: кояш тыныч.
Юаш, Сабыр!
Тәртибенә
«биш»не куя астрономнар.
Әйтерсең лә
каргамаган аны беркем.
Кара куллар,
маңгайлардан тирне сөртеп,
каргамаган, яңгыр көтеп.

Әйтерсең лә
бер чакны да
каралмаган,
тотылмаган.
Әйтерсең лә
кояш исеме белән
бер мордар да
ант итмәгән,
котылмаган!..

Тыныч кына елмаясың, Кояш.
Ә бит синең сурәтеңне
төрле позаларда
ясадылар
урам рәссамнары.
Җилкәннәргә төшерделәр
Посейдондай*.

---

* Посейдон — мифик диңгез алласы.

Күпләр
синең утлы шарың каршында
тезләнделәр хамелеондай,
мәрхәмәт сорадылар,
синең үлүеңне теләделәр.

Син күрмәгән гүя берсен дә!

Ә кайвакыт,
йөзеңә җир шәүләсе төшеп,
тулгак тоткан төсле каралганда,
алар
кулларын җәеп ялвардылар:
«Тукта!
Кояш, үлмә!»
Әнә шулай ярый алмадың син кешеләргә.
Син аларга бриз булып,
муссон булып килдең,
кайгылы йөзләрен,
кипшенгән иреннәрен юдың,
шауладың океан өстендә,
яңгыр булып...

Синең юмартлыктан файдаланып,
байракларына төшереп синең сурәтне,
шәһәрләрне җимерделәр.
Ә син — тыныч!
(Бәлки, борчулыдыр,
кешеләргә генә күрсәтми.)
Ә син быел тыныч.
Утлы клавишыңда
тик тынычлык көен уйныйсың,
Җиргә алтын кыллар тартылган...

Бер кояшмы соң син?..

Рәхмәт, Кояш!
Алтын сабырлыгың хакына!

*1964*

## *Елъязмадан бер көн*

*(22 июнь, 1941 ел)*

Төнлә зур план өлгерде.
Паркет буйлап елтыр итекләр
арлы-бирле йөрде.

Йөнтәс юан бармаклар
иелеп кул куйдылар:
план әзер!
(«Инде хәзер үрелергә дә була
байракка!»)

Аннан
килеп бастылар
дөнья макеты алдына.

Кулларда — флагчыклар.
Алар тиздән, зураеп,
кайсыдыр капкаларда,
гөмбәзләрдә җилфердәрләр!
Әле картага тик
энә белән генә кадыйлар.

Күчерәләр шахмат уйнагандай:
— Европага — мат!
Фрау Россия,
инде сиңа чират!..
...Әле чикләрнең ни икәнен белми кошлар.
Төклетура Рейн ягыннан Вислага оча.
Җылы яңгыр, Одер аша чыгып,
рәхәтләндерә
Дунай розаларын сугарып!
Әле болыннарны иңли уйсыз чалгы,
җиләк кенә киселеп оча бары!

...Ә картада шул болынны
кызыл белән урадылар...
Берни белми чыбыркысын сөйрәп йөргән
малайны да калдырдылар
шул божрада.

Тагын божра, уттай божра...
уратды усакларны!
Димәк, бу урманда дөрләр иртән
партизан учаклары!..

Байракны күчерәләр карта буйлап, —
якынлаша блиндажлар жыры.
Байракны кададылар калага, —
димәк, әле җавап бирәсе бар
блокадаларга!

Карта буйлап карандаш йөри,
бер ноктаны табып, шакый шунда, —
димәк, Җир тын калыр
стенага шакып сөйләшкән
тоткын коммунистлар тавышына.

Итекләр шыгырдый паркетта —
бу әле Мәскәү янындагы кар түгел!
Торачак әле чайкалып бураннарда Зоялар —
аларны таңда дар көтә...

Ишек ачыла — кандай кызыл бусага...
Таң кызарткан йөз белән
мәңгелеккә китәр Мусалар...

Тәмәкесен мәрмәр савытка төшерә берсе —
тиздән Гастелло
янган самолетын
юнәлдерер
автоколонна өстенә!

Тәрәзәгә килде рейхсфюрер,
томалады таңны —
тиздән, шуышып соңгы көч белән,
үлем уты сипкән дзотларны
күкрәк белән каплар
Матросовлар, Газинурлар...
«Майн кампф»ның соңгы битен япты берәү,
һәр хәрефе аның — баш сөяге...
Европа өстендә старт өчен
күтәрелә куллар.

Әле быргыларга тулышып тора
перроннарга түгеләсе моңнар...
Тузан гына уйный юлда...
Офыкта яңа көн өлгерә.
Түшендә елмая сабый:
баш очында
алма күрә...

*1967*

## *Ватык гильотина*

...18 августта,
ватылу сәбәпле, гильотина
эшләмәде.

*Гестапочылар рапортыннан*

Без шаһит:
кымшанмады гильотина, фюрер, —
без шаһит!
Без, арийлар, сиңа кул кушырып килдек,
эшләмәде машинабыз, нишлик?
Эшләмәде, үзебез дә кул кушырып тордык...

Рурдан иде корычы да, эшләмәде.
Хурлык!
Әллә каты муен эләккән, әллә үзе ватык.
Империя маркасы бар балтасында, факт!
Бүгенге кич йолдызлы иде, шигъри иде вакыт.
Сүнмәгән йолдызлар яна, шаһит!..
«Тегеләре» сөйләшә алмый, хәер,
стенага шакып.
Тереләре — тере килеш, факт!
Гендель музыкасын куйган идек, кан көенә
җайлап...
Бүген бер баш та чапмады, кан акмады сайрап.
Бу дөньяга мәгълүм безнең
«нацист» дигән кайрак!

*

Язды алар рапорт: кызыл чирдән
без киләбез җирне коткарып...
фәлән сәгать инде чаба алмый,
сәбәбе шул: техник тоткарлык.
Кадалгыры!
Империяләргә хезмәт иткән
иң тәвәккәл, төгәл машина —
гильотина балта күтәралмый,
төшералмый кешеләр башына!
Чират көтә сугым! Палач кына
ирешмәде бүген бәхеткә.
Төн сезнеке, татарлар һәм галлар!
Бәхетегез бүген, яһүдләр!
Бәхетегез әле — төн буена
катнашмыйсыз гареш туенда...
Һәм бәхетле сез дә... башкисәрләр,
башларыгыз әлегә муенда!
Утыра тормыш үлем вокзалында,
гомер тавын сөйри сәгатьләр.

Зур дөньядан китә алмый кешеләр
кечкенә бер
«техник сәбәптән!»
Ә башкисәр әле башын кашый —
атказанган сугым мастеры.
Гильотина — маллар арасында
егылган да үлгән ач бүре.
Нәрсә булган, әле әрдәнәгә
шәп тураган иде югыйсә?..
Бу минутта хокук яши әле
хат язарга әйтеп:
«Ул исән!»
Бу минутта, тәрәзәсен шакып,
шатландырып була һәр илне:
улларын Җир әлегә югалтмаган.
Дөнья әле
тере Җәлилле…
Бу мизгелдә илгә багышланып
тере җырлар тибә канында…

Соңгы тәмәкесен тарта җәллад
үлем машинасы янында…

*1972*



## *Сабый елы*

Берләшкән Милләтләр Оешмасы 1979 елны
Халыкара сабый елы дип игълан итте.

Җиргә, күккә бир сабырлык,
тыныч кына янчы, Кояш!
Илдә-җирдә имин, иркен
сабыйларның сулышын тойгач!

Сез дә, президент әфәнде, —
иминлекнең гади юлы, —
әмер бирегез томаларга
пушкаларны, —
Сабый елы!
Сабый елы...

Тып-тын торыгыз, литавралар,
үлән шыткан тавышларны
ишетерлек булсын җирдә,
суның ярга ышкылуын,
җилнең ефәк алкышларын...

Сезнең бурыч, әфәнделәр,
урталыкны табу юлы.
Тынып тыңлыйк Кояш җырын —
җирдә, күктә,
бар киңлектә
дәвам итә
Сабый елы,
Сабый елы!

Үлән шытсын, сөт күп булсын,
яңа Өмет туып торсын.
Җир Өмете черем итә —
чаң-набатлар тынып торсын,
ут-кораллар торып торсын!..

Нәрсә көтә аналарның
киләчәккә сузган кулы?
Галәм асларында изге
нарасый ел —
Сабый елы,
Сабый елы!

Аналарның күз карасы —
юк аларның гади елы.
Аналарга һәр елны да
гомер буе
Сабый елы,
Сабый елы!

Җәрәхәтле планетаның
иңнәренә сарыла быел
сабый кулы —
Сабый елы.

*1978*

## *Җәллад*

Чәчләре чал агай: — Минем һөнәр —
Уникальный ул! — дип мактана, —
Юк, арттырмыйм, — ди ул, — Хөкем көне —
Нюрнберг истә саклана...

Үткән-беткән эш, — дип сөйли миңа, —
Палач булдым үткән гасырда.
Туры килде Ватан сугышында
Күп фашистны тотып асарга!..

Син... шикләнмә, — ди ул, — хезмәтем шул,
Асуга да кирәк осталык.
Берәү... икәү... синең кулдан китә...
Ияләндем, киттем остарып.
Муеннарга элмәк кидерү — пүчтәк,
Осталыктан килә
кыскалык!..

Бер фашистны... астым...
биш мәртәбә!
Булган, ахры, аның биш җаны?!
Соңгы җаны инде очты дисәм,
Сикереп тора, элмәк бушанып!..
Эшне кыска тотам:
«клиентларым»
Эһ тә итми кала
таганда...
Сугыштан соң киткән әрвахларым
Атыналар сыман...
һаман да!..

Башын иеп, Ходай каршысына
Һавалардан атлап барган кук!..
Бара-бара, бермәл
тынып кала...
Болытларга җитеп арыган кук...
Син шагыйрьме?
Минем...
хезмәтемнең
«шигъри ягы» әллә ошады?..
Сугыш бетеп,
дарга чират үткәч,
клиент беткәч,
урын бушады...

Гөнаһларым алай юктыр димен, —
Үтәдем мин приказ кушканны,
Палачларны аскан палач идем,
Дошманнарның булдым дошманы!

Җирдә күптер гыйбрәт алыр нәрсә, —
Хакимгә дә хаким,
Палачка да палач бар, димен.
Юкка гына тагар иделәрме
күкрәгемә
«Җиңү» орденын?!

*2002*

## *Өлкән таллар урамы*

Өлкән таллар урамында
узган җәйнең моңы тора.
Иң чал тал да кыштырдамый,
тын утыра.

Урам өстенә иелеп
уйный таллар, чумып моңга;
ә уйлары сузылып ята
күләгәләр булып юлга.

Өлкән таллар урамында —
кызыл йолдызлы капкалар.
Эңгер төшсә, ачыла-ябыла:
хәтерләр кайталар...

Кайта башлый кайтмаганнар,
кайта хатирәләр, сагышлар...
(Өлкән таллар урамында —
онытылган тавышлар!)

Кисеп чыга юлны ак өметләр —
кайталар —
яшьли киткән егетләр;
аксакаллар тамак кыра, күршеләр.

Кемдер буш нигездә күрсенә.
Көннәр сәлам бирә бер-берсенә...
Йөри анда кыймый гына
киленнәрнең күләчлеге.
Чагылып китә, моңлы төштәй,
әниләрнең яшьлеге!..

Аналар хәләл сөтен имезгән —
кайталар бар да
туган нигезгә:
кайталар —
улларыннан яшь аталар,
аталарын узып чалланган уллар...

Энгер төшүгә,
Өлкән таллар урамына
кайталар —
бер-бер артлы
еллар!..

*1978*



## *Йокысыз төн*

Йоклый алмый ана төнге сәгатьләрдә,
яши ул төнне җиңеп,
сугыштан кайтасы улларын көтеп,
ут кабызып йокларга гадәтләнгән.
«Улым, — ди ул, — кара әле сәгатьне,
ничә икән Җир вакыты белән?»
(Сәгать белән әтәчләр
таңгал киләләр төндә.)
«Улым, — ди ул, —
сәгать сукты ничәне?»
Йолдызлар яна атылып
төштә түгел, өндә!
Йокысызлык авырайтты башкаеңны,
чалартты синең чәчләреңне бу тормыш та.
Иссен генә иде кыйбладан
җиләс җил,
тамсыннар иде түбәгә көмеш тамчылар, —
җиңел булыр иде сулышка!
Без йоклаган чакта да,
йокламый хәсрәтле Җир,
гүя аны бикфорд шнурына асканнар.
Без йоклыйбыз, — ачыла абага чәчәге,
бөреләр тын гына көтәләр таңны,
төнге җилләр әллә кая качканнар...
Ай узып китә тәрәзә артыннан,
көтә Җир
әтәчләр суккан иң имин чаңны.
Йокы алмый безне өр-яңа таңнар каршында —
Җирдә әле фаҗигаләр тулы.
— Биләүдәге чактагыдай тыныч йокла, улым!
Чал чәч юлы кебек Киек Каз Юлы...
— Ничек тыныч йокларсың соң бу дөньяда?
Йоклатырга җыеналар безне болай да...

Төштә түгел: ракеталар төбәлгән күккә,
зур янгыннар төтене килә
җилләр искән уңайга.
Йоклый алмый Җир!
Чүп кенә тик
йолдызлар фәлсәфәсе аңа.
Аңа әзерлиләр яңадан
йокы порошогы —
агулы газлар,
тәмуг базлары
үрчеп тора һаман да...
Тарихтан сабак алып,
йоклый алмый
гүзәллекне тудырган халык.

Без дә,
Җирнең мәшәкатьләреннән,
ызгышларыннан
беркөн
арып китеп йокласак та,
йокларбыз тик
Вөҗданны һәм Уяулыкны
куеп сакка!

*1986*



## *Татарстан туфрагы*

*(Мөнәҗәт)*

Көлсу туфрак та кара туфрак —
Татарстан туфрагы.
Дага эзе иңгән яудан,
Тарих үзе эзен салган
Татарстан туфрагы!
Кара туфрак та кызыл туфрак —
Татарстан туфрагы.
Йөрәгеннән каны тамган
Бабам буразнагаауган
Татарстан туфрагы!

Комлы туфрак та моңлы туфрак —
Татарстан туфрагы.
Буыннарның моңы калган,
Оныкларың отып алган
Татарстан туфрагы!

Көлсу туфрак та ярсу туфрак —
Татарстан туфрагы.
Сабан ярган, уклар яуган,
Күкрәгеңдә утлар янган
Татарстан туфрагы!

Татлы туфрак та ачы туфрак —
Торган җирем туфрагы.
Яңгырлар вә күз яшь яуган,
Гел язларга карап барган
Татарстан туфрагы...

Сиңа күчкән ата-анамның
Җиңел булсын туфрагы!..

*1971*

## *Сугышка экскурсия*

### I

Илем барлый кабат байракларын,
Чормалардан төшә комач төргәк.
Җиңү язы! Сафлар уза гөрләп,
Төгәл басып елтыр аякларын.

Сафлар инде тыныч атласыннар,
Каберләргә чәчәк исе сеңгән;
Кояш булып комач байрак менгән
Үлем фабрикалары капкасына.

Стенада — мемориаль такта.
Бүген алар җирдә музей гына...
Килмәделәр яшьләр кызуына! —
Туды алар сугыш үлгән чакта.

### II

Экскурсант булып килдең син дә,
Тыныч ызаннарда чәчәк атып.
Сугыш җиргә үлем чәчкән вакыт
Анаң карынында идең илдә.

Гаепләмим сугыш күрмәдең дип, —
Ул мәҗбүримени гомер өчен?
Бу фикергә әле килер өчен
Аның барын хәтта белмәдең бит.

Сугыш күрмәдең, дип гаепләмәм,
Тик көнләшәм синең язмышыңнан.
Дөнья азмы «дәрес» алды шуннан,
Һәм безне дә ул фән сай итмәгән.

## III

Яңа буын йөри музей карап:
Китәселәр — киткән, эзен салган...
Музейларда эзе генә калган,
Сугыш үзе түгел, экспонат.

Ул йозакка әле бикләнмәгән.
Ул вакланып тормый вак эш белән.
Илләр белән уйный, язмыш белән,
Нәфесе дә аның чикләнмәгән...

Йөнтәс куллар сөенә алтын санап:
Адәм каны хәйран табыш бирә!
Җир читеннән сиңа тавыш бирә,
Сугыш әле түгел экспонат.

## IV

Син күрәсең барын (түгел күзсез;
Күзсезләр дә биредә яхшы күрә,
Бар да биредә тып-тын шуңа күрә),
Син аңларсың биредә барын сүзсез.

Сугыштан соң туган тынлык түгел, —
Сугыш хәзер тирән тавышлана,
Канда йөри, яна, сагышлана!..
Мең нәфрәтләр белән кайный күңел.

«Күрсәтәсе иде үзләренә
«Иҗатларын!» — шулай хәтер дәшә,
Мең корбаннар, озатып кабергәчә,
Карасыннар иде күзләренә...

## V

Көнчыгышка очкан штандартлар*
Музейларда уяу тора:
Әй җилферди әле хыялларда
Көнчыгышка җырлап очкан чаклар!

Капкаларда, рейх җыры булып,
Тирбәлүләр ефәк тавыш белән!
Гөмбәзләргә менү алкыш белән,
Империяләргә тугры булып!

Җир йөзендә тора шундый чаклар,
«Байракчылар» әле йөри анда.

Ятса ятсын болар музейларда,
Сафка керә яңа дубликатлар.

## VI

Иезуитлар яңа элмәк сайлый.
Ә биредә зәңгәр күзле кызчык,
Куенына таш курчагын кысып,
Пушкаларга төртә: «Бу нәрсә?» — ди.

Эшафотка ымлый: «Әй, таган бар!
Әйдә, әткәй, әйдә, атынyйк без...» —
«Бер аңларсың әле, алтыным, түз, —
Атынганнар анда, атынганнар...»

Күзләрен ул яшерә нарасыйдан...
Салюттан соң туган яңа токым
Беләме соң әле дарлар халкын?..
Әйдә, сеңлем, гөлләр арасына!

* Фашист байраклары.

## VII

Китик әйдә, калсын полигоннар,
Китик, якты җырга киткән сыман.
Күрелмәгән чорга җиткән сыман,
Кочагына алсын киң болыннар.

Ак болытлар йөзсен күзләрендә,
Дулкыннарга кара, якты суга.
Җир куеныннан кояш яктысына
Яшел дөнья шаулап күтәрелә.

Колакларда әле тавышы тора,
Сугыштан соң ничә еллар узган...
Әйтерсең лә гүли бомбовозлар, —
Үләннәрдән чыга төклетура.

## VIII

Оча трасса үткән вакытларга,
Сыза тургай язын ялкынланып.
Ә каршыга иген дулкыннары
Күтәрелә иске окоплардан.

Трасса оча сугыш эзе буйлап,
Бормаланып кирә күңелләргә.
Туктый-туктый бара гомерләргә,
Шәүлә уза Кеше йөзе буйлап.

Аерыла дөнья ике якка,
Аерыла сугыш ызанынннан.
Өр-яңа бер буын уза моннан,
Туган җирем хәтере, синең хакка.

## IX

«Онытма!» — дип кирт син маңгаема,
«Хәтерлә!» — дип, кабат башка тукы;
Һәм язуын ташның биш кат укы, —
Җир, хәтерең күчсен малаеңа.

Мин хәтерле булыйм синең кебек,
Синең кебек зиһен артсын миндә;
Хәтер гөлең чәчәк атсын миндә, —
Мәрхәмәтле булыйм илем кебек;

Елгаларың үргә аксын миндә,
Үткәннәргә кайтыйм җилең кебек.
Мин хәтерле булыйм синең кебек,
Җир, хәтерең күчсен малаеңа.

*1965*

## Фаҗиганең асылы

...Очраклы фәлсәфә түгел...

*Вольтер*

Җилләр шаулап торган сахрада,
кылганнар да качкан буш чүлдә
ак таш төсле ята баш сөяге,
күләгәләп комны эсседән...

Эзләре юк.
Кем булган ул? Килеп соңгы урынын
тапкан сары сахра эчендә...

Элек чиксез офыкка төбәлгән,
бу бушлыктан чыгар әмәл эзләгән
күзләренең кара суы
комнарга беткән сеңеп...

Һаман шулай офыкка багып калган
күзләрнең буш оялары —
мәңгелектән ярдәм сораган кебек!

Хәзер инде тарихчылар әйтсеннәр:
чыккан булырга тиеш, дип, бу юлчы Фәссәннән...

Археологлар әйтсеннәр: сәмум җиле искәндә
егылгандыр бу адәм...
Багучылар әйтсеннәр: булгандыр изге җаннан, —
еллар үткән, комнар күчкән, әмма
җәсәден, дип, комнар күмә алмаган:
күзсез башым булса да,
җир өстендә ятсын, дип,
ялваргандыр Алладан!
Социологлар әйтсеннәр:
ташлаган, дип, юлдашларын,
идеалист! — дип,
үзе генә омтылган, дип, кыйбласына!
Андыйлар гел ялгызлыкта
югалта башларын!
Сәнгать әһелләре әйтсен:
бу кеше, дип, тапкан үз ролен,
кабатламаган бүтәннәр юлын!
Язмыш сәхнәсендә, соңгы сәгатьтә
ышангандыр, диеп, сәнгатькә:
ялгыз Гамлет бөек монолог сөйләгән
кулга тотып, олылап баш сөяген!

Оптимистлар әйтсеннәр, ниһаять:
яшәргә, дип, теләге булган көчле —
шуңа да бит комнар диңгезеннән
өстә калган кеше!

Сары ком дәрьясын җиңеп,
җигеп бөтен көчен,

омтылгандыр фикер тулы бу баш,
миен кайнатса да кояш,
кешелеккә Табигатьнең
серен ачар өчен!

Чүл-япанда япа-ялгыз калганда да,
хыялында эзләгәндер үз Мәккәсен...
Шагыйрь әйтсен: охшаш аның язмышына,
үз йолдызын эзләгәндер,
булган харап...
Уйлый шагыйрь: буш «чүлмәккә» карап
инде ни әйтәсең?

Фаҗиганең асылы андамыни —
шагыйрь өчен зур фаҗига
үлүдәме, комнар күмүдәме?
Гаҗәпләнермени тарих аның җансыз гәүдәсенә,
бер сөям җирне чүлләр
кояшыннан каплап торган
баш сөяге күләгәсенә?!

Фаҗига, бөек фаҗига менә шунда:
бөек максат белән чыгып озын юлга,
күзләр дымы кипкәнче карап үз офыгына,
тормыш мәгънәсенә,
ком таулары, вакыт сахралары аша кичеп
барып җиталмаган Юлчы
үз Кәгъбәсенә!*

*1974*

* Биредә: максатына мәгънәсендә.

## *Бурыч*

Рәхмәт, илем, имин иртәң өчен,
җылы урының, назың-иркәң өчен;

дүрт фасылың, яңгыр-карың өчен,
синдә үскән сөйгән ярым өчен;

табындагы ипи-тозың өчен,
синдә тапкан үз йолдызым өчен;

өлешемә тигән көмеш өчен,
ерак, якын таныш-белеш өчен;

өстәлдәге кәгазь-караң өчен,
көрәшеңдә алган ярам өчен...

Иң зур бурыч алдым үзем өчен,
ышанып әйткән җылы сүзең өчен —

ишетмәде бугай аны беркем:
«шагыйрь» дидең бит син миңа беркөн!

*1980*

* * *

Тирә-ягым ап-ак юрган — бу кай төш?
Моңа чаклы күргәннәрем булган — төш...

Торып чыксам, и, ни күрим, тышта — кыш!
Борчылмагыз, барыбызга җитә эш!..

...Яна учак — утын чиме — чыш та пыш.
Узган гомер, үкендерми искә төш!..

Менә көрәк — бусагаңа килгән эш,
бер чараң юк, кирәк бүген — тизләнеш!

Кыш-оккупант, булыр сиңа бездән — эш;
ашыккансың, әмма көтмә тезләнеш!

Әнә бүкән, менә балта: эшкә — эш!..
Дәшми генә допрос ясый миңа Кыш...

*1990*

* * *

*«Зең!» шигыре уңаеннан Ләискә*

Иртүк торып таң каршына чыксам,
бакчадагы алмагачлар баш иделәр,
барысы дәррәү: «Зең!» — диделәр.
Лаек булдым алмагачлар сәламенә!
Шулар менә кодрәт бирде каләмемә.
Чияләрнең ак таҗлары
зеңләп оча куаклардан...
Җитез җилләр әйтте зеңләп,
син булгансың бу якларда:
чыклар булып тама әйткән сүзең,
бу бакчадан кайчан чыктың үзең?
Аккан суда чагыла йөзең, күзең...
Зең!..
Күк чәчәкләр чайкалалар,
зәңгәр бәллүр зең аларда...
Нинди хикмәт: бу яз тоташ
зеңләү тора һаваларда!
...Минем — Зең! студиямдә
Төклетура языла тасмага.
Күк күкрәүләр, үлән шавы, җил тавышы,
кызлар кер чайкыйлар басмада...

Табигать фонограммасы!
Бер поэма яздым.
Исеме «Зең!»
Каләм көйле чаклар, шөкер.
Яз йә көзен
Җыр Бакчама
килеп чык ү-зең!..

*1997*

## *Сурәт*

...Сай инештән өч дус Эт балыгы
Төшеп килә Олы тугайга...
Шадраланып китә су өсләре
Җилләр исеп киткән уңайга!..

Җыелалар бар балыклар бергә,
Төрле «милләт»: чабак, ялтушлар...
Кармак сабына куна Җилпәз канат,
Канатында яна бар төсләр!..

Кайный тугай! Үтә күренә суы:
Монда Чуртан — тугай түрәсе!
Бар инешнең балыгы җыела бугай,
Корылтайларыдыр, күрәсең.

...Диварымда түгел, күңелемдә
Туган яктан килгән бу рәсем!
*2003*

* * *

*Шәриктәшем Ләбиб Айтуган ядкәре*

Син бар ул, Айтуган,
Күгеңдә Ай туган.
И нәни Моцарт син,
Моңнарга бай туган!

Сау безнең мәгарә,
Мәгърифәт бар бит ул.
Мәгарә, мәгърифәт
Мәгънәдә пар бит ул!

...«Иптәшләр» урамы
(«Общага», кәнишне),
Син җыя идең бит
Үзеңә бар ишне.

Мандалин кыллары
Иркәли кояшны...
Син киткәч, дускаем,
Моң басты бу башны!..

Җырлады, елады
Мандалин кыллары...
Шул көннән яңадан
Күрешеп булмады.

Шул көннән эзлим мин:
«Айтуган, Ай-ту-га...ан!»
Хәтерең көненә
Җыела бар туган.

*1968*

## *Сары көчек*

Әче таңнан, урам кичеп,
тәгәрәп чыкты сары көчек.
Йөгерә-өрә, өрә-йөгерә, —
талантлы ул әнә ничек!

Өрә җилгә, әллә кемгә,
чит-ятларга, туганына, —
үкенмәслек булсын дипме
көчек булып туганына?

Йөреп өрә, йөгереп өрә,
бии-бии, ята-тора!
Дөньясында бер гаме юк
адәмнәрне шаккатыра!..

Борчак кеби, борча кеби,
бик бәйләнчек нәмәкәй ул!
Дәү үсмәгәнлектән генә
бәләкәй ул!..

Нигә аңа «көчек» диләр, —
үзенчә бик эре бит ул!
Ныклап торып ачу чыкса,
бүре бит ул!
Җаны чыкмаганга гына
тере бит ул!

Ә бүген ул өреп туймый,
әллә чынлап,
әллә уйный...

Әйтерсең дәү эш майтара, —
чаң-чаң килеп өрә, зәһәр!..
...Таш бәгырьле салкын шәһәр
ишетми дә үзен, каһәр!

Бөтен шәһәр кубар иде,
кеше өрсә шулай әгәр!..
Әле ярый сирәк була
кешеләрдә андый хәлләр.

*2003*

## *Дәрдмәнд көенә*

*(Парафраз)*

Үтте еллар, үсте сакал,
Еллардан җим күрмәдем.
Пәрәвез җепләре буйлап
Үрмәләүне белмәдем.

Үтте гомер, узды кавем,
Эчтән-тыштан җил өрә.
Җан-яфракның калтыравы
Менә ул шуңа күрә!

Эчтән — ыштан, тыштан — дошман, —
Басканнар аягүрә!..

*2003*

* * *

Үтә еллар,
Ага сулар,
Утлар сүнә
Яздылар...
Сулар ага,
Арта бара
Йөрәктәге
Язулар.

Ташка уйган,
Имза куйган
Язуларны
Җил ашый.
Йөрәгендә
Илен йөртә
Еллар кичкән
Ир башы.



## *Киткәннәргә гимн*

...Әмма без җиңдек.

*Һенрих Һейне*

Борчылмагыз, яшел киңлекләрдә,
Яшел калкулыклар төбендә
җир шавыннан киткән дус-ишләр!
Зәңгәр коштай җәеп канатларын,
барчабызның хәтер күгеннән
тыныч җиргә иңә бу кичләр!

Һәр иртәдә календарьдан бер бит
өзеп алу — һаман шул бер гадәт.
Көн әйләнә, кояш — шул һаман!..
Кояш асларында йөргән чакта,
исемегезгә сөю һәм сәгадәт
без булырбыз — сезгә юллаган!

Борчылмагыз, калды, диеп, өстә
ярты эшләр, иҗат, бирәчәкләр,
алгы көнгә дигән хыяллар...

Шул ук эшләр җирдә — сез кабызган
чор ялкыны бара Киләчәккә:
Вөҗдан уты, Хәтер — уяулар!..

*1973*

## *Ватан сугышында булганнар*

Карт солдатка сулышын өрә һаман
кырык бернең салкын кышлары...
Ватан сугышында булганнарның
акрынлап
чыга
очлары...

Сөйли агай: иртә җикте дөнья,
сабан тотып билләр язылды.
Калды язым ерак Сослангырда,
калды язым...
окопларга күмдем язымны!..

Нәрсә калган инде — офтандырып,
тәрәзәгә килә ул язлар?..
Килә кебек... кайсы вакытларда...
окоплардан
япь-яшь авазлар!..

Мөнәҗәтләр әйтә төнге җилдә, —
тынгы белми бер дә карт тирәк.
Туган туфрак өне дәшә бугай:
«Батырга да, — диеп, —
ял кирәк...»

Олы безнең һәрчак Ил-йорт хәтере:
шәфкатьле ул ятим, толларга...
Салынмаган хатлар килә һаман,
килә күченеп елдан-елларга!..

Ишетелә кебек, кемне эзләп,
еллар аша
пуля очканы...

Ватан сугышына кергәннәрнең
акрынлап чыга очлары...

Сугыш! Сугыш! диеп, күп сөйләнде.
(Сугышканнар белән булышма!)
Безнең рухны изеп үтәлмәде
миллион тәгәрмәчле Сугыш та!

Ватан сугышлары... Күп инде ул,
саный китсәң, безнең туфракта.
Ватан сугышы — атаң сугышы гына
түгел бит ул —
сузыла еракка!
Туктаргадыр, бәлки? Стоп-кадр!
Хроникаларның тасмасын
өзәргәдер шул еллары белән:
киләчәккә аяк басмасын
Сугыш-гыйфрит!
Ап-ак экраннардан
инвалидлар йөгереп чыкмасын,
таралмасын сугыш авазлары,
нарасыйлар изрәп йокласын!

Сугыш күрми язган шигыреңне, энем,
соңгы кабат яз да нокта куй.
Тик... хәтердә сакла... гүреңәчә.
Нәфрәтеңне янган утка кой!..

Каты әйтсәм, үпкәләмә, нәнә, —
И, истә соң салкын кышлары...
Ватан сугышында янганнарның
акрынлап
чыга
очлары...

*1980*

## *Җиңү көне*

Медальләрен тага бүген бөтен ирләр.
Яңаралар
хәтерләрдә
кан коелган бөтен җирләр.

Йокыларында күрсенә
Яраланган калкулыклар, үрләр...
Музейларда
кылычларның корыч йөзенә
бәреп чыга
салкын тирләр!..

Уйчанланып
кызара офыклар,
тын калалар кичләр...


Бер минутка иңәләр
тигезләнгән бөтен окоплар.
Тынлык!
Җир йөзендә
Җиңү туган вакытлар!
Батырлар да бүген түзми,
Әйләнеп куялар ерак кабердә...
Медальләрен тага бүген бөтен
ирләр...

Кайберләрен бүген
пуля түгел, —
ега
кургашындай
хәтерләр!..

*1979*



# Тәрҗемә үрнәкләре



Пабло Неруда

*(Чили шагыйре)*

## *Чилига кайту*

Туган ил! Минә кабат
язмышыма кайтам, —
димәк, сиңа —
төрле телләрдән,
төрле илләрдән,
шаулы урманнардан,
шаулы калалардан —
сиңа:
ниләр күрсәм, —
күзләрем бәбәгендә саклыйм аны,
нәрсә тотсам, — учларымда саклыйм аны,
ишеткән һәм белгән хатирәне
вакыт яза
җыерчыклар чөйязмасы белән
маңгаема уеп,
тамга куеп...
Һәрчакны мин сиңа кайтам —
олыгаеп та, яшәреп тә:
яшәрәм сөюдән, кайнар мәхәббәттән;
олыгаям: бу мәгълүм, билгеле,
чөнки ашый мине
сәгатьләр, атналар, айлар,
календарьның рәхимсез тешләре...
Чит җирләрдә ниләр очратсам да,
кайтарам да
синең аяк асларыңа җәям,
синең чәчләреңә кадыйм, —
сиңа, кадерле, назлы Илем!
Мин кешеләр арасында йөрдем,
шаулы базарларны күрдем,

фикерләр һәм ташлар җыеп,
урамнарны гиздем,
чәчәкләр өздем.
Сине мин көчлерәк яраткан саен,
син мине ныграк сөйгән саен,
син баерак була бардың миңа.
Үзем эзләп тапкан,
кешеләр бүләк иткән хәзинәләрне —
барысын да сине бизәү өчен генә
тупладым мин, газиз илем,
сине җырлау өчен,
зурлау өчен газиз җир кисәген...
Кая барсам, анда мине
дуслык, назлау һәм мәхәббәт
көтеп алды.
Кая барсам,
зур мәйданнарда
кайнар үбүләр,
җырлар, күбәләкләр сипteләр котлап! —
мине яратып,
димәк, сөеп сине...
ә мин җавап бирә идем:
«Күрегез, мин бүтән юк инде, — дип, —
кагыласыз икән миңа,
назлыйсыз икән мине,
димәк, сез назлыйсыз
минем илне,
мин үскән җирне...»
Бу — ярату, Чили,
синең зәңгәр дәрьяларыңны,
юлдагы җырларыңны,
хәтта кырдагы чакматашларыңны!
Минем җырлар аша чит-ят күзләр
синең җирне, синең далаларны
күзәтteләр,

Ариканың сары толымнарын,
сагышлы Антафагастының сары йөзен
балкытып үтүче
төнге корабларның йолдызлыгын;
шулар белән бергә
куе шәмәхә төстә
янып торган виноград куакларын,
җир һәм диңгез төбендәге күмер тавын;
ә аннан соң яшел районнарда
кояш сугарган бодай массивларын...
Синең хакыңда,
язмышлар һәм гомер хакында
рәхәтләнеп, ихлас җырладым мин...
Синдә беркем хәрәкәтсез тормый.
Минем халкым — димәк, хәрәкәт.
Минем Илем — юл ул!
Туган җиремә шундый
кичерешләр һәм җырлар белән кайтам,
белеп кайтам
ниләр көткәнен...
Бу хисләрем өчен
ниндидер министр
мине антипатриот дип атар, бәлкем;
бу — ахмаклар өчен җитә калыр...
Бер газета күсесе,
каләмен үткә манып,
«Эль-Меркурио»да минем исемемә
һәм эшемә
пычрак ягар, бәлкем;
кайчандыр мин сүз һәм икмәк белән
ярдәм иткән,
ә хәзер данга сусаган яшь кеше,
шартлар чиккә җитеп әйтер, бәлкем:
«Аның тере җырларына каршы
үлеләрне күтәрик кабердән!..»

Әнә шулай
минем күләгәм күләгәсендә
сугарылып,
көнчелекнең болганчык дулкынында,
агулы тирәк үсәр, бәлкем?..
Ярый, кичер мине, йә, кичер, Илем,
бу лавр бәйләмен
ераклардан Сиңа китергәнгә.
Әгәр бу да кирәк түгел икән,
күм син аны,
якты, зәңгәр киңлекләреңә,
тик анда да
байракларың төбенә күм, яме!
Син уйларсың, бәлкем,
дөнья күрмәгән, дип,
яки capларсың авызны минем;
һәм, беркем дә ишетмәслек итеп,
тавышымны томаларсың, бәлкем...
Тик сайлыйм мин
шундый көрәш юлын:
бары туган халкым, Илем хакына гына
башланмаган Сөю,
кул тимәгән
Бәхет телим!..

*1968*

Витезслав Незвал

*(чех шагыйре)*

## *Пәке йөзенә*

Тагын бер яфрак өзелер, —
бу инде... көз булыр.
Төшләремә алма тоелыр каты, —
ә бу инде — картлык...
Картаермын тулы бер гомергә,
танымас, шәт, мине
беркем дә!..

*1960*

Константин Ильдефонс
Галчинский

*(поляк шагыйре)*

## *Кичке сөйләшү*

*(Диалог)*

— Сөйлә миңа,
мине ничек яратасың?
— Тыңла, сөйлим алайса соң:
кояш уйнаганда йөзләреңдә ялкынланып,
көяз эшләпәңдә, гөлдән үргән такыяңда,
концерт залында йә юллар тузанында —
очкын чәчкән күзләрең гел күз алдымда;
йокы катыш, иреннәрең төнен нидер
дәшкән чакта,
ак күбеккә батырып кулың, эштә тирләп пешкән чакта,
таксида һәм бульвар эскәмиясендә,
чатларда, тыкрыкларда, елмайганда берәрсенә,
оялганда, чәч бөртегең бармагыңа чорнаганда,
хәвеф-хәтәр синә кайгы юраганда,

чәкчүрләрдән, яланаяк, тауларда һәм диңгезләрдә.
Бүген. Кичә. Төннәрен һәм көндезләрдә,
язын, безгә карлыгачлар кайткан чакта...
— Ә җәйләрен?
— Кызу җәйнең үзе кебек.
— Ә күзләрен, өй түрендә җил сузганда сагыш көен?
— Сөям, хәтта күзгә яңгыр
җирне ялгыш онытса да...
— Көмешләтсә тәрәзәне кышкы көмеш?
— Ә кышларын — ялкын кебек. Якын килеш
ике йөрәк тибә бездә. Яз да, көз дә...
Тәрәзәмне кар караулый.
Һәм каргалар кар өстендә.

*1960*

Эдуардас Межелайтис

*(Литва шагыйре)*

## *Налоглар җыючы*

Вак чиновник Мигель Сервантес де Сааведра 1590 елда корольгә тәэсирле бер үтенеч кәгазе тапшыра. Сервантес үзен хәзерге Боливиянең башкаласы Ла-Пасның налоглар җыючысы, ягъни коррехидоры итеп билгеләвен үтенеп сорый. Шәһәр ул чакта алтынга байлыгы белән шөһрәт тоткан була. Ә бу мескен исә акча эшләп бурычларыннан котылу һәм кешечә яшәү турында хыяллана.

Ләкин Ходай һәм король бурычка баткан чиновникны кызганмый. Сервантеска бурычлары өчен төрмәгә керергә туры килә. Эч пошудан алҗыган әлеге бичара үзе кебек икенче бер бичара — Дон-Кихот һәм аның корал йөртүчесе маҗаралары турында китап яза.

1960 елда Ла-Пас муниципалитеты Мигель Сервантес де Сааведраны шәһәрнең мәңгелек коррехидоры итеп билгеләү турында карар чыгара. Бу юлы Мадрид мәрхәмәтлерәк кылана: Ла-Паска Сервантесның бронза фигурасын җибәрәләр. Ниһаять, ул теләгенә ирешә!

* * *

Испан короленнән җирдә соң ни калган, —
ялган китап, җыр һәм әкиятләр янган!

Укучыга кыен җәза — бу хакта,
бер юл булсын, күңелдән шигырь ятлау.
Ятласа да оныта малай кинәт,
моның өчен аңа икеле, димәк!..
Теге исә, монархны калтыратып,
яңагында яшь бөртеген ялтыратып,
учы белән яшереп бер үк вакыт
елмаюын, каһкаһәне туры атып,
саклап кала мәңгелек ике нәрсәне
йөрәгендә: елмаюны, күз яшьләрен...
Шуңа микән онытмыйлар андый затны:
ил буенча эш тапмаган кандидатны
китерәләр (бронзадан!) юбилее датасына:
алтын җыйсын, диләр, кайтсын да Ла-Пасына!
Хәзер шундый алтынны алган җыйнап:
каберендә ыңгыраша галиҗәнап!
Җый, әйдә, көрә, налогчы, барын да, —
исән чакта җыя алмаганнарын да!..

Марис Чаклайс
*(латыш шагыйре)*

## *Кант кабере*

### I

...Күз дә кысмый дөньяга
җимерелгән собор. Тугыз ярыгыннан
исә җил, кая барып сугылырга белми.
Җил — чәчүче. Ни игә җил?
Менә бу сөрү ичмасам! —
ләхет чокырлары, гусеница буразналары.
Сугыш кыры. Каралаучы*.

* Кенигсбергның латышча иске атальшы. Хәрефкә-хәреф — сугыш кыры.

## II

Зират тәресендә — карга.

## III

Карганың бөек мәнфәгате:
Кар-р!

## IV

— Ә шулай да, — дим каргага, — күрәсеңме,
сөрелмәгән, сугыш кагылмаган
Кант кабере.

## V

— Очраклылык, кар-р! Тагын шундый
тик бер генә сугыш — каберләр дә,
син дә, мин дә юк булырбыз, кар-р!
Иң яхшы дигәндә дә кешелек
оялыр үз үткәненнән.
Фикер ияләре, кәгазь буяучылар,
җирдә акыл сатучылар
кая олактылар, кайчан
дөньяны коткарып булганы бар?
Кар-р!..

## VI

Юк,
бер чеметем мәет көлен каплап
яткан бу таш кантары түгел,
авыр фикер, очкан кошның җиңел күләгәсе,
биек болытлар —
аның кабере!..

*1987*


Максим Танк
*(белорус шагыйре)*

* * *

Җиргә яфрак коелганда,
җылы якка киткән чакта,
калдыралар кошлар әрәмәдә
үзләренең язгы җырларын, —
чит якларның сүрән күгендә
югалтудан куркып аларны.

Шуңа күрә агач тармаклары
талгын гына тирбәлдерә
үксез калган ояларны,
һәм аларда, бишектәгедәй,
йокыга талган җырларны,
хыялларны,
бөтен сайрауларны,
сызгыруларны,
яңгырауларны,
гүләүләрне,
бөтен шавын
урманнарның!..





# *Поэмалар*



## *Зәңгәр көянтә*

*(Чын легенда)*

Ташка басып иелә-сыгыла су алганда,
көянтәсе чишмә җырын тыңлый иде.
Кыз иңендә тибри-тибри кайткан чакта,
пар чиләктә пар бәхете чыңлый иде!
Пар чиләктә Ай чайкала, Ай чайкала,
көянтәсе кызга кушылып җырлый иде!
Сыйган иде пар чиләккә йолдызлары...
Бер көянтә, чайкалдырып,
алып кайта —
бар дөньяны!

Әле ярый, җирдә булган чишмә юлы,
чишмә юлы — кавышуга тик бер сәбәп...
Көянтә юк, чиләкләр юк — яшь сылуың,
эңгер төшкәч, суга диеп
киткән сәгать...

* * *

Рәхмәт сезгә,
җирдә барлык көянтәләр,
рәхмәт сезгә, пар чиләкләр, —
кыз баладан!
Язгы вакыт — күкләр җиргә гашыйк вакыт, —
кавышырга көянтәләр кузгалалар.
Юкка гына, тиз кайтыр, дип көтә ана!
(Бу аналар һәрвакытта кызганалар!)
Ние гаҗәп: язгы вакыт — назлы вакыт, —
унсигездә
кузгалалар
кыз балалар!..

* * *

Кичке эңгер... Тик ул чыкмый. Көтмә җырым, —
көянтәсен сөяп куйган коймасына.
Мин язачак шул көянтә тып-тын гына
ничәнче ел карап тора кыйбласына;
карап тора үткәннәрен, чишмә юлын, —
пар чиләкне чайкалдырган йомшак иңнәр
кагылганын тоя кебек, вакыт-вакыт
кагылып үтсә
язгы җилләр,
назлы җилләр!..

* * *

Көянтәләр, сиртмә төсле чайкалдырып,
су китергән авылымда һәр өйгә дә...
Көянтәсен иңнәренә салу белән,
сөю язы кукрәп килгән
Фәридәгә!..
Аны гына читләп узмас язгы шаукым,
аны гына читләп үтмәс чишмә юлы...
Таң сулары чайкалдырган, чайкалдырган
тал шикелле нечкә буен, зифа буен!

Асылмалы күпер сыман шул көянтә
кавыштырган Фәридәне
Хафиз белән...
...Көянтәсен калдырды да китте Яшьлек!
Су юлында, суга сусап, андыз шиңгән...

* * *

Су юлларын айкап эзлә яшьлегеңне, —
чиләгеңне, көянтәңне тот кулыңа!
Тормыш юлы — чишмә юлы түгел икән,

килде гүя су юлыннан —
суд юлына...
Сәбәпләрен сорама син, узган инде,
гомер узган, моңа өстәп ни әйтәсең?!
Шул коймага сөялде дә карап калды,
калды аның, калды зәңгәр көянтәсе;
калды аның пар канаты, пар канаты,
һәм мәхәббәт күперләре калды гүя!..
Йомшак иңнәр кагылганын тоя кебек,
җил кагылса, шул көянтә —
җанлы гүя!..

* * *

Ишегалды тып-тын тора, тып-тын тора.
Чыкты Хафиз
һәм бүкәнгә
чапты балта!
Чират житте көянтәгә, —
бер кизәнеп,
көянтәне чабып атты
кыл уртага...

Тукта, кеше!
Хуш, көянтә,
хуш, легенда!
Шулай укмы кыска булды синең юлың?..
Синнән бер дә аерыласым килмәде дә —
нишлим инде — шунда сынды минем җырым!..
Теләгеңә ирештеңме, булды, егет,
булды, кеше, бар да булды, —
канәгатьлән!
...Ут юлларын айкап килде соңгы аваз,
соңгы сәлам, соңгы каргыш мәхәббәттән!

Ә ут гүя кызыл бүре,
кызыл кыргый —
ашый җанны ыргый-ыргый,
талап-талап...

Күз алдымда калыр минем
ут эчендә
Мәхәббәттән каерылган
ике канат!

*1962*

## *Таң шәһәре*

*Түбән Каманың яшь төзүчеләренә*

...Мең ел аша сезгә эндәшәбез,
үлгән шәһәрләр,
сезнең тавышыгызны
археологлар
төптән күтәрә!
Мең ел аша
кайта алиһәләр,
йөзләренә
елмаюы каткан таш булып.
Кара туфрак,
бар да сиңа төшә, —
актаралар сине, күмәләр.
Күмәләр дә тагын актаралар,
әби патша балдакларын табып,
археологлар:
— Ха-ха! —
көләләр...

Музейларга керә империя.
(Заманында нинди кодрәтле!)
Ватыкларын бәрхет мендәрләргә
куя заман, —
нинди хөрмәтле!
Саркофаглар,
купец комганнары,
таш ядрәләр,
Пугач байрагы,
җиз быргылар,
кояш сәгатьләре...
бит боларны күрү — файдалы
һәр кешегә: җирнең катламнары —
археология —
тарих дәресе!..
Көлә-көлә нәни малай бара:
син бит, малай,
шәһәрләрне таптап йөрисең,
империяләрне!
Әкиятләргә бару җиңелрәк эш.
Әкият үзе килә чын булып...
Ә гүзәллек
тарих катламыннан
күтәрелә,
мәрмәр сын булып...
Әкиятләргә бару җиңелрәк ул,
чыгып киттек мәллә, туганым?
Сөйләп тормыйм сиңа, үзең кара
күңелең белән
шәһәр туганын!..

* * *

— Шәһәр ничек туа?
— Туа шәһәр

кеше йөрәгендә иң элек;
аннан, төне көнгә ялганганчы,
өстәленә утыра
иелеп!..
Сыза-боза,
аннан нивелирлар,
окулярын турылап кояшка,
урамнарны сыза...
Проспектлар
күзләр белән сызыла
иң башта!..
Шәһәр ничек туа?
Экскаватор
Алып чүмече белән
туң туфракны ала каерып,
аннан — самосваллар чабыша башлый,
һава белән җирне аерып
кара монда!..
Шәһәр юк әле.
Ләкин исеме бар!
Һәрбер ана
карынында йөрткән чагында ук
сабыена исем кушкандай,
япан кырга язу кагыла:
«Биредә — шәһәр булыр!»
Тудың икән — исем табыла!..

* * *

Диварлар юк биредә, таш диварлар,
син, рәхим ит:
ачык — дүрт ягы!..
Кояш хуҗа монда һәм Азатлык,
һәм шуларга кушыла
җыр тагы!..

Диварларсыз гомерлеккә түзәр, —
мәңгелеккә чыкты сәфәргә.
Эңгер туса,
кояш хәбәрчесе —
таң җилләре килә
шәһәргә!

Рәхмәт сезгә, утлар,
әле сез бар,
рәхмәт, шырпы,
давыл каршында,
япан кырда синең белән булдык,
таңга каршы өмет каршылап...
Кар өстендә янды калориферлар,
утлар янды, утлар сүрелде.
Таң алдыннан,
зәңгәр мираж булып,
күзебезгә
шәһәр күренде!..
Миражмы соң?
Бу — проект икән,
архитектор көлә каршыда:
— Шәпме, малай?!
Тагын дистә елдан
шундагыча булыр — барысы да!
Төн килүгә кердек вагоннарга,
көртләр ярып, кардан юл эзләп...
Күз йомылгач,
алып китте безне
тавыш-тынсыз гына поездлар...
Хыял шәһәренә!..
Баш очында
симфония уйный ак буран!..
Биш минуттан сызылып төшкә керде

ап-ак шәһәр,
анда —
ак урам.
Таң шәһәре!..

* * *

Биредә зарланмый беркем дә,
зарланырга чөнки юк урын:
«тузанлы» дип, кемнәр бәйләнсеннәр,
шәһәр тумас борын?..
Кемгә зарланасың, —
тик үзеңә,
чөнки аны үзең төзисең!..
Үз-үзеңә дошман булмас өчен,
дус булырга
юлын эзлисең
хезмәт белән...

Менә — «автовокзал». Юл чатында,
чемоданнар өстенә утырып,
юл көтәбез,
күзләр — офыкта...
Машиналар кояш чыгышына
оча, оча!
Шофер исә
ашын оныткан...
Дүрт ягыбыз — кыйбла!..
Ә каршыда —
зәңгәр таң-диңгездә
ап-ак айсберглар сыман,
яңа йортлар калка, —
киләчәкнең адресаты!
Бу —
яңа заман!

Нәкъ җидедә, нәкъ иртәнге җидедә
гөл тибрәлде
самосваллар җилендә.
Исте җилләр, күтәрелде офыклар,
корыч куллар
кагылып китте
болытка...
Нәкъ җидедә эшче куллар берләште...
Нәкъ җидедә, нәкъ иртәнге җидедә
кран белән
күтәрделәр —
Кояшны!

* * *

Саумы, шәһәр!
Карлар эчендә
туңмадыңмы?
Нихәл!
Ак яу булып карлар килә сиңа,
проспектларың буйлап чаба,
тулгана...
Җил: тугыз балл!
Ора күкрәгеңә —
чыда!
Каеннарың саумы,
сеңелләрең?
Язны төштә күрә бугай
сиреньнәрең?..
Таныйм сине.
Белә идем сине бишектән.
Тора иде җилләр уртасында бер йортың.
Тонык кына яна иде утың,
чакырып
булачак шәһәр кешеләрен,

үзен төзүчеләрен...
Әйе,
утыра иде калкып бер йортың —
архитектор өстәлендә
бер ак шакмак!
(Өстәлдә —
рафинад шәһәр!)
Өстәлдә — яшелгә буялган каеннар.
(Җил юк өстәлдә!)

Җеп-рельслар
трамваен көтә...
«Мәйданда» нәни чуерташ.
(Бу — булачак һәйкәл
синең төзүчеңә!)
Бүген
Сиңа керәм, шәһәр.
Узам түреңә:
гүя күренә макетың
зурайткыч пыяладан.
Бу — син?
Нәкъ шулай идең
минем хыялымда!..
Ә чынлыкта...
чакрымнар һәм еллар аша килә
яшь шәһәрнең
беренче трамвае...

*

Барысы да — безгә!
Бу ярлар да, болыннар да,
үзәннәргә тулышып аккан җил дә,
якты минутлар да, сагышлар да,
якынлашып килгән
зәңгәр кич тә...

Скептиклар әйтсен:
«Кала бар да —
        Янып сөйгән яр да,
        тал да, гөл дә,
        йолдызлар да,
        яңа калалар да...»

Калсын!
Офтанмыйбыз һич тә.
Бүген бездән
калулар түгел,
калдырулар турында
яңа җыр тиешле
яңа заманга!..

*

Калдырабыз төзеп ак шәһәрләр.
Диварлары — пыяладан, мәрмәрдән;
эчләренә тула ал таң!..

Калдырабыз
сезгә атап —
адресаты киләчәктәгеләр!
Нигезе аның — иске нигез —
уртак Ватан!

Иданнәрен, бәхетле парлар йөрсен, дип,
шомартып тигезлибез;
тәрәзәләрен сезнең якка, гел яктыга —
йолдызларга төбибез!

Түбәләрен ябабыз
гел якты уйлар белән —
башлары гел
биек йөрсен дибез!

Еллар түренә кереп ерак китәр
безнең куллар салган нигез!..
Юлыгызга, ак шәмдәлләр төсле
рәт-рәт тезеп,
калдырабыз ак каеннар
Яшьлек бульварында!
Шаулап торсын алар киләчәктә
яшьлек юлларында!

Кагылганда төнге карлар
Республикам байрагына,
яшь йолдызлар йөрсен сөенеп
Өмет Мәйданында!..

*1964*

## *Йолдызстан*

### I

Безгә чаклы да бит җир уллары
хәстәрләнгән, озак җыенган.
Кызу атылып янган йолдыз сыман,
Коперниклар сүнгән бу юлда.
Галилейлар, Брунолар янган —
безнең көнгә төшкән яктысы.
Инквизитор утларында янып,
фән иткәннәр шуның чаткысын.
Калугада туып, бөек гакыл*
йолдызларга юлны өйрәткән.
Тарихлардан эзләп торасы юк, —
постаменты аның —
йөрәктә!..

---

* Циолковский күздә тотыла.

*

Эшләдекме инде барын Җирдә,
гафу ителдеме ялгышлар?
Лаек улы булдыкмы соң Җирнең,
ишеттекме кайнар алкышлар?..
Таныймы ул безне улы итеп,
гражданы итеп тоямы?
Яңа маҗаралар эзләп кенә
ташлыйбызмы
туган ояны?..
Болытлардан узып менәр булса,
очкыч сыный элек моторын.
Йолдыз булып атылып янам икән,
нуры булып сиңа кайтырмын!
Бу — тикшерү — олы юл алдыннан,
Күкрәгемнең тотып сул ягын...
Имән төсле бертын чайкалдым да
таң җилләрен йотылып суладым...

## II

Вакыт җитте!
Безгә яшь гасырлар
башын иеп
капка ачарлар...
Җемелдәвек планеталарга,
таныш түгел зәңгәр атауларга,
елмаюлы ерак утларга...
— Хәерле юл! —
Җилдә ромашкалар
бил турайтты көмеш чыклардан.
...Безне биләүләргә биләгән Җир
төтен сыман дымга төрелде...

Ерак йолдызларга юллар ачык —
Кабатланмас
старт
биреллде!

*

Хуш, туган җир!
Экрандагы төсле
күренә синең күксел
йомгагың...
Пыялага башын куйган килеш,
сине күзли
сирень куагы...
Ул — пассажир бүген,
әйтерсең лә
Шигърияттән үзе бер вәкил.
Матурлыкны яклап юлга чыккан,
Ассамблеяга гүяки!
Йә, нихәл соң, Җирнең тарту көчен
җиңеп булдымы соң, Сирень дус?..
Корыч кабырчыкка кермәс йөрәк, —
космоста да мин бит синең дус!

Икебез дә бер үк туфрактан без,
максатлар да — бер үк тарафтан...
Минем йөрәк алай бай да түгел, —
сагынган да, бары
яраткан...
Шул ярату, дускай, күтәрмиме
Айга төбәп безнең корабны?!
...Киек кошлар алтын каурыйларын
йолдыз җилләрендә таратты...
Кометалар, метеорлар ява,
Казык йолдыз яна якында.

Галактика дулкыннары кага
иллюминаторым артында!..

О, Җир нинди!
Йомры, өмет төсле
түм-түгәрәк,
тигез — һәр якка!
Койган шарын шулай
мастер карый,
әйләндереп ике бармакта!..

### III

Сабыемны китерәм күз алдыма:
ташлаган да барлык тәтиләрен,
чит бер планетага баскан кебек,
үзе туган җиргә тәпиләрен
саклап кына тидерә ятсынудан.
Без дә шулай. Ят бер дөньяда.
— Сәлам, Йолдызстан!..
...Баш очында
«Җир» исемле бер йолдыз яна!..
Ул үпкәле түгел бугай безгә,
төзелешләрдә ашны оныттык ич.
Топкаларда тере килеш янып,
хәл җиткәнче үзен җылыттык ич!
Бармакларны суык санаганда,
өлеш тиде йөрәк җылысыннан.
Ул кинәнә җылынып без кабызган
Магниткаҗның кайнар сулышыннан.
Кул тимәгән далаларны сөреп
калдырдык без,
юллар ердык бозлы суыкларда,
яз илчесе — яшел кошлар булып,
яфрак кунды шәрә чыбыкларга!

Легендага тиңдәш эзләр уеп,
туңа-туңа бозга басып йөрдек.
Бил тиңентен ап-ак көртләр ярып,
Ил каршына Язны ашыктырдык!
Ап-ак карлар төште, җирне сагынып,
ак бәхетләр җиргә кагынып төште...
Җиргә житмәс йолдыз янып бетте,
сагынудан гүя кабынып көчле!..

*

Офыкларда комач байрак булып,
анда инде яңа таң яна...
Эфирлардан соңгы хәбәр көтеп,
жир уллары инде уяна.
Таң башлана анда Гимн белән,
караңгыны җиңә Яктылык.
Анда Кояш тормыш каршысына
Тау артыннан,
океаннардан чыга атлыгып!
Бакчаларны яңгыр сугардымы,
яфракларда чыклар атына...
Әй, туган жир!
Безнең көлү, күңелдәге сафлык,
иҗатларда яулап алган шатлык, —
Һәммәсе дә синең хакыңа!..

Синең яктың безгә килгән кебек,
безнең жылы сиңа житәрме?
Кояш юлына ракета гынамы?! —
Сине сөю безне күтәрде!
Күңелләрне бизи тик ул гына,
бөек итә сөю ялкыны...
Сандугачның нәни йөрәгенә
дөнья сыйган —
сөю аркылы!

## IV

Көндәгечә тормыш бара иде
яшел планетаның иңендә...
Кеше булып җирдә тудың икән, —
максатларың бар бит синең дә...

Син йөрисең материклар буйлап,
ил бурычын төяп җилкәңә.
Кеше икән — синдә җир язмышы,
кирәк сиңа — тыныч «Иртәгә».
Прогнозлар расмы, һава ничек,
яз кайтамы иске эзләрдән?
Телескоплар,
Айны якынайтып,
өсләреннәнниләр күзләгән?..

Торпедолар, кара дельфиннардай,
уйнаклаша Куба ярында.
Хиросима. Уран бизгәгеннән
тынып кала сабый
карында...

Әле анда кыяр-кыймас кына
кошлар куна шәрә куакка!
Нагасаки. Әле яңа гына
яшел чырай кайта
кыякка...
Крейсерлар тубына күкрәк куеп,
дулкыннарга ава яшь кыя,
Европаның тимер капкасына
кага-кага, кем ул яшь коя?..

Офыгыннан күтәрелгән һәр таң
көнен башлый шулай уянып.

Егерменче гасыр. Атом чоры.
Бу — гадәти көне
дөньяның…

*

Чү, каләмем!
Нигә төштек әле
мәшәкатьле Җир уртасына?
Әйдә, хыял, син күтәрче безне
романтиклар орбитасына!
Анда ямьле! Туплар авазыннан,
ичмасам, бер йолдыз селкенми!..

Планеталар
тып-тын йөзеп йөри
аквариумда
маймыч шикелле!..
Хыял белән кошлар юлы буйлап
күтәрелгән чакта түгәрәк,
Җир эндәште:
— Минем язмыштан тыш
бәхетегез булмас түгәрәк!

V

Туры килмәс инде сиңа, иптәш,
хыялымны чынга юрарга.
Минутларны санап, сәгать теле
якынлашты
яңа эрага!

Син сәгатькә карап тыныч идең,
тыныч иде әле карашың…
Олы угы кинәт сикереп алды
гасыр белән гасыр арасын.

Ак кәгазьгә күчереп утыра идем
нокта куйган хыял-фикерне.
Дөнья, тын кал!
Эфир дулкыннары
чынбарлыкка безне китерде.

Нишләдегез, тугры фикерләрем,
каләм,
алдашумы иде ниятең?!

Сизәсезме, кешеләр,
геройлары бит без
чынбарлыкка ашкан әкиятнең!..
Жюль Вернннар, Уэллслар кая? —
күреп калсын дөнья кызыгын:
Социализм күккә ялгап менде
Чынбарлык һәм Әкият сызыгын!..
Сез кайда соң, бергә шатланырга,
кайда соң сез, даһи фантастлар,
оракуллар,
йолдыз багучылар,
романтиклар,
шагыйрь Такташлар?!
Тавышыгыз кая, Дедал, Икар,
ник тындыгыз тарих төбендә?
Легендалар кая?!
Эндәшмимсез?..
Нигә соң сез ләм-мим бүгенгә?
Күрдегезме инде, җир уллары,
чыкты безгә нинди канатлар!..
Галактика ярларына карап,
кузгалдылар космик кораблар!..
Әйтерсең лә алар язып менде
хыялларның чынга ашканын.
Хыялмыни! Миллион рупорлардан

Җир тыңлады улы дәшкәнен:
«Хәлем яхшы, яхшы!
Очып үтәм
Азиянең зәңгәр иртәсен,
Европаның төнен…
Ә экранда,
минем бәхетем булып,
туган җирем, йөзеп үтәсең!»

…Ил уллары җиде кат биеклектән
«Хәлем яхшы!» диеп эндәште.
Ташлар булып ташлар гамьсез булмас —
ул йолдызлар, беләм, көнләште!..
Хөр Русия мендә Колумб кебек,
тыныч ярышларга юл башлап.
Җир әйләнә, тибә Ил йөрәге.
Җир йөрәге мендә
Кояшка!..

## VI

Йолдызстан!
Әй йолдызлар иле,
таңда искән җиләс җилләрдә
җир малае сиңа шушы җырын
сәлам итеп язып җибәрә.
Кайберәүләр сөйли: кеше анда
җирдәгедәй абынып егылмас.
Тыныч тормыш!
Әмма бодай уңмас,
чәчәкләр һәм кайнар җыр булмас.

Сөйләсеннәр! Даһи әүлиялар! —
Үз күзебез күрер барсын да…
Чәчәкләр һәм тормыш җырын яклап,

сирень шаулый тәрәз каршында.
Җирдә бар да әйбәт:
көн туга,
ямь өстәргә аяз иртәңә,
чыкта сугарылган комач гөлләр
шау чәчәкле башын күтәрә!
Һавалары шундый зәңгәр аның,
көн үткәндә безнең кыектан,
көтмәгәндә, өмет итмәгәндә,
өлеш чыга хәтта болыттан...
Сандугачка — тәхет,
безгә — бәхет,
Җир бик уңай оя корырга.
Җир уллары!
Кирәк безгә аның әйләнешен
сугышларсыз юлга борырга.
Ымласа да ерак планеталар,
чакырса да йолдыз юллары,
биеклеккә карап талпынсак та,
Җир максаты булыр —
югары!

Җем-җем итә илем йолдызлары,
космонавтлар җырлап узганда.
Туган җир ул!
Күкләр көнләшерлек
Йолдызстан төзедек без анда!
Ә шулай да җирдә эшләр күпме, —
Җиң сызгана хезмәт ярышы!..
Дулкыннарын Айга кага инде
Кулунданың алтын арышы!..
Безнең яшьлек төзелеш мәйданында
тезгенләде ярсу Падунны.
Тизлекләрне куа яңа тизлек,
еллар сорый бүтән адымны.

Эшләр күпме! Һәрчак көрәшләргә
чакыру килер алгы сызыктан.
Килер көннәр! Башка батырлыкны
игълан итәр
яңа Левитан!
Күрәзәлек нигә? Болай да бит
реаль хәлен илнең хис итәм:
Ерак таңнан әлегә күрелмәгән
яңа Шагыйрь тавышын ишетәм!
Тоеп торам яңа космонавтның
галәмнәрне айкап кайтасын...
Сувениры итеп
сөйгәненә
бирер гашыйк
зәңгәр Ай ташын!..

*1957–1962*

## *Уйна, улым!*

Идәнеңдә ята солдатларың,
калай әтәч,
агач космонавт...
Солдатларың кулсыз (син бик усал!),
бер почмакка китеп поскан ат.

Синең гүя бирредә —
автопарк!
«Пожарный»лар килеп туктаган;
«самосвал»лар тора әмер көтеп,
тик песиең генә йоклаган...

Шулай, улым,
син уйныйсың, әйдә,

уйна, уйна —
уйнар чакларың.
Гомер буе уйнамассың әле —
килеп җитәр уйлар чакларың!..

Син сорарсың беркөн:
«Җир зурмы?» — дип.
(Җавап бирә инде әтиләр.)
Зурлыгына әгәр ышанмасаң,
үлчәп карар синең тәпиләр.
Шушы яшьтән,
әле йөргән чакта
ярым атлап,
ярым үрмәләп,
өйрән, әйдә,
төзелеш әлифбасын,
курчакларың белән бергәләп.
Менә быргы сиңа —
горнист кебек
планетага, яле, сал аваз!
Йолдызларга җитеп яңгырап кайтсын.
Давыл тынсын ерак океаннарда,
күкләребез булсын чалт аяз!

Үз буының исеменнән җирдә
хәбәр сал син, әйдә, барысына.
Бишегендә баскан сабый төсле,
яфрак чыксын Кояш каршына!

Син уйныйсың.
Язгы тәрәзәләр
күк юлына карый яктырып.
Шул экранда елның дүрт вакыты
алышына,
җилләр кага юлга чакырып.

Син уйныйсың,
галәм гөмбәзендә,
үзенә туплап барлык язларны,
баш очында тавыш-тынсыз гына
янып тора
атом казаны!
Яна кояш, сүзсез җыр шикелле,
чаткылатып төсләр гаммасын,
үбә шашып
йолдызларны,
Җирне,
язгы бөреләрне —
һәммәсен!

Уйный Кояш,
әйе, ул да уйный:
уйный язны,
җирдә яз ясый.
Уйный Кояш,
сөю җырын уйный,
гашыйк булдың, Кояш, әллә син?
Син белерсең,
җирдә Кояш кызы —
Мәхәббәт бар,
гизә дөньяны...
Ул сулышын өрсә,
миллион еллар
бозда туңган йөрәк уяна...

Ә син нәни. Сиңа әле Кояш
әниең күзләреннән елмая.

Ә син нәни. Сиңа түшәм кая,
кая сиңа галәм гөмбәзе...
Сизмисең дә.

Төннәр буена болай «уйнап кына»
ураганнар Җирне дөмбәсли!

Уйнап кына атылып китә йолдыз —
метеор бәрә кораб бортына...
Уйнап кына кагыла
кемнең кулы
берәүләрнең яңа йортына?!
Авып китә ничә «этажлы йорт»,
ә кем көлә анда кул чабып?
Уенчык йорт!
Минем малай көлә,
кабат төзәренә ышанып.
Көлә малай,
кул чәбәкләп көлә,
чәчелеп ята агач шакмаклар...
Ә кайдадыр
чынлап «уйный» кемдер,
кеше көлми,
елый такмаклап...
Кул чәбәкләп,
бии-бии елый,
кайгысыннан шулай бушанып;
тормыш ватыкларын таптап елый,
төзеп булмасына ышанып...

Малай белми,
сикергәләп көлә.
Күрегез, имеш, тагын төзәтте!..
Музыкант күк шундый бирелеп уйный,
Уйный малай тыныч хезмәтне!..

* * *

Уйнадылар еллар безнең белән,
уйнадылар —
исең китәрлек!

Агач мылтык белән күзенә төбәп,
ул елларның исен китәрдек.
Ә әтиләр чын мылтыклар белән
шундый «уйнадылар» сугышны,
шундый уйнадылар —
ике арада
үлем төяп чуен туп очты!..
Без еракта,
кулны кулга куеп
«очты-очты» уйнап йөргәндә,
канат асларына бомба тагып,
очкан анда корыч тилгәннәр.
Очты-очты — снарядлар очты,
күз яше һәм каһәрләр очты...
Очты-очты — нигезе-ние белән
Җир йөзеннән шәһәрләр очты...
Очты-очты — күпме халык очты,
очты куллар, аяклар очты,
очты-очты тимер дивизия,
свастикалы байраклар очты.
Очты-очты — әй, күперләр очты,
җәһәннәмгә вагоннар очты!
Очты чиннар, кокардалар очты,
Һәм тәреле погоннар очты!
Очты-очты — рейхстаглар очты,
Адольфлар очты чайкалып,
креслолар,
«Майн кампф»лар очты!..
Очышларга, әй соң, бай тарих!..
«Сугыш-сугыш» уйнап очты еллар.
Калтырап торды дөнья һавасы.
Очты еллар.
Ерак офыклардан
ишетелә сугыш авазы:
— Айт-два,
айт-два!..

Янып тора хәтер,
 әйтерсең лә
гигант учак дөрли дөньяда...
Гомерлеккә сиңа бер киңәш бар:
шырпы белән, улым, уйнама!..

Ә магнатлар акча чөеш уйный:
Ватанын да сала уртага...
Барыннан да
 әйбәт уйный заман —
алышына төсләр картада!
Башын иеп,
 иске дәвер китә —
Үз уенын инде уйнаган...

Чалкан төшеп пушка лафетына,
Диктаторлар китә дөньядан!
Әгәр икәү «очты-очты» уйнап,
очмый торган әйбер исемен
әйткән чакта кул күтәрсәм,
 көлмә, —
мин күбрәкне күргән кешемен...

*

Тәрәзәдән синең йоклавыңны
күзәттем мин, шундый бирелеп
йоклый идең.
Нәрсә тотмакчы син,
ак кулларың белән үрелеп?

Өч йөз бала йоклый тәгәрәшеп,
чалкан төшеп,
ятып түш белән,
авыз турсайтып,
үчекләп кемнедер,

үпкәләп кемгәдер,
елмаеп, сөйләшеп төш белән,
очып,
юрганнарын тибеп,
бу Кояшка
ике ярымшарын күрсәтеп,
назлап кына сыйпый апалары
түшләреннән, «үсә-үсә» дип.
Өч йөз чырай!
Үпкәле иреннәр —
йокыда да уйный,
очына:
«түт-түт»,
«бип-бип!»
Нәни куллар ята,
Җир алмасы көтеп учына.
Пластмасс машиналар йөртә куллар,
ә иреннәр һаман:
«Түт-түт!» — ди.
Уйнадык та шулай тәгәрәшеп,
йокыга да килеп җиттек, ди.

Биш бармагы белән нурлар тотып,
баш астына салып бер кулын,
тәгәрәшеп өч йөз бәби йоклый, —
төшләр күреп йоклый
бер буын!

Алар йоклый. Яңа шәһәр туа,
Кояшкача чөеп түбәсен.
Сметалар үсә. Счет төймәсе
алар өчен бии, күрәсең.
Алар өчен яңа планетада
яна утлар,
дөрли учаклар.

Алар йоклый, ап-ак планетадай
ап-ак мендәрләрен кочаклап.
Алар өчен әле иң кирәге —
йокы,
уен,
сөтле шешәләр...
Хуҗа булыр өчен бу тормышка,
әнә шулай
елап-көлеп үсә кешеләр!..
Нәни кешеләр!
Җирдә
баштанаяк
манам диеп, сезне бәхеткә,
тавыш-тынсыз,
сүзсез җыр шикелле
яна Кояш алтын Тәхеттә!
Җылы булсын өчен кешелеккә,
Кояш түгел, без дә янабыз...

Баш очында
сүзсез җыр шикелле
яна Кояш —
алтын полонез!

*1964*

## *Таш аргамак*

Таш капка.
Таш диварлар
Таш дәүләт тып-тын...

Диварларда ята ташка-таш,
Таш плитәләр:
исемлеләр,
исемсезләр...
Солдатлар янәшә —
башка-баш.

Баш очында — таш паспортлар.
(Сугыш пропискасы!)
Котылгысыз ике дата:
«Килгән. Киткән».

Таш дәүләт.
Юк бередә погранзастава...

Чикләр юк.
Шлагбаумнар юк.
Чикләре уза телеп йөрәкләрне.
Кызыл меридиандай ул чикләр
прицел сызыгы буйлап үтәләр.
Ул чикләр
мәңгелеккә илтәләр.

Ул чикләр —
камчы булып ята җилкәдә.
Ул чикләр —
ат тоягы шикелле каты,
вөждан газабыдай авыр ул чикләр...

Кайгы кебек тирән,
намус кебек чиста,
яшь шикелле кайнар,
штык кебек салкын ул чикләр!..

Койма аръягында көн башлана.
Койма аръягында сәгать суга —
күңел сөенеп куя!
Димәк, Тормыш атлый,
Тормыш — юлда!
Таш һәйкәлләр
уңда-сулда...
Кайгылы матәмдә
таш ат башын игән.
Таш ирене белән
авызлыгын кысып,
кешни ярсып,
чәйни таш ялын.

Ә өстендә —
яралы яшь егет,
таш егет
таш атында бара чайкалып,
сызылып төшкән йөзенә
таш каны!
Мәңге шулай
таш аргамаклар,
таш кешеләр
гасырлардан барыр гасырга...
Санга сукмый алар
таш чикне!

* * *

Чү! Шаулама.
Йоклый батырлар.

Юеш окопларда
иңне иңгә куеп
яткан төсле йоклый туганнар.
Акрын!
Диварларда җилләр,
җилләр генә шаулый, ярсына.
Җилләр генә шаулап-көлеп кергә
мәрмәр постаментлар каршына.
Акрын, җил! Биредә — кешеләр. Акрын, уятма.
Алар
уяу иделәр, уятма. Алар авыр походлардан соң
онытылып черем итәләр. Биредә танкларны җиңгән
ирләр ята. Шәһәр төзүчеләр йоклый биредә.
Шахтер йоклый — яңа катламда, юлчы йоклый — ярты юлында;
шагыйрь йоклый — ярты поэмада, җырчы тынган
ярты җырында...

*

Койма аръягында
тормыш бара.
Шәһәр шау-шулары,
сабыйларның ишетелә анда көлгәне.
Ә биредә чаба таш аргамак,
шакы-шокы килә таш тоягы...
Юк, сәгать ул! —
Сәгать адымы белән
ишетелә
Вакыт килгәне...

* * *

Бу таш сыннар,
беләм, таш булса да,
җанлы тормышка бит кызыга.
Авызлыгын чәйни таш аргамак,
таш аллалар елый музейда!

Ташлар сөйләмиләр,
саргаялар,
каралалар,
яшел мүк баса.
Кем ятканы биредә онытылыр,
Җирдә йөргән кеше йокласа,
Җирдә калган Хәтер йокласа...
Кем ананың каберен югалтса,
кем атаның каберен югалтса,
ташны түгел,
таш бәгырьле улының
таш йөрәген яшел мүк баса.

* * *

Таш койманы онытып
йөри Яшьлек.
Керфегенә кунган
карны эретеп,
суырып үпте егет сөйгәнен...
Өсләренә кинәт бәс ишелде,
ак каеннар куйды сискәнеп.
Тартынма син, егет:
алар — ташлар гына,
тарсынма...
А, юк! Киттең,
син аларның
карашларын тойдың каршыңда.
Пышылдады күңелең:
— Кичерегез...
Зәңгәр эзләр калды
ике пар.
— Кичерегез безне,
сөю сүзен
әйтеп өлгермәгән егетләр!
Кичер, хәтер!

Нәрсә, егет,
ташлар өнсез алар,
ник үзеңне
гаеплегә санап йөрергә?
А, юк,
тынлык белән,
таш тынлык белән
алар җиңә безне,
мәҗбүр итә җавап бирергә!

— Кичерегез, мәхәббәтне татып
өлгермәгән батыр егетләр!
Кичерегез, — диде ике йөрәк, —
зәңгәр эзләр калды
ике пар.

Алар шулай
таш дәүләтне
ташлап киттеләр.

**Үкенү монологы**

Син дә килдең бирегә көннәр аша, еллар
аша килдең,
ашыкмаган идең, килеп җиттең.
Каршы алды сине...
Өлгермәдең. Соңгы бүләгедәй
ташы калды сиңа.
Соңладыңмы, әһә, соңлама, дип,
ничә тапкыр сиңа,
тәрәзәңә көннәр шакып керде
ничә тапкыр сиңа.
Соңладыңмы, әһә, салкын ташы
инде такыр сиңа...

Еламады, таштай катты —
яше калды сиңа.
Теләсәң нишлә, хет башың ор —
ташы калды сиңа...
Соңладыңмы, таш каршында,
әй, көчсез дә бу яшь!
Соңгы чара — ташы калды,
ташы белән сөйләш!

**Беренче таш монологы**

Улым, безне аерган чик —
мәңгелек ул.
Ләкин сине күрәм.
Авыр миңа...
Син бер качак кебек үз илеңдә, —
кулың күтәрәсең җилгә дә.
Каберем ташы сиңа калкан булмас,
ата даны мәңге алып бармас —
вакыт, улым,
барма җилкәдә...

**Икенче таш монологы**

Без — яшьтәшләр, улым, синең белән.
Мин туктадым төгәл утызда.
Төгәл утыз — сиңа. Синең юлың
минекеннән әле бик кыска...
Ташлама юк яшькә. Яшь — агымсу.
Үзең ата, үзең ир хәзер.
Тормыш өчен көрәш постларында
аталар һәм уллар —
бер хәзер!

## Исемсез таш монологы

Җиңүгә ике адым иде. Ике адым. Берсен атладым.
Мин егылдым, Ватан. Улың итеп күзем капладың.
Син кичер, Ватан! Калды минем канлы сукмагым.
Үлемне мин исән чакта санга сукмадым!
Бер гомерем бар иде, аны да сиңа бирдем.
Кичер, илем, бирегә мин вакытсыз кердем...
Оныттым мин төсләрне дә,
гөлләреңнән исен...
Туган илем, онытмамын
байрагыңның төсен!
Үлем кыен түгел. Кыен шунысы —
почта йөрми бирегә.
Әйтер идем бер сүз, ләкин
кош та керми бирегә...
Иң кыены, дезертир дип
уйлый бугай хатын.
Табар иде, бармагандыр
аңа соңгы хатым...
Мин үтәдем антны, җаным,
хет бер ташыма сыен.
Үлеме дә берни түгел,
билгесезлек кыен!
Биредә күпләр нәни кызын яки улын көтә.
Мин — «билгесез». (Нәни куллар чәчәк салып китә.)
Мин — «билгесез». Шул көенчә
ничә ел ятам.
Исемемне булса да бер
язып куйчы, Ватан!

* * *

Таш капканы каерып ач,
капканы —
ишетелә
тормыш какканы.

Мәңгелекне сөйрәп,
        таш юрганың
        ишетелә ярсып чапканы:
        «Мең тугыз йөз кырык...»
Ак диварның
        исем-фамилияле бер ташы
        ничә еллар дәшә:
        «Хуш, туган ил!
        Мең тугыз йөз кырык...»
        Китеп барган шулай ир башы.
Тукта, тыңла!
        Уятмагыз!
        Таш өстендә
        кызыл йөрәк төсле ут яна.
Плитәдә ахак йөрәк дөрли —
Уяу бул син, Хәтер, йоклама!
        Әйдә, җаным, әйдә,
        чыгыйк биредән,
        сагышларны шунда яндырып.
        Җаны булган бөтен нәрсә йоклый.
        Тик мәңгегә уяу:
        Хәтер,
        Ут!
        Башны иеп,
                утлар йотып чыктык,
        талгын безнең бөтен хәрәкәт...
        ә капкага кемдер
        тырышып язган:
        Ирек + Кояш = Мәхәббәт.

*Казан — Балдоне — Рига, 1963*

## *Сонгми*

Лидице, Пирчюпис, Хатынь — фашистлар тарафыннан җирдән юк ителгән авыллар. Алар меңнән артык. Тарихтагы бу исемлеккә тагын бер корбан өстәлде: Вьетнам авылы Сонгми... Америка солдатлары Сонгминың 500дән артык тыныч халкын үтерделәр һәм авылны яндырып җир белән тигезләделәр.

**«Онытма!»**

Кояш эзли иртән:
бар иде авыл,
бар иде авыл...
Кырда кара давыл!..

Сонгми,
синең хакта бүген бу җырым,
синең әле пыскып
көлең дә суынмас борын,
кузгалды йөрәгем соңлаган янгынга.
Инде үзе дөрли, яна
кеше исемен йөрткән адәмнәр яккан утта!
Кемнәрдер пышылдый инде анда
(янгыннан соң!):
«О-ныт-ма!..»
(Шулай дигән идек Хиросимадан соң да!)
Сонгми, суынма!
Сине,
инде бер янганны,
кирәк түгел кабат сүндерергә,
(моны теләүчеләр бик күп:
«утың күренмәсен!..»)
кабызырга кирәк сине,
феникстай терелтергә,
йөрәкләрне җырга ягыйк —
утың сүрелмәсен!
Син — мәңгелек ут.

Утлар уты!
Яндыр барсын, көйдер, өт, Сонгми,
каргышың кызуында!
Тирбәлсен мәңге,
тирбәлсен синең шәүләң
егерменче гасыр офыгында.
Күренсен тарих кырларыннан,
дөрләсен исемең —
набатка күтәргән чаңмыни!
Кешеләр
тәҗрибә сүзе итеп әйтерләр:
«Бар иде бит җир йөзендә,
бар иде... Сонгми!..»
Шушы янгын, ялмап хәтерләрен,
дөнья барын
оныттырмасын бер генә минутка.
Сөйрәсен синең ялкын эчендәге тавышың,
сөйрәсен бугазларыннан
үзләре яккан утка!
«О-ныт-ма!»

...Әзләнмә, җил,
актарынма көлдә,
ишекләр юк,
калган бары — тотка.
Ут эчендә ахакланды җаннар —
әверелде тоташ утка!..

## Җир анты

Җир ант итте иртән күкләргә:
«Ант итәм —
тургайның беренче һәм соңгы җыры белән,
игелекле кырларым,
күкрәүләрем,
яшеннәрем белән ант итәм;

океаннардагы давылларым,
йөземнән юк ителгән шәһәр-авылларым,
яңгыр-яшем,
үлән-чәчем белән — ант итәм;
ант итәм
корбаннарның җиңел туфрагы белән,
толларның авыр күз яшьләре белән,
гашыйкларның
беренче һәм соңгы сөюе белән,
сабыйлар иренендәге хәләл күкрәк сөте белән,
гөнаһсыз күзләрнең кара суы белән — ант итәм:
сакларсмын мәңгегә аның ярасын!

Кисәләр явыз куллар,
аударалар иң кирәкле тирәгемне —
гомер агачын!
Актаралар салкын куллар, актаралар йөрәгемне,
йолкыйлар шытырдатып бәгърем парәсен —
кеше гомерен!
Ут төртәләр каныма, ут төртәләр, әйтеп:
«Бәгыре кайнасын!..»
Кан коялар явыз куллар, — кызыл диңгез! —
кан коялар,
кызыл болыт булды инде күккә ашканы...
Күккә ышанмыйсыз икән, кешеләр,
карагызчы бер дөньяга —
гөнаһлардан каралды Кәгъбә ташлары!
Тәннәремдә биш уянам, мин биш янам:
миндә Дахау, Хиросима градуслары...
Кайнаталар бәгыремне, ут ягалар, кайнаталар,
кайнаулардан — янар таудай, җаным айнымый.
Тәнемдә җөй-җөй булып сызылып, иске
Пирчюпислар* яталар,

* Пирчюпис — Германия фашистлары яндырган литва авылы.

аларга килеп өстәлде
утлы яңа җөй —
Сонгми!..
Матур лозунглар яза кешеләр, яза миндә, —
кычкыралар барлык ганимәтләр: «Бар да — Кешегә!»
Гөлләр үстерәләр, шаулый бакча язгы җилдә;
шаулап торган тормыш бакчасында
кеше гомере — киселә!
Күренә миңа: киселә тора, тоям күпне:
кемнәр яклый, упкыннарга мине кем этәрә.
Күтәрәләр дә бәндәләр иңнәренә кара йөкне,
әйтәләр гаҗәпләнеп: «Ничек Җир күтәрә?!»
Ә үзләре ничек итеп явызлыкны күтәрәләр,
авырлыгын сала бу йөк көчлеләрдән башлап кемгә?
Азатлык байрагы астында Азатлыкны үтерәләр!
Кемгә кирәк ул азатлык — кешеләрдән башка — кемгә?!
Ялны белми гизәм галәм океанында,
метеорлар яңгыры аша уйлап чыгам төннән көнгә:
бәхет микән, хәсрәт микән сезнең тормыш чатларында,
нинди мирас кучә икән кемнән — кемгә?..
Ә сез әле һаман үтереш уены уйнап
туялмыйсыз, кеше җаны — сезгә санмыни!
Кая гына поссагыз да, сезнең бөтен эзләр буйлап
артыгыздан яныш бара, чаба — Сонгми!
Динамиттай суга Хәтер, минем хәтәр
күз яшьләрем, каргышларым —
әйләндерә тораташка!..
Җәһәннәмгә очкан җаның: «Иманым — Җир», — диеп әйтер,
минем кәгъбәм — үз хәтерем,
мин тезләнмим Кара Ташка...
Мин — Җир!

**«Мин — Сонгми!»**

Инеш кенә чылтырап агып яткан
тупыллы һәм таллы бер авылга
төнге сәгать 12 дә,

дәшми-тынмый,
килеп керде...
Сонгми!..
Су сорады...
Кара шәлен япкан.
Тезләнде ул килеп
мич алдына:
«Кояш мине эзли, диләр,
ә мин аны күптән
күргәнем юк.
Ә мин аннан качам,
куркам хәзер
яктылыктан...

Мин, кешеләр, сездә калам.

Йөрим нигездән нигезгә...
Без, җирдән үчкән авыллар,
йөрешәбез шулай
бер-беребезгә.
Сорашабыз хәлләрне.
Карыйбыз бары тик сүнгән учакларга,
искә төшерәбез сабыйларның шат авазын,
икмәк исен,
тормыш төсен,
матчаларда бишек тирбәлүен...
Картларымның тамак кырган авазы
тора һаман
ишегалларымда!

Тора һаман урамнарда
агачларның яшел күләгәсе...
һәм тирбәлә
юлга төшеп
гашыйкларның
ак шәүләсе!..

Әтәчләрем кычкыра
таң алдыннан...
Яңгыр ява!

Һәр иртәдә
кыр капкамнан көтү чыга...
Су алалар коемнан!..
Бар да миңа шулай тоела.
Үзем белән йөри күченеп
бар да...
Кайталар кешеләрем,
китәләр — төрле вакытларда,
аердылар мәңгегә йокымнан!..

Төнем — йокысыз.
Булдым Пирчюписта.
Ул савыккан, җыйган балаларын.
Лидицеда булдым.
Ул да онытып килә бугай
иске яраларын...

Сөйләштек утырып бер туйганчы,
таң сызылганчы...
Тик
йокыда,
каядыр төш күреп еласа балалары,
үземнекеләр! дип ымсынып
куя йөрәк, барын юксынып,
әрнеп сызлый...

Мин — Сонгми.
Мин — яну образы!

Әгәр
Җир шарындагы бөтен авылларның
учаклары җыелып янса да,
яна алмас иде минем кадәр!..

Мин — Сонгми!
Калды нигезем такырланып.
Шул янудан миллионнарга тапкырланып,
чаткыланып
үрчедем мин!»

Шуннан бирле
яши йөрәк уртасында
һәр кешегә —
берәр Сонгми!

*1970*

## *Урман җиле*

### I

Мин елларны ярып алга барам,
ә син, урман, колагыма һаман
сер сөйлисең... Яшел симфония!

Кояшлы җил, кояшлы алан!..

Яшел бөреләргә җан кергәндә —
үрелгәндә язгы күкләргә, —
иң беренче ләйсән яңгырлары
җиргә сибәләвен яратам.
Урман өсләрендә — алсу таң...
Күке — җанлы урман сәгате, —
ел да саный еллар исәбен...
Яңа гына туган яфракларга
җәйге яңгыр койса, күк күкрәп,
мин яңадан туам! Әйтерсең лә
урман белән бездә — бер күкрәк!

Яшеннәре белән чаткыланып,
күкрәүләрен алып җәй килә.
Тынып кала бермәл сандугачлар,
җәйге хуш исләрдән исереп!
Куера һәм калыная яфрак, —
җирнең иң бай чагы дымнарга;
нәзек сабакларга сөт йөгерә,
җиләкләргә җирдән бал менә!
Бал гынамы? Урман туфрагыннан
нинди төсләр иңә гөлләргә!
Мин тикмәгә сине искә алмыйм:
Урман, синдә тагын ныграк сизелә
Кояш, Су һәм Туфрак дуслыгы.

## II

Күләгәләр, яфрак ешлыгы.
Шуның аша нурлар —
кояш балалары коела,
Чайкала һәм бии чал наратлар,
урман җыры шаулый югары!

Ап-ак нурлар — арфа кыллары, —
җилләр чиртеп уйный таң җырын.
Нарат очларына күтәрелеп
бер карасаң, дөнья селкенә!

Урман — яшел храм, залларында
орган музыкасы ишетелә...

Күзләреңне йомып тыңлап кара, —
диңгез шаулый кебек якында.
Диңгез шаулый, җылы зәңгәр җиле
кочып үтә сине арканнан:
ак яхталар уза, дельфиннар...
медузалар, ап-ак парашюттай,

диңгез десантыдай тирбәлә!
Күзең ачсаң, син урманда тагын, —
урман җиле сине иркәли.
Абагалар — яшел урман гербы.
Һәрбер яфрак битен кояшка
куя монда, биек үрмәли!

### III

Ешлыкларны, якты күлләрне
акрын гына кичеп килә көз, —
тирәкләргә кабына сары төс.
Көзге сафлык керә урманга!
(Кайгы, димә һәрбер сарыны,
сагыш, димә, бу — өлгерү төсе!)
Салкынча җил исә сарылып
тармакларга, куак эчләрендә
сары чыпчык, сикерә-сикерә,
орлык чүпли! Менә үрмәкүч
капроннан да нәзек җәтмәсенә
киләп сарып йөри чабулап, —
керфекләргә ябыша пәрәвез!..

Нинди һава! Куак тәлгәшләрен
сыйпап узсаң, соңгы чикләвекләр
рәхәт булып җаныңа кагыла!
Җир маеның исе япь-яшь кыяр
исен хәтерләтә борынга!

Ул миләшләр яна ахакланып,
чем-чем булып, җилдә тирбәлеп, —
балланырга кырау көтә алар...
Ә таң белән ап-ак кыраудан
урман гөле башын күтәрмәде, —
кыштан хәбәр килде
урманга!..

## IV

Кичер, урман, синең моңнарга
вакытында җавап бирмәдем:
улың булып сиңа килмәдем...
Иңнәреңнән синең төшкән инде
көз бүләге — сары күлмәгең!..

Алан тулы яфрак, тубыгыңнан,
әйтерсең лә барам су ерып...
Бәйрәм иткән давыл: тәңкәләрне
уңга-сулга сипкән мул итеп!

Каршылыйсың мине сүрән генә,
соңлап кайткан гамьсез ул итеп.
Минем өчен соңгы матурлыгың
булганы юк! Менә хәзер дә...
каршылыйсың кышкы йокыңны син,
сары түшәгеңне әзерләп!

Матур төшләр сиңа, урман-сылу!
Җәйләреңдә якты яшеннәр,
зәңгәр күздәй күлләреңә карап,
сыйпап үпсен яшел чәчеңнән.

Матур төшләр сиңа, урман-гүзәл!
Сиңа кайта язын яшеллек.
Ә мин — Кеше! Яшьлек эзләремне
узган еллар ерак яшерде...

Сиңа барсам, урман, карагайлар
әкият сөйли миңа һәр чакта.

Ә мин — Кеше. Мине заман җыры
эзләп таба синең кочакта!

*1968*

## *Хиросима шагыйрьләренә*

*Фаҗиганең 30 еллыгына*

Сакура* чәчәк атканда,
алсу бер таңда...
Сез тынычлап йоклыйсыздыр, бәлки,
Тынычлык мәйданында**?
Аз гына тәтенләнә хәтер
дөньяда...

Кайдан белим соң мин,
ерак август таңында,
тыныч болын буйлап
бозау куганда,
яланаяк малай,
сезнең якларда
атом гөмбәсенең зураеп үсүен,
миллион гомерләрне кисүен.

Радиоактив җилләр исүен...
белми идем.

Атом корбаны нәни Сасаки***
кайта да, еллар аша
атом көйдергән күзләрен эзләп,
кояш сорый нәни учына...
Ә сез әле тыныч йоклыйсызмы
шундый чакта,
шагыйрь булып, тыныч йоклыйсызмы?

Нигә күтәрмисез тавышыгызны?!

---

* Сакура — япон чиясе.
** Хиросимадагы мәйдан.
*** Сасаки — атом нурларыннан сукырайган кыз, һәйкәле Тынычлык мәйданында.

Йокы алмый
гүзәл иртәләр алдында,
Тынычлык мәйданында.
Көрәш рухы биләп алса жанны,
тынлык дип кенә
тынычлап булмый бит ул,
жаннар белән генә
яулап була аны!

Ә сез, япон шагыйрьләре,
Таконури*,
тыныч йокларга тиеш түгелсез.
Тынычланмаска
Тынычлык мәйданында
безгә,
атом көйдергәнче күгебезне,
Таконури, син әйт!
Шагыйрьләр әйтсеннәр үз сүзләрен.

Нигә кутәрмисез тавышыгызны?!

Яшел болын буйлап
мин яланаяк
кызыл бозау куганда,
искән икән радиоактив жилләр,
күргән бар илләр
атом һәлакәте үсканен,
еллар өстенә
жәелгән кара шәүләсен...

Нигә кутәрмисез тавышыгызны?!

Бөек еллар өчен,
якты киләчәк хакына?
Нигә?

---

* Таконури Симидзу — күренекле шагыйрь, «Хиросима жырлары»ның авторы.

Байрагыңдагы тотылган кояш
азат булсын өчен.

Нигә?

Тарих белә,
1945 нең 6 нчы август иртәсен...
(Мин кызыл бозау куган ел...)

Нигә күтәрмибез тавышыбызны?!

Радиоактив җилләрдән
саклый алмый бернинди «банзай»лар,
коткаралмас бернинди камикадзелар.
Япон шагыйрьләре!
Нигә күтәрмисез тавышыгызны?
Хиросима шагыйрьләре!
Тыныч калырга тиеш түгел
Тынычлык хакына
һәр ил шагыйре.
Ә шулай да,
Хиросима ватаны буларак,
Сезнең тавыш
ешрак ишетелергә тиеш
кешеләргә!

Без тыныч калырга тиеш түгел
тынычлык мәйданнарында.
Кешелек тыныч карамый
атом ярасына.

Кояш шагыйрьләре!

Тырышыйк без, әйдә,
шәһәр генә түгел,
илләр
булмасын дип,
ХИРОСИМА!

*6 август, 1975*

# *Табигатькә дүрт җыр*

...1627 елда соңгы тур сыеры үтерелгән...
...Кайчандыр Лабрадор ярыматавында яшәгән канатсыз кошлар — гагаркалар, кешеләр эзәрлекләвеннән качып, Фарер атауларына күчкәннәр, 1844 елда шулардан соңгы пар кош юк ителгән...
...Соңгы зубр 1927 елда Алаус тавында атылган...

*Табигатьне саклау хроникасыннан*

## I

Рәхмәт инде, безгә килеп җиткән кошлар,
канатлылар, канатсызлар — һәммәгезгә!
Кичеп ташкүмергә калган урманнарны,
кичеп боз чорларын, кеше куйган тозакларны,
очып-йөгереп, әмма кошлар булып, кош хәлендә
безнең чорга килеп, урман-кырны-күлне ямьләвегезгә!
Рәхмәт сиңа, канатсыз кош, — елышып как кыяларга,
Лабрадорның җылы ярларыннан
килеп чыгып Атлантика карларына
гел канатсыз килеш, төрле җирдә кышлап-җәйләп,
чакрымнар һәм вакыт буйлап йөгереп, җәяүләп,
омтылгансың безгә — яңа чорның таңнарына!
Ашкынгансыз икәү — калдырырга яңа токым,
җитәкләшеп мәхәббәттә, яшәп томшыкка томшык!
Сыенгансыз җылы эзләп салкын, юеш кыяларга,
карлы киңлекләрдән эзләгәнсез ышык...
Җитәкләшеп мәхәббәттә, гомер буе аерылмыйча...
Һәр адымыгыз сезнең — яшәү өчен тартыш!
Яңа чорның уртасына җитеп егылгансыз —
хушыгыз, башны башка куеп, мәңгелеккә калган пар кош!
Ә шулай да, ис китмичә тарихка һәм еллар узуына,
сезне чорлар алып килгән — Дарвин музеена...

## II

Еллар томаны аша ишетәм ерак быргы җырын,
таныйм, чорлар урманыннан чыккан тур сыерын!
Килә кешеләр каршысына, башын тотып чор җиленә:
япь-яшь курпы исләрен сизәдер борыны!..
Килә туры! Үзәннәр дә, кыя-таш та яшерә алмый —
таудай гәүдә кучеп бара яшел киңлекләрдә!
...Учак яна! Ит кирәк, ит! Ит тавына туры карап,
таш балтасын тотып чыга, күтәрелә бәндә!..
Учак яна... Ил куана — муенына кызыл элмәк кигез!
...Сагыныр өчен калыр тарихларда — ике метр мөгез!..
Сурәтенә карый һәркем җирдә соңгы турның.
Музейларда билгеләгән тарих бу турның да урынын!
Зур булу да кыен табигатьтә! Көчлеләрнең дошманы
да зурдыр...
Кичер мине, кеше токымын, кичер... соңгы зубр!
Экспонат булып калдың бөек корбаннарга...
И, бозавың үксеп елый сыман ерак урманнарда!..

## III

Рәхмәт сезгә, тургайларым, кыр кошлары!
Тикмәгә халкым җырларына сайрап кермәгәнсез, —
һәр җырында халкымның — кошлар канатлана!..
Баш иеп сезнең табигать биргән якты талантларга,
җиңеллек телим сезнең канатларга!
Күп сүз әйтелсә дә сезнең исемнәргә, үзебезнең тургайларга,
болар әле азрак бугай шулай да!
Сез ул тынычлык көен таратучы тугайларга,
сез бит тиңсез күкләр оркестры!
Һаваларда уңыш маршын уйныйсыз кистереп!
Рәхмәт сезгә, җирдә туып, сезнең белән очрашканга,
рәхмәт — язмышларга!
Рәхмәт сезгә, тирәкләр, туган җирнең куаклары,

һәрбер тармагыгыз — якты — кошлар иле!
Һәр куакка якты моңнар кунакласын,
кагылмасын сезгә афәт җиле!
Менә бүген
туплар, утлар шартлаганда еракларда,
матәм җыры кагылганда колакларга,
кеше битлеге киеп, зобанилар
үтереш уены уйнаганда,
без яшәгән чәчәкле җир янганда,
табигатьнең дошманнары бомба ташлап куанганда,
алтын хакына җирне урап ялкынга
кара мәкер уянганда, ерткычлык нәфесе канда, —
бүген һәйкәл куясы бар сезгә, Табигатькә,
һәйкәл коясы бар кешелекле киек-җанварларга!
Һәйкәл куясы бар
йөрәгендә кешелек дигән җаны барларга!..
Бүген кирәк, менә шушы бөек сәгатьтә,
һәйкәл кирәк олы сәнгатькә!
Алар исемен мәрмәрләргә,
иң ак Кәгъбә ташларына кирәк уярга!
Күкнең һәр кошына, җирнең һәр үләненә, гөлләргә,
имин хәбәр китергән җылы җилләргә,
җир күркәдәй шаулап торган урманнарга,
ил көзгесе булган елга һәм күлләргә,
дала мәкләренә, кылганнарга,
җирне гөл итүче игелекле җаннарга
кирәк бүген һәйкәл куярга,
Табигатьнең җаны өчен
дога кылганнарга!

## IV

Сиңа зур бер сүзем бар, Кешем:
ирешелгәннәр — бар да синең эшең,
төзелгәннәр — бар да синең эшең,

өзелгәннәр — бар да синең эшең,
барында да синең өлешең!
Күз алдымда синең узганың:
кагып мәгарәләр тузанын,
бу көннәргә таба килешең...
дөнья киңлегенә куанып!
Чактың чакма, ут кабыздың учакка.
Күп тырыштың маймылдан
кеше булыр өчен!..
Ә кайчакта — син сузылдың пычакка.
Кан агыздың!
Чактың чакма, ут көйрәттең учакта...
Әйе, тарих сине аклый күп чакта.
Ия булгач инде камиллеккә — гакылга,
син карадың бөек серләр артына...
Күз ташладың еракка һәм якынга,
тал кистең дә бишек астың матчага,
син карадың учактагы ахак ялкынга!
Әнә шулай
башланды синең кешелекле эшең.
Син бит тумыштан ук җирдә —
өр-яңаны,
камил затлар төзү өчен,
үзең дә бит Мәхәббәт тирәгенең
алтын җимеше!
Сөю улы булып тудың,
сөяр-көяр өчен.
Килмәдең тормыш арбасына фәкать
кайгы төяр өчен!
Шуннан бирле
биек-биек баскычларга
җитәкләде сине Сөю!
Рәхмәт сиңа, Кешем,
табигатьнең улы булып
җиргә туган бөек җисем!

Рәхмәт сиңа,
таш балтаңны ташлап, үсеп,
Айга менгән өчен!
Һәркемнең бар җирдә үзенең кошы, үз агачы,
гомер дәрьясына койган үз инеше;
һәр тирәктә — туар буыннарның
сөю бөресе!

* * *

Суларга төшмәсен агулы болытлар,
имин көн каршына ургып чыксын җирнең һәр чишмәсе.
Әле җир карынында шыткан туар оныклар,
дәрьяларга иелеп, саф су эчсен,
кан-яшь эчмәсен!
Дәшсен аларны якты хыяллары, йолдыз далалары,
саф үләнгә ятсын чалкан табигать балалары!
Саклап шушы якты хыялларны,
булыйк табигатьнең күзе-колагы!
Яшәсен бу игелекле туфракта,
яшәсен — җирнең һәрбер куагы!
Өмет белән бага безгә чал җиһан йөзе,
калсын табигатьтә кешеләрнең
кешелекле эзе!
Менә шулдыр, Кешем,
кешелекнең бер вәкиле булып
сиңа әйтер сүзем!

*1974*

## *Соңгы гыйнвар*

*(Публицистик поэма)*

Тонык ай бата-чума йөзә болытлар эченнән,
әйтерсең кемдер калкан ыргыткан болытлар артына;
әйтерсең бозлар арасыннан тирбәлеп йөзә көймә —
алар утырган көймә —
Фин култыгында...
Ул ята.
Кар туза. Ерактан
күтәрелә, үсә төнге орган авазы, —
әйтерсең Лондонда — даң-доң! — чиркәү кагалар, —
шул чиркәүдә —
большевиклар съезды...

Күтәрелә, гүләп, ерак Таммерфорс,
фин бозлары эри чикәләрдә,
йөзгә бәрелеп уза Саян җилләре...
Кан авазымы бу, симфониями?

Көрәш жыры, «Аппассионата»!
«Аппассионата», ерак җәйдән
күкрәп килгән җылы яңгырдай,
карлы төнгә агыла. Эри карлар,
карлар түгел, ап-ак маңгаеннан
тирләр тама, —
шундый авырлар!
Ерак түгел язгы яңгырлар!..
Рәхмәт,
булды,
житәр, Бетховен!
Сүнде эфир.
Бик сак кына ачып ишекләрне,
узды шәүлә алгы бүлмәгә.

Шәм калтырап яна. Шул яктыда
Өмет* килде
хәлен белмәгә.

Өмет килде аның янына.
Утырды да, баш очына иелеп,
сорады ул:
— Нәрсә, Володя?..

Яз хәбәре төсле якты күзләр
күңел жылысы белән елмая.
— Укы әле, Надя, «Мәхәббәт»не**,
бөек инглизне
яңадан.

*

Декабрьнең кырыс жилләрендә
янды башым,
жил агачны бөкте бульварларда,
курай уйнап исте чатларда...
Ап-ак көшел булып кар буралды,
сызгырды жил туган якларда...

Очты кошлар, тәпиләрен тартып;
пыран-заран килде ак дөнья!..
Куян чапты кырда. Бүре, улап,
таңын каршылады капкында.

Тимерне ул чәйнәп качалмады —
ачалмады салкын йозакны...
Килде аучы иртән. «Кунагын» ул
пушторгка тунап озатты...

---

* Өмет — сүз Надежда Крупская хакында бара.
** Джек Лондонның «Тормышка мәхәббәт» хикәясен Ленин Крупская-дан үзенең соңгы көннәрендә дә укыткан.

...Шундый сыңар бүген эзгә төште, —
ычкынгандыр ничек капкыннан? —
каны кала карда, бик сак кына
килә бүген Кеше артыннан...

Эзне исни, туктый, тагын килә,
сеңеп карга төнге тынлыкта...
Кеше шуыша, туплап соңгы көчен —
ак киңлектә хәлсез бер нокта.

Ул үрмәли җан ачысы белән,
җиңнәренә канлы кар тулган.
Килә үлем менә өченче төн
эзәрлекләп аның артыннан...

Өстерәлә, тотынып әремнәргә —
бу бәйгедә узар кем кемне?
Кысыла ара. Туктый ерткыч. Күзләр
яшел ялкын кинәт бөркеде!

Ул якында, менә сизелә тыны, —
кагыла йөзгә, авыр... кызганыч...
Ул ач җанвар, ул яшәргә тели,
ул нәфесен сиңа сузган ич!

Ул — карт җанвар. Аның көче инде
житсә житәр авыру кешегә.
Ул — янәшә! Менә... борыны тия
муенының шәрә төшенә!

Яна күзләр! Менә көткән корбан —
ул батыра шәрә азавын...
Соңгы мизгел! Шул мизгелдә Кеше
кичерә дә үлем газабын,
талпына да, туңган бармакларын

ач бугазга батыра капшап!
Тыны бетеп кыса! Аннан ава,
бушап калган капчыкка охшап!

Айкала да күкләр тынып кала —
ята икәү карны тыгызлап.
Ә мәхәббәт җиңә! Бу бәйгедә
секундантлар бары — йолдызлар...

Тавыш-тынсыз җемелдиләр, гүя
галәм ярына яккан учаклар.
Бер бүрене генә будыкмы соң —
меңен будык. Дутов, Колчаклар...

Мең бүреләр зәгыйфь Россияне,
эзәрлекләп, канлы бөҗрага
кыскан чакта, алмаз кылычы белән
аларны ул күпме тураган!

Бүген менә шул ук бүреләрнең
төште бугай берсе эзенә.
Менә бүген
Үлем дигән бүре
карап тора аның күзенә.

*

Аның бәгырендә мең яра бар,
ята анда эсер кургашы,
югалтулар катыш өмет җыры,
һәлакәтле хәтәр юл башы,
Саян салкынының энәләре,
фин бозлары, карлы дулкыннар,
Темза ютәлләре... Жандармның
дага эзе ята сулкылдап.

*

Горкада кар ява,
бар дөньяда
яфрак-яфрак карлар ява сыман.
Каенлы Җир язга карап оча
яфрак-яфрак карлар арасыннан.
Оча карлар
таллар арасыннан.
(Каны саркый тирән ярасыннан!)

Ил өмете булып кызыл гөлләр
шытып чыга
ап-ак кар астыннан.
Горкада кар ява,
(Соңгы Гыйнвар!)
Карлар эри аның карашыннан.

Горкада кар ява.
Бар дөньяда
яфрак-яфрак карлар ява сыман.
Киңлекләрдән ап-ак Гыйнвар бара...

Сызлана Ил
Аның ярасыннан.
Өметле Җир язга карап оча —
алыштырып оча көнне төннәр...
Карлар туза — гүя хәлен язган
бюллетеньнәр оча,
бюллетеньнәр!..

Бар дөньяга оча бюллетеньнәр.
«Хәле ничек?», «Хәле ничек?» диеп
сорый төннәр,
сорый көннәр...

«Хәле ничек?» диеп сорый Илем,
тынып калган Гыйнвар паркта.
Иптәш Эшче, куеп чүкечен,
тын алмыйча күзен төбәгән
Горкадагы ерак бер йортка.
«Хәле инде ничек булыр?» диеп,
Сембер белән
Самар киңәшә.
Керфек какмый инде беркем, бер төн,
бер генә көн хәлен белмәсә.

*

Горкадагы шәрә өрәңгеләр,
аллеяда карлы юкәләр,
селкетми дә Гыйнвар сыкыларын,
күтәләр —
кар шәлләрен урап тезелгәннәр.
Дөнья тып-тын: «Нәрсә булган соң?»
Боз астында тирән сулап ята
янәшәдә Пахра елгасы...

Аллеяда бергә Аның белән
уйнап йөргән шаян балалар,
кар йомарлап нәни учларына,
тынып калган...
Күгәрчен тәпиедәй,
нәни бармаклары кызарган.

Еракларда
Таммерфорс шахтерлары тынган,
коммунарлар күтә Сенада...
Халыкларның бөек сабырлыгы,
Везувийдай,
тын да алмый көтә
дөньяда!

Өметле Җир язга таба оча,
алыштырып оча көнне төннәр...
Карлар туза —
гүя хәлен язган
бюллетеньнәр оча,
бюллетеньнәр!..

*

Яз ишек төбендә кала...
Басу-кырлар кала сөрелмичә,
Уңыш җыры күккә үрелмичә
(тик Кояш күгендә кала!).

...Толлар кала,
балалар елап кала
колонияләрдә икмәк-нисез...
Хаклыйсы бар сабыйларның хакын —
мондый чакта ничек китмәк димсез?!

Күпме алар кала — әлифбасыз,
кырык ямау сырган бишмәт киеп?!
Гыйнвар салкыныннан алсу куллар
сузылалар сүзсез «Икмәк!» диеп.

Күпме әле кабызасы утлар! —
Россияне алар ничек илтер —
тиешенчә
җылытылмыйча кала Россия...

Никадәр эш кала! — юк, бу булмас!..
Ярты юлдан ничек китмәк кирәк?
Ерак түгел Ил язына тагын, —
бик ашыгып алай типмә, йөрәк.

Шул кадерле вакыт тикмәгә
әрәм булсын, имеш,
гафу итмәс.
Кесәдәге аның сәгате
ничек тигез бара! Узып китмәс.
Хуҗасын ул калдырсынмы шулай?
...Ул сәгатен алды.
Сәгать ашыга.
Минутларны куа секундлар.
Йөрәк ашыга —
куа сәгатьне.
Куышалар Гомер белән Сәгать, —
бу тартышта узар
кем кемне?
Гомер тынып калса,
чабар сәгать —
галәм марафоны шикелле!..

Мәңгелектән чабар — мәңгелеккә!
Дәвам итәр бөек эстафета.

Гомер циферблатын кеше җирдә
секунд угы кебек кенә
үтеп китә!

* * *

«...Тавышы көчле иде... Баритон... Җырлый иде. Репертуар: «Безне чиркәүдә ярәштермәделәр», «Мин сезне сөям, сөям чиксез», «Варшавянка», «Тор, күтәрел, эшче халык!..»

*Н.К.Крупскаяның 1935 елда Баш мие институты анкетасына биргән җавапларыннан*

*

Әй җырлады җирнең баритоны,
күзен кысып, яңа Җыр башлады:

«Тор, күтәрел, эшче халык! — диеп. —
Кузгал, уян,
хаклык юлдашлары!»

Әй җырлады шундый — искитәрлек! —
Ярлы түгел иде репертуар! —
Ну җырлады! — ак-ком-по-не-мент-ка
«Аврора»дан
гөрселдәде туплар!..

Әй җырлады — кара сәмруг кошлар
әйләнгәләп төште байраклардан,
әй җырлады — капты яз ялкыны —
кояш керде
Кышкы Сарайларга!..
Әй җырлады, тавышы көчле иде —
гөлләр чыкты шытып, кызыл гөлләр!
Күтәрделәр җырны бишьеллыклар,
мартеннарда янган кызу көннәр!

Күтәрделәр забой чүкечләре,
кабатлады домна, ялкын сулап;
офыклардан офыкларга сугылып,
дулкынланды кырлар алтын сыман...

Әй җырлады — сөрген салкыннары
йөрәкләрне җырда берләштерде.
«Чиркәүләрдә ярәштермәделәр,
ярәштерде безне көрәш җыры!»

Җыр башлады.
Кушылдылар аңа
бар дөньяның эшче-инсаннары,
Җир яшьлеген балкып җырлады ул,
кушылды аңа
Кояш-шансонье!..

Җир утлары кушыла аңа янып,
дөрләп кушыла кояш факеллары.
Җырлады ул
миллион аваз белән
Революцияне,
ялкынланып!

*

Еракларда ни ул бер талпынды, —
аллеядан узды Төн шәүләсе.
Килә,
килә,
якынлаша Җиргә…
21 нче Гыйнварның
салкын дүшәмбесе.
Юлга чыкты, офык буйлап килә,
капшап килә бөтен йөрәкләрне.
Бара Гыйнвар, гүя ап-ак җанвар,
ак зынҗырга урап тирәкләрне.
Заставалар аша уза Шәүлә,
Кызыл майданнарны иңләп килә.
Диварларны үтә! Бар җиһанга
«Без Ильичсыз!..» сүзе кинәт менә
яңгырап китәр тиздән. Календарьда
калыр мәңге соңгы «Егерме Бер»…
Соңгы Гыйнвар, соңгы җанвар төсле
Мәңгелектән кире килерме бер?
Яңа иртә туа майданнарда —
күзләрендә яше
мөлдер-мөлдер…

Бас уртага, каршы төш юлына:
«Горкага юл,
Үлем
бу түгелдер!..»

*

...Менә Ул ята.
Кызыл табут —
Йөзеп бара...
Тугызынчы симфония
ут дулкыны булып агыла, агыла...
Ал байраклар шәүләсе йөзендә.
Акрын-акрын кызыл табутын
алдылар да иңгә күтәреп,
кызыл йолдызлы еллар,
үксеп, аны озата бардылар.
Күтәрделәр
иң өстенә алып
Глуховтан —
Сембергә чаклы.
Күтәрделәр иң өстенә салып Илләр өстенә.
Күтәрделәр аны
Байрак итеп
Кояшка!..

*

...Ишек төбендә
часовойлар алышына,
җырлый курантлар,
йолдызлар ява.
Баш очында
алышына еллар...
Агыла җанлы ташкын Ленинга.
Киңәшергә,
баш киемен салып,
бүрекләрен,
йөрәкләрен кысып учларына,
килә кешеләр,
агыла ташкын,

агыла колонналар
бу җиһанның бөтен почмагыннан...
Агылалар еллар һәм елгалар,
киләләр, киләләр, баш иеп,
кызыл йолдызлы еллар!
Килә шаулап Разлив каеннары,
килә Урал, килә Доннар аңа,
килә Илнең бөтен елгалары
дугайланып
Аның баш очына;
килә Аңа Сен-Дени бистәләре,
коммунарлар кайта Пер-Лашездан...
стенага терәп атылганнар,
Лена буйларында туң туфракны
кочып үлгән эшчеләр кайта;
киләләр бишьеллыклардан,
Мамай үрләреннән кайтканнар,
күтәрелеп исемсез гүрләреннән,
билгесез солдатлар,
исемсез калкулыкларны
кочып егылган баһадирлар,
яңа гына
Ай тузанын какканнар...

* * *

...Ул тәрәзә каршысына килде —
таң сызыла.
Тышта зәңгәр таң.
Тулгана кар.
Җирдән Гыйнвар бара —
аның өчен ява соңгы кар.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Соңгы Гыйнвар...
Юк!

Соңгы карлар кинәт ташкын булып,
Җирне юып китәр, соңгы кар...
Ерак түгел инде Ил язына,
карлар коеп чигенә
ак Гыйнвар.
Ашыктырма, үлем: табасы бар —
киләчәккә туры юл бармы?
Килә дә Ул, туры проводка
тоташтырып куя елларны.
Тора Ильич туры проводта,
аягында тора нык басып.
Шаулый язлар, еллар хәбәрләшә,
Ил йөрәге белән тоташып...
Ак легенда булып
килә карлар,
килә ак яу галәм ярыннан.
...Тора Ленин
тәрәзә каршында,
галәм десантыдай,
Мәңгелеккә
сикерер алдыннан.

*1980*

## *Болгар фрагментлары*

*(Археологик эскизлар)*

Туфрак катлам-катлам биредә —
Тарихның маңгай сырлары.
Бу ташлар, бу өлгеләр бары
гомер фрагментлары...

### I

Синең йөзне күрдем
Идел көзгесендә.

Син
кайчандыр
шушы биеклектән караган.

Көмеш әремнәрне ера-ера,
нигезеңә барам,
аякларга сугылып сыкрый ташлар,
балакларга сарыла сырлан,
ябыша тарих.

Таш баганалар,
имән бармак сыман,
өскә карый,
гүя алар
кояшны арканлаган.
Кояш сәгате!
Циферблатта — гасырлар.
Сәгать биредә бары
шайтан тәгәрмәче,
архаизм!

## II

Мин кая барам?
Кояш чыгышыннан
баешына чаклымы?
Мин тик бер кунакмы?
Җирем нинди —
көксел туфракмы,
акмы?

Кемгә таянам?

Минем моңнарны үзенә кундырган
тигәнәкме,
алтын куакмы?

Еракмы синең үткәнеңә?
Көткәнең нинди?
Кем нигезләре кемнәргә калмый,
уралмый утка кемнәр тәхете,
кемнәр бәхете...
Кем ярларын кемнәр кочмый?
Нинди кошлар
очмый кыйблага?..
Синең йөзне күрдем елгада.
Баш очында Итил-су ага...

## III

Уч төбемдә — бер чеметем туфрак:
ялтырый ком — гүя йөзек кашы!
Синнән калган ядкарь: янган бодай,
соры чүлмәк китеге,
орчык башы...

Төш вакыты.
Кояш бии!
Ауган диварлар артында —
орчык тавышы...

...Җырлый орчык сузып-сузып,
кыз кулында очып-очып,
сүсне сава кабадан.
Кылдан нечкә җепләре лә.
Үткән көннәр,
искән җилләр,
аккан сулар ярлардан.

Җырлый орчык очып-очып,
җептәй эрли көннәрне...
Җырлый орчык көн артында,
җырлый орчык ел артында.
Эрләнәдер җептәй сузылып
кемнәрнең гомерләре...

Орчык җыры — Иделдә.

Уза көннәр — җырлый орчык,
уза еллар — җырлый орчык,
зырлый-зырлый керә очып
күңелләрдән күңелгә...
Төш вакыты.
Кояш бии.
Ауган диварлар артында —
орчык тавышы...

**IV**

Туганым,
ыруым,

кандашым,
тыңлачы!
Көннең нәкъ кыл уртасында,
нәкъ түбәдә торганда кояш,
безнең көрәкләр,
синең капкаңны үтеп,
килеп төртелде
Ак Пулатың бусагасына.
Рөхсәтме?
Рөхсәтме
кагылырга акрын гына
ташларыңа,
кузгатырга урыныннан
Мәңгелекне?
Җавап бир!
Син каршы чыкмадың...
Тамды чыклары
Кунак өең өстендә үскән
кычытканнарның...
Синең нигезеңнән
коньяк-көнчыгышта,
бер-беренә башын куеп,
үсеп утыра иде
бер пар шәмәхә гөл.

Ни турында сөйли алар?

Әллә алар Мәхәббәт һәйкәлеме,
әллә тамганмы шунда
ике тамчы ал кан?
Дошман угын сындырганмы
шунда синең калкан?

Шатлык яшеме алар, әллә сагышмы?
Рәхмәтме, әллә бәддогамы,

каргышмы?
Әллә биредә бер сөңгедән
ике гашыйк йөрәк тынган?

Кылганнар,
ни булган?
Кылганнар эндәшми,
авызын йомган.

## V

Сөйләгез, кылганнар,
дала йомгагы — дуңгәләкләр!
Чабамсыз,
яулар төсле томырылып,
җилләр куенынннан эзлимсез
тынгылык?
Пышылдап сезгә ни сөйли комнар?
Үткәнгә чабамсыз?
Алай булса,
еракмы бирелән Вавилонга?
Тирәндәме Тубылгытау*?

Алырга кирәк әле тагын
ничә катлам?
Һәлакәт килде
　　　　кайсы яктан?
Тирәндәме ыңгыраша
яңа Пальмир**?

Вакыт —
бөек хаким,
җавап бир!

---

* Тубылгытау — Болгар шәһәрләреннән берсе.
** Пальмир — хәрабәләр шәһәре.

Тынлык.
Ташлар ята тынып.
...Жирән археолог,
пычагы белән телгәләп җилне:
«Бирелә...
Ак мунча булган», — диде.

Без ышандык —
елтыр пычак
кояшка тиде...
Ышанабыз!
Тарих антлардан көчлерәк.
Җир үчлерәк, көчлерәк тарихтан.
Бары да чөнки
җирдән калыккан.

Туфрак куенында —
байраклар, калкан,
таш китапка язган васыятьләр,
гөл балчыгына әверелгән
ал кан...
Ышанабыз: күтәрелә төптән
күгәргән булат, черегән көбәләр...

Ышанабыз.
Яланнар өстендә
бер минутта торды күләгә, —
ак тәпиле кояш
керде төрбәгә.

Әмма
ак сарайларны,
чуен капкаларны ватып,
Кояш-тәгәрмәчтә
алга чаба Вакыт!

Фиргавен укчысыдай көлеп,
сибелә җилдә
алтын чәче...

Вакыт гомере — мәңгелек.

## VI

Мунча ташлары ята таралып,
каралып чыкты болыт, эссе салды.
Койды яңгыр...
Ташлар чыжламады.
Алар салкын...
Янәшәдә генә яшь каеннар.
(Себерке исе белән тулды һава!..)

Калтырана зәңгәр кычыткannар,
шыбыр-шыбыр
яңгыр ява...
Табигать
кояш ләүкәсендә
җирне чаба,
җирне чаба!..

...Җирән археолог,
пычагы белән телгәләп җирне:
«Бирелә...
Ак мунча булган», — диде...

## VII

Биредә
команнармы күзләрен йомган,
әллә мәңгегә тынган
шөһрәтле кыпчаклар?

Тик бу нигә,
хәзер барыбер:
сөяк куллар ята
соңгы ташын кочаклап.
Шунысы кыйммәт —
җир өстендә булып киткән кешеләр:
игенчеләр,
тимерчеләр,
гаскәриләр,
даһилар…
Алар исеменә гимн булып,
кырлар тутырып үскән
көмеш арыш, алтын бодай.
Гәрәбәдәй яңгыр тамган
игелекле туфракка.
Алар иккәннәр шул туфракка
орлыклар гәрәбәдәй.
Вакыт урып алган
бу кырлардан
хәрабәләр…
Оя корганнар. Тереклек борнаган.
Булмасын өчен токым ач-ялангач,
агач төрән сөреп барган — кояшка чаклы,
җилләр эчендә туктаусыз биегән
чабагач.
Бөкре урак йөргән кырны урап,
учмаларны тезгән, куйган зурат,
ял иткән,
чормага кадалгач…

А, биредә нинди хөрмәт аңа!
Урыныннан кузгатудан хәтта куркып аны,
пумалалар,
бик сак кына, ялый соры тузанын…

Бәхеткә, бәлки, бик якындыр?..

Бик тирәндә түгелдер, бәлки, Шатлык?
Ләкин күз яшьләре
ни рәвешле ята туфракта —
бриллиантмы?
Җир астына күмеләме Хаклык?

Эзлибез: табылсачы бары
бер саплам җан,
бер йотым яктылык!
Кайда калган беренче Мәхәббәт,
Туу сулышы
яки гомернең
беренче һәм соңгы авазы?
Күрек сулышын терелтеп буламы,
дөрләтеп буламы сүнгән учакны,
чыгарып буламы
тирәндә калган язны?
...Көрәкләр төшә
туфракка
кыйгач...
Менә урам! Менә юл!
Күңелем чатларында —
Кояш!..

## VIII

Таң алдыннан
иел яшел калкулыкка,
колагыңны җиргә куй:
ишетелер, хәбәрләшә
Тубылгытау әтәчләре,
бер-беренә аваз бирә
җиһан хәбәрчеләре.

Оран китә җирнең дүрт ягына.
Җил кагыла
болытларның комач байрагына —
таң кабына!
Вал өстенә ишелеп килә иген гаскәре:
дулкынлана арыш сафлары,
шаулап килә бодай...
Бу — мәңгегә шулай.
Эленеп тора җиһан кыңгыравы:
вал өстендә —
тургай!

*1969*

## Бусага

*Әнием Мәйсүфә Мифтахетдин*
*кызының якты истәлегенә*

Хәтерләрне барлыйм менә —
Кем бар, кем юк, кем бар?..
Кара суда кемне юа бу дулкыннар?
Хәтер дигән бөек хаким ак киемнән
кайтып килә,
Хәтер дигән хәстәре дә ак төендә.
Каршылыйк, без, хәтерсезләр, каршы чыгып,
хәтерсезлек томаннарын кичеп.

...Түбәнә чаклы ачык калган ишек...

* * *

Бусагада торам менә. Кырыс хәтер
чакырмый да, кумый мине — үзең атла!
Онытkансыз! Йөрәгемнең уртасында

ярым ята иркәләнеп җиде ятка!
Бусагада торам менә. Уян, хәтер,
өмет белән килгән идем синең утка!
И бу хәтер, очадыр ла төтен булып...
Одиссеен онытмаган Пенелопа!
Геракл баганаларын гүя узып,
җир тирәли әйләндем мин гомер кичеп.
Одиссейдай, тугры булып, бусагаңнан
үтәр идем, Вөҗдан, синең хәлең ничек?
Бөек хәтер исән-имин, шөкер әле,
син, йөрәгем, ялгыз түгел, шуңа сөен!
Онытудан җаным өшеп калыр иде, —
Пенелопа онытмаган Одиссеен!
Онытмаган күкне — болыт,
киңлекне — җил, җирне — яңгыр яисә кар...
Җир убылсын, аның изге кайгыларын
бер мизгелгә онытмаган
пакь җаннар бар!

* * *

Ә без менә онытабыз,
калку туфракларга башны куеп,
онытмаска! диеп, яшь түгәбез
һәм... китәбез.
Өндәү билгеседәй, күз яшьләре
тама өнле туфракка,
Мәңгелеккә!
Ә үзебез
онытабыз җир хаҗәтен,
дуслар хыянәтен, әҗәтен,
тәмугын һәм кыямәтен.
Без — имансыз!
Җир хәтерли бугай
туган туфрак, искән җилләр,
кеше әманәтен, хыянәтен!

*

Бусагада торам. Агара җир,
хәтерләрне күмә сыман ак кар.
Хыянәтләр күмеләме, антлар?
Тырнакларың канаганчы актар!
Бусагада торам. Намусымда.
Булмый андый бусаганы атлап!
Ходайгамы, кемгә ялварырга,
гаделлеккә биргән антны хаклап!
Булмый онытуларны, хыянәтне аклап!

* * *

Тәвәккәлләп атлыйм бусаганы,
хәтер бара минем белән бергә.
Кая безнең антлар эчкән мизгел:
«Синең белән мәңге бергә... Гүргә...»
Кая хатирәләр? Уртак моңнар?
Бу җиһанның гөмбәзенә тиеп,
и тантана итә карагруһ:
«Онытырга кирәк вәгъдәләрне!..» — диеп,
ышанмадым кәррә сүзләренә,
дөрләде җыр, ахак учак булып.
Кәрлә җаннар шиңде яктылыктан.
Хаклык — юмарт, калды дардан йолып!
Сакла, Кояш, Ходам, хәтеремне,
сакла, Тәңрем, рухи наданнардан!..
...Ялган вәгъдәң, төренеп сәламгә,
килгән шыңшып үткән заманнардан!

* * *

Бусагада торам. Кемне көтәм?
Утлар көтә. Керәм. Утлар сүнә.
Ак тупыллар минем белән бергә,
хәтерледер алар, шуңа күрә:

жилләр, күбәләкләр,
дуслар кирә...
этләр өрә,
дошманнар да кирә,
«хәтерләре» бар бит — шуңа күрә!
Шундый чакта алар, «хәлне белеп»,
җиде төндә йокыларны бүлеп,
керә алар
ишектән дә
тишек-ярыклардан,
«дуслык» дигән ялган битлек
киеп!
Мин каршылыйм барын,
башым иеп...

* * *

Хәтер-суны кичтем. Бусаганың
ниндилеген үзем беләмдер!
Тәрәзәдән карыйм. Таллар боек,
боз астында ташбаш үлгәндер...
Таралды йорт. Йоклый песи (белми!).
Хиросима килде бу йортка!..
Йоклый ана, чал чәчләре тарау...
Вөҗдан гына уяу: «Онытма!..»
Тәрәзәләр елый!.. Күктә Җидегән
борып куйган таңга тәртәсен.
Тәрәзәдән карыйм еллар аша,
күтәрәм дә Хәтер пәрдәсен.
Таң сызыла...
Сарбай сырпалана,
сизепмедер тормыш үчешен?
Һәрбер төге белән тота әрвах,
аңлый ул да
якын кешесен!
Сагышларым күчә талларыма,

алар әле кышкы киемнән...
Ләгънәтләмә мине, кичер, язмыш,
бер кайтырбыз бозлы өеңә!..
Без дә әле, йорт иясен тыңлап,
шыпырт кына сызып шырпыны,
әфьюнны бер чакрым суздык, —
туган йортның калсын төтене!

* * *

Керегез сез, якты өметләрем,
керегез, дуслар,
сезнең өчен Хәтер-учак янган!
Керегез белеп — хаклык, хыянәтне
кемнәр кичә ала Бусагадан?
Баганалар ыңгыраша, ава,
Ыңгыраша капка күгәннәре...
Күләгәләр...
йорт Хуҗасы чыга,
бусагадан чыга күләгәләр,
күчә, чүгә,
чүгә-чүгә бии! —
и тантана итә күләгәләр,
и тантана итә! Биеп арыгач,
ак морҗага килеп сөяләләр!..
Тамак кырып, Хуҗа чыга йорттан,
(йортның рухы китә күченеп!)
Ана һаман юрый күккә багып
(сизә бугай Сират кичүен?..)
Язмышларда гүя Хиросима,
язмышларда — бөтен дөнья бар.
«Килдек-киттек» диеп әйтер өчен
бирелгән бит инде визалар!
Күңелемә кереп калдың, Сарбай,
чыгалмассың күңелем-ояңнан.
Кайбер дустан эт ул мең кат тугры,

дисәм, кичер мине,
и Аллам!
Җидегән якларына авышып бара
нинди җисем? Йолдызмыдыр, нидер...
Ераклаша бара, түбәләрен
моңнар беләш япкан
безнең өйдер...
Ана тавышы: «Ак күлмәгем кидер, кидер...»
Бусагада торам. Язмышымнан
онытылып калган тагын нидер...
Ишек кага кемдер...
Юк ла, җилдер...
«И мөкатдәс...»
үзәк өзгеч көйдер!..

*1987 – 1988*

## *Сәхипҗамал*

*(Дастан-поэма)*

Күр: ничек, иртә кояш чыкса,
җиһанга нур тула, —
Һәр күңелләр нурланадыр,
чыкса Гыйззәтуллина.

*Г.Тукай*

### I

### Ретроспекция

Казан өстендә болытлар,
гүләп тора ак диварлар;
Казан суы өсләрендә
оча көзге акчарлаклар,
тавышлары ташка үтә!

Петропавел чиркәвенең
чәукәләре кыш алдыннан
соңгы вираж ясый күктә...

«Юлларымда калыкканнар,
ничек өреп аударасы?» —
котыра җил. Очып бара
Сөембикә манарасы
гомерләрдән гомерләргә,
очып бара Тарих аша.

Күзге күктә кәрван-кәрван
теткәләнгән болытлары...
Идел күзгесенә карый
көзге Казан, туган Казан...

Казан берни онытмады.
Бер мизгелгә артка чигеп,
бүгенге көн үткәннәргә
урын бирә күз алдында:
...Вознесенский буйлатып
шаулый тояк тавышлары,
уза погонлы җайдаклар,
очкын чәчә дагалары...
Александр мәйданында
зеңләп куя өзәңгеләр,
укшым-укшым кан шикелле,
яфрак коя өрәңгеләр.

Рәшә кебек пәйда була
ютәлләгән кярханәләр,
сау эшчеләрне кайнаткан
иске сабын заводлары:
җил китерә Бакалтайдан
йөкчеләрнең авазларын...

Ай да, бизгәк тоткан кыздай,
карый моңсу чарлагыннан.

Агыла көфер почмаклары,
нотыклары, вәгазьләре...
ишетелеп киткән сыман
үткәннәрнең «Яшәсен!» һәм
«Долой!» дигән авазлары,
Ишетелеп китә чаттан
бутышникның сыбызгысы,
җигүле ат борылып керә
Мәскәвески урамына,
шагыр-шогыр көпчәкләре...
Апуш чүккән арба төбе...
Ил түрендә куылып йөри
фида җаннар, нәфис җаннар...
Бер тәрәздән моң агыла:
«Кем белер кадереңне и...»
Сәхипҗамал,
Сәхипҗамал!

### II

Казан өстендә болытлар,
гүләп тора ак диварлар,
Казан суы өсләрендә,
ерткаланган афишадай,
оча көзге акчарлаклар...

Утларын кабызды Казан,
бар көченә яктырды ул,
кемне көтә, кемне якты
тамашага чакырды ул?

Мәйдан тоташ сәхнә гүя,
рампа утлары кабынган...

Бер күләгә менеп килә,
килә Черек күл ягыннан,
тамак кыра, таяк тавышы,
үзе әле якынлаша,
күләгәсе, мәйдан тутырып,
узып китте мәйдан аша.
— Әй, чал карчык, син кем? — ди җил, —
Ә ул берни эндәшмәде —
хәсрәт эчкән Тугызакмы син?..
Учма-учма чал чәчләре
тузгып чыккан, ап-ак шәле
сыйпап килә мәйдан ташын.
Каберлектән киләсеңме?
Әй бичара...
Таяк тавышы
сыкрый мәйдан ташларында
бүгенгедәй.

Акрын гына, өрәк төсле,
атлаганы сизелми дә,
узып китте мәйдан буйлап
ак күләгә,
озын шәүлә
таягына таянган да...

Узды шәүлә, озын шәүлә,
ак диварларга елышып.
Аңа балкып карап калды
«Дворяннар җыелышы».

Узды уңга, узды сулга,
тыкрыктагы таш баскычтан
күтәрелде... Сөялде дә
язды һуштан.

Хәлсез бармак көчкә-көчкә
ак төймәгә баса алды.
Ачылып китте гүя дөнья.
Гүя тулы гасыр үткән,
гүя майдан аша түгел,
гасыр аша килеп җиткән.

Ачылып китте якты ишек,
өйдәгеләр шаулаштылар,
аягына сарылдылар:
«Синме соң бу,
Сәхипҗамал,
Сә-хип-җа-ма-ал?!»

Сәхипҗамал инде — Казанында!

### III

Күрче, нинди сәхнә Казан!
Декорацияләре дә
әзер килеш, тот та уйна —
бөтен Россияләрендә
бер генә ул моңлы Казан,
бер генә ул нурлы кала.
Кемнәр уйный, кемнәр елый,
кем көрәшә гомере буйлый,
үз йолдызын үрелеп ала!
Кемнәр сүнә, кемнәр түнә,
кемнәр күнә тук язмышка.
Шундый итеп уйнады ул,
балкыды ул мең балкышка!
Мохтаҗмыни ул алкышка?

Алкышлады аны заман.
Бүгенгә ул Казанында

үзе кайный! Кайнатты ул
миллионнарны заманында!

Волжская! Идел кызы!
Көтә Ижау бүген аны...
Мутиннар вә Кариевлар,
дер селкетеп бу дөньяны,
уйнадылар үз-үзләрен
бөек заман каршысында.
Иленә гашыйк җан-Таһирлар,
җан-Зөһрәләр — барысы да!

Сәйяр җаннар юлда әле,
Юлда — «Сәйяр» арбасында.
Бүген — «Сәйяр» арбасында,
иртәгә — «Нур» сәхнәсендә
үз-үзеңне табасың да,
юл тотасың яңасына —
гомер буе сәйярлеккә! —
«Әйдә халыкка хезмәткә,
хезмәт эчендә йөзмәккә».
Яфрак булыйк ярасына,
керикләче дәвасына!
Күрче, нинди сәхнә Казан!
Уйналадыр Яңа Заман.

### IV

Халык тарихында олы юлга —
зур сәфәргә чыга Театр.
Кан елатыр еллар алда синең,
юлың сикәлтәле,ерактыр!
Әмирханның киңәшләре истә:
милләт кызы, сәхнә — синең эш.
Куй, шауласын көфер почмаклары,

ирләр уйный хатын-кызлар ролен,
бүгеннән соң менә син тиеш!

Киңәшләре истә Галиәсгарнең,
соклануы истә Тукайның...
Сәхипҗамал, шул сәхнәдән гайре
ни шатлыгың синең, ни кайгың?..
Сәфәр чыкты Театр. Зур сәнгатьнең
почмаклары алда, түрләре.
...Кукшелләнә ерак офыкларда
Академиянең үрләре.

## V

— Сәхипҗамал, җиткән, күпме юдың
Апанайлар табак-савытын?!
— Бәлки, сине бай кияүгә димлик?
Иртә киден тормыш камытын.

Ыспай егет, кара мыек белән
чәчегезне бәйлик, үскәнем!..
(Сәхипҗамал сизә иңнәрендә
зур очышка канат үскәнен...)

Әрҗәсен бирмиләр,
кияүгә димлиләр,
бирмиләр киемен,
биклиләр йозакка.
— Җүнлерәк яшәрсең,
кияүгә бар, җүләр!
— Ачыгыз ишекне,
Һич кермәм тозакка!
— А, ничек байыйлар калфакчы кызлар,
нинди бай кияүләр баш имиләр!
Синең сүзне кәтә яучы-димче.

Карасана, син бит яшь, димиләр...
Килгән егет, бар да олы купкан,
бирнәләрең синең, һай, кичекте.
Тора да кыз: «Кияү — Театр түгел,
алыштырасым юк,
ач ишекне!

Ач ишекне, апа, кеше булсаң,
ач ишекне, көтә юллар алда;
ач ишекне, Тормыш, киң дөньяга,
ак канатлар үсте, тоям җанда!»

— Калфак бирәм сиңа, энҗелесен...
— Кагылма син, толчок, тиң түгелсең!
Театрмы, әфьюн сатучымы —
ачыкланыр — алда Көн беленсен!

## VI

Җыеныгыз,
көтә Мәдәният,
өч тиенгә тамак ялгасак та,
Син, Кудашев, сатма чалбарыңны,
бу вокзалдан алга бармасак та.

Җыелдылар «Сәйяр» әһелләре:
— Таралабыз, йә, хуш, Сәхипҗамал.
Спектакль кабул ителмәде,
акча бетте, рәт юк тамак ялгар.

Җыелдылар «Сәйяр» әһелләре,
Кариев та тирән уйга баткан.
Әлфиraктан әлмисакка илткән
Сәнгать юлы төшә, һай, кыйбатка!

— Җыеныгыз, көтә Мәдәният,
Локман, Ильяс, Кари, Гыйлаж, Барый.
— Сәхипҗамал туташ, сез — кыз бала,
Ир-егетләр ич без, безгә — ярый!..

Чалбар сатып түгел, ат сатып та
илтеп булмас иде вакытында
олуг сәнгать дигән кыйблаларга,
бу җигелү авыр — хакы шунда.

Ничек сезне саклап калыйк микән
ач-ялангач итми, Волжская,
Зөләйха вә Фәхерниса туташ?
Юлга чыктык,
иш беребез житми, Ильяс кая?

Берәм-берәм авыл, калаларда
сибелделәр, кушылдылар тагын.
Калмыйк әле, син биредә икән,
шул арбада, Сәхипҗамал җаным!
Бер арбада,
без «Нур» арбасында
киләчәккә үтик әле тагын...

*

Кышын кышлап, юлда җәен җәйләп,
килеп чыктык Өфе, Чиләбегә...
Чиләбедә уразага эләктек,
туры килер озак чиләнергә.

Ни эшләмәк кирәк, гөбернатыр
Рөхсәт бирер, бәлки, бераздан соң.
Ничәнче көн инде, ирексездән,
театр да тота «ураза»сын.

## VII

Менә... килеп җиттек. «Без — монда» дип,
яз афиша фәлән чатларга.
Ява яңгыр, арба тәгәрмәче
ыңгыраша ерак якларда...

Җаек, Өфе, Мәкәрҗәләр аша
бара ширкәт, җилдә тирбәлеп.
Бара Театр, кыен мәгърифәтнең
биштәрләрен иңгә күтәреп.

Бара Театр халык каршысына, —
кул чапмыйлар, дустым, җылыйлар...
«Сәхипҗамал, кайда Кариев?» дип,
аягыңнан егып сорыйлар...

«Без үзебез инде зур булдыкмы, —
без үзебез инде «Нур» булдык.
Нур төшәме бездән күңелләргә?
Нур булдыкмы, әллә... хур булдык?»

Сәхипҗамал, уйнап күрсәт әле
Искитмәле итеп тормышын.
Ир-егетләр чәчелә төрле якка,
ник атыңны туры тотмыйсың?

— Сәхипҗамал, кая китте Ильяс,
кая Мохтар, кая Тарханов?
— Олы юлда бар да,
уртак юлда
Театр ул бетмәс таркалып!
Бара Театр, чакрым баганалары
атылып кала озын юлларда.
Ярты юлын уза сәйяр булып,
әверелеп аннан нурларга...

Сәйяр була, күз яктысы була,
ил яктысы олы сәхнәдә.
И талантлы Тормыш-спектакль,
ия икән олы мәгънәгә!
Сәнгать бөек!
Түбәләре — күктә.
«Арыдым» дип, тешең агартма.
Барып җит тик,
шушы хакка соңгы
калфагыңны салып ломбардка*!

## VIII

Менә җәннәт!
Сәхипҗамалкаем,
чакыралар сине табынга.
Ташла театрны,
күч җәннәткә,
аша да эч ябь-яшь чагында!

Табын сыйлы. Сылу сине сыйлый,
күркә кебек бугаз киереп,

иркәчләре килә, шампан кайный,
коч ярларны,
яшә сөелеп!

Өстериләр аны сыйлы түргә:
менә тормыш, менә театр!
И замана, килмәдем табыныңа,
Тормыш — сәхнә, шуны күрә тор!

---

* Волжская ширкәт хакына калфагын да ломбардка салган булган.
*Артистканың истәлекләреннән*

— Фәкыйрьлектән сине йолып алам,
Менә шампан, кайный ак күбек!..
Син яшь кызсың, йөрмә дөньясында
гидайларны тәяп,
ат кебек!

Назлар кирәк синдәй нәзкәй билгә,
йомшак түшәк, сеңел, түшикме?
Күтәрелә,
тора ят куллардан
Сәхипҗамал:
*— Ачыгыз ишекне!*
*Ачыгыз ишекне сез*
*ак дөньяга,*
*Театрга, пәрдә, күтәрел!*
*Энҗе калфак дуслар башында дип,*
*Мәдәният таҗын йөртә бел!*
*Ачыгыз ишекне сез, мещан җаннар,*
*сезләрдән без сөяк көтмибез.*
*Ач булса да, горур безнең милләт,*
*без тән белән сату итмибез!*

*

Бара театр, бара төйи-төйи
юл уңае рухи байлыкларны.
Әкиятләр юл бирәләр!.. Әйдә
гизеп кайтыйк Мәскәү,
Җаекларны!

Узыйк әле алга, өфтанмаска,
юл яктыртып кыен чорлар аша.
Бу дөнья бит үзе бер театр,
халык рухы — үзе бер тамаша!

## IX

### Сәхипҗамалның ак шәле

Кыйбла йолдыз каршысында,
Җил-җил тибрәтеп чукларын,
чакыра, әйди оныкларын
биек, якты офыкларга!

Сәхипҗамалның ак шәле
ерак еллар томанында,
Киек Казлар Юлы сыман,
сузыла якты кыйблаларга...
Шул ак шәлне җилләр алды,
илтеп дәрьяларга салды,
мәхәббәте дәрьясына!

Төнне яктырткан шул ак шәл,
балкып татар дөньясында,
иңбашында сылуларның
якты сагыш, якты моңдай,
йомшак наздай сузылып ята,
җил-җил килеп чакыра алга!

Сәхипҗамалның ак шәле,
татар хатынының хәле
кара шәлдәй сөйрәлгәндә
инкыйлабка илткән юлда,
Сәхипҗамалның ак шәле
мәгърифәткә алып чыга.

Караңгылык патшалыгын
Үтәдән-үтә яктырта
якты образ — Катерина,
Сәхипҗамал — Катерина

ерак еллар томанында
тоныкланмас Хәтер инде.

Сәхипҗамалның ак шәле
Зур бирнә ул Көрәш-туйда
Ил кызының батырына
Сәхипҗамалның ак шәле!
Саубуллашып китеп бара
Ерак-ерак офыкларга...
Сагыну кала оныкларга.

Сәхипҗамалның ак шәле —
Пакь йолдыздай туташ шәле
ашып бара болытларга!..

Кемнәр уйнар яңасында?..

## X

Татар зиратында көз. Пәрәвез
керфекләргә сарыла. Барам шуннан —
эзләп соңгы йортын. Комач кызыл
карга миләшләре арасыннан.

Афишалар укып йөриммени —
укып йөрим ташка язганнарны.
Кариевта булам. Ә бер чатта
килеп табам Ильяс Ашказарны...

Төп нигездән ерак китмәгәннәр, —
күрше генә икән Тукай, Камал...
Өянкеләр шавын тыңлап ята
гастрольләрдән кайткан Сәхипҗамал
гәүдәләре бирегә. Шәүләләре
тормыш сәхнәсендә, күк чатында.
Көз саргаеп тезен чүккән, ул да

сәҗдә кыла Татар зиратында.
Зиярәт иттем мин дә күңелемнән,
фигылемнән мөмкин кадәресен...
Һәр калкулык — йөрәк уртасында,
чирәменә чаклы кадерле соң!

## XI

### Дога Фасылы

Халык күзендәге карындыкны
ачкан кебек,
шөкер,
сәхнә пәрдәсен иң беренче күтәрүчегә
багышладым,
кара мунчаларда, чыра кабызып,
театр сурәләрен ятлаучыга,
аң орлыгын, яктылыкның нурын
күз карасы кебек саклаучыга!

Багышладым
сәхнә колларына,
өйдән өйгә читек-калфак җыйган,
йөрәгенә кочак-кочак игелек сыйган
туташларга,
Беренче Театр улларына!
Багышладым Галиәсгар җәнабләренә,
«Сәйяр» ширкәтенә, аннан «Нур»га.
Кариевлар шәрәфенә, Кудашевка,
зобанилар җанны кыскан чорда
шәмнәр булып төнне яктыртучы
фида җаннар үткән кыен юлга!

Багышладым
беренче сукмакларда,

диндар әтиләрдән кача-поса,
рәеш киемен киеп,
кысыла-кысыла,
залга кергән беренче тамашачыга!
Багышладым,
шөкер,
бөек сәхнә хакына
читкә куеп тормыш нигъмәтләрен,
диндар күсәгенә каршы барган,
йөрәгенә йөз җәрәхәт алган,
чүпкә санап сарай зиннәтләрен,
халык мәнфәгате өчен янган
фида җанлы сәхнә йолдызына,
милләтебез кызына —
Сәхипҗамал ядкаренә!

Багышладым,
шөкер,
олуг мәгърифәт юлында
гөлтләп янган гомерләргә.
Яшәсен һәм чәчәк атсын
гомер бакый
Беренче Театр рухы күңелләрдә!

*1984*

## *Атлантида*

*(Яңа мөһаҗир)*

Тубый агач төбенә
Утырыр идем, солтаным.
Тубый агач көйләрен
Тыңлар идем, солтаным...

*Сабый чакта әбием*
*әйткән мөнәҗәттән*

*

Татар Иле, синме Атлантида,
Күп гасырлар эзлим мин сине?..
Ачы язмыш, табалмаслык итеп,
Үзгәрткәндер бары исемеңне...

Атлантида, бәгърем, эзлим сине,
Илне югалттыкмы гомергә?
Эзлим сине, сине упкан сулар
Дулкыннарын бәрә бәгырьгә.

Атлантида, син бит Татар Иле, —
Охшап калган, охшаш кабергә.
Кандашларның сары сөякләре
Кычкыралар төптән хәзер дә!

Атлантида, ерак Атлантида,
Телсез калган халык шикелле.
Тыны бетсә дә бит,
тирәнлектән
Дәшми ләм-мим...
Балык шикелле.

* * *

Бир фатиха, бабам, олы юлга,
Кайда минем нәсел-нәсәбем?..
Мин дөньяга килдем сезне уйлап,
Сезнең хакка янып яшәдем.

Син гүреңнән, бабам, эндәшәсең:
Кыйблалардан нинди хәбәр бар?
Безнең тарих җыеп алган уңыш
Харабәләр, бабам,
Харабәләр...

Болгар туфрагында өнсез калдым,
Ике учка кысып башымны:
Җаһил кяфер анда чиркәү салган,
Нигез итеп кабер ташыңны!..

Беркем тирмәсенә ут төртмәдек,
Хөсетлекне ни дип белмәдек.
Кабер ташын юкса нигез итеп,
Ай урынына тәре элмәдек!..

Халык көлгән чакта еламадык,
Халык елаганда көлмәдек...

Орчык җыры Болгар туфрагында,
Чулпы җыры сөйли ни хакта?
Исемеңне, татар, тот югары,
Кяфер белән кермә никахка!

Улый шакал
Тарих сахрасында:
«Татар, батар,
батар корабың!..»

Үләт козгыннары очкан чакта,
Син, кардәшем,
Синдбад кебек алга карадың!

Әкияттәге сыман
юлың буып,
Юлларыңа таулар өйделәр.
— Дөньялыкта сиңа зиндан булыр,
Кояш күрмә, пишке! — диделәр.

Татар барда хәтәр бар, дип, кяфер,
Күзең чокып,
Тарих даласына җибәргән...
А, ни хикмәт! —
Дошман каршысына
Килеп чыккан укчы — Җикмәргән!

Буең кыска, акылың сыек булсын —
Коршаганнар сине калыпка.
А, могҗиза! —
җаһил каршысында
Әверелгәнсең гигант Алыпка!
Сихерчеләр тарак ташлаганнар —
Юлларыңда баскан карурман...
«Карурман»нар җырың булып калгач, —
Таш йөрәгең, иблис, ярылган!
Сихерчеләр көзге ташлаганнар —
«Йотам!» диеп, туфан калыккан...
Тылсымыңа — тылсым: дәрьяң корыган,
Мөмкинмени
Хыянәтне яшерү халыктан?!

* * *

Атлантида,
Сине океан йоткан,

Убылганнар Атлантидалар.
Татар Иле,
Кояшларга тотынып,
Сине саклар
жаны фидалар!

*

Синең белән авырыйм ничә гасыр, —
Миндә — Атлантида авыруы!
Ул канымда минем ыңгыраша,
Авыруларга юкмы даруы?
Анам карынында чактук әле
Яшәгәнмен синең тәнеңдә.
Мин — бер молекула,
Бер күзәнәк, —
Сагынам сине шул ук хәлемдә!..

Сагынам сине, ерак Татар Иле,
Атлантидам минем, кояшлым!
Атлантида булып батма берүк,
Тәмугларга салма бу башны!

Йә, аваз бир, кыпчак,
кардәш коман,
Йә, аваз бир, үле мәмләкәт!
Йә, торыгыз, Биләр, Тубылгытау,
Тор, Жүкәтау, —
Сүзеңне әйт,
Калыйм канәгать!

Эзлим сине, Болгар-Атлантида,
Юк, малыңны түгел — жаныңны!
Офыккача
ут елгасы булып,

Көрәшләрдә аккан каныңны!
Эндәшегез, кандаш, нәселдәшләр,
Гомер буе көтә Ил-табын...
Сагынышкансыздыр,
еллар кичеп,
Изге туфрагыңа
кил, табын!

Үткәннәрдән бер моң кайта саркып:
— Тубый агач төбенә
Утырыр идем, солтаным.
Тубый агач көйләрен
Тыңлар идем, солтаным...

Ак күбәләк булып рухлар кайта,
Барлык ыру көйли бергәләп:
— Кораеш атлы еланга
Бездин күптин-күп сәлам,
Кораеш атлы еланга
Бездин күптин-күп сәлам!

* * *

Бер Ходаем гына, тик ул әйтер:
«Аваз бирдем сиңа, тел бирдем.
Явыз кавем аны кисә торды,
Үсә торды,
Сиңа гел бирдем!
Файдалан син аны, игелеген күр,
Сакла, татар, иблис-азгыннан,
Сакла, бәндәм, шайтан төкермәсен!..»

Тәкъдиреңә шулай язылган.

* * *

Кичке намаз. Кем ул җирне үбә?
Сәҗдә китеп чал бер карт тынган.
Болгар туфрагына ятып үкси,
Кайткан да ул
океан артыннан!

И әремнәр тибри талгын җилдән,
Иркәләнә җаннар бик соңлап.
Соң булса да, кичер, газиз туфрак,
Тәһлил әйтә кошлар сулкылдап!..

Кошлар канатының җилләреннән
Ак чәчләре, кылган шикелле,
Уйнадылар газиз ыруымның — мөһаҗирнең,
Җан авазы кырга сирпелде:

Йә, Ватаным, саумы!
Кайттым сиңа,
Күрәм сине яңа заманда.
Исән икән синең кәрваннарың,
Сарайларың исән һаман да!

Исән икән, шөкер, Колгалиләр,
(Гали затлар нигә кол булсын?!)
Ә Сөембикәң, Колшәрифләр юлы
Кәгъбә якка илткән юл булсын!

Тукайларың азан әйтә синдә,
Өлгер, ыруым, син дә азанга.
Тик без генәмени — кайта Хәтер,
Җиде гасыр кичеп Казанга*.
Кичке намаз. Дәрли Хәтер уты.

*Җиде гасыр кичеп — Явыз Иванның Казанны алуы күздә тотыла.

Сәҗдә кыла бөгелеп үләннәр.
Азатлыгың өчен үлгәннәр дә,
Хәер-догаң көтеп, ут каршына
Курпы булып шытып килгәннәр!

*

Җаһил җаннар, ягез, ук атыгыз,
Теләгәнчә җанны кыйнагыз, —
Иманыбыз таза, ут кошыдай*,
Колшәрифкә —
Барыр кыйблабыз!..


Баткан чакта коллык дәрьясына,
Җаның бәргәләнгән чагында,
Төрле кыйтгаларда дога кылган
Туганнарың булды янында —
Изге җаның
Кыл өстендә торган чагында!..

...Яшәсен лә мәңге халкым рухы, —
Гали, Рөстәмнәргә тиң бит ул...
Татарстан,
Төптән күтәрелгән
Атлантидам,
бәгърем,
син бит ул!

*1999*

* Ут кошы — легендадагы көлдән яралган Феникс.

# Балладалар



# *Таш елады*

Кешеләр!
Кичерерсез,
Хиросима
Сагышын җырласа үзенең.
Беләсез, сезгә дә моңы кагылыр
Йөрәктә калган яра эзенең.

*Япония шагыйре Таконуриг Симидзу,*
*«Хиросима җырлары» җыентыгыннан*

## I. Диңгез яры

Тыныч кына туды бу таң,
Уйсу җиргә томан ятты.
Шул таң белән канат җилпеп,
Оясына лачын кайтты.

Очып кайтты җитез лачын,
Балаларын сагынганга.
Шатланды ул ана булып,
Алар канат кагынганда.

Сокланды ул аяз таңга,
Оясына бикләнмәде.
Күк гөмбәзе — ефәк чатыр, —
Бернәрсәдән шикләнмәде.

Диңгез сакчысы кыялар
Болытларга гүя тоташ.
Давылдамы шул кыядан
Аерылып төшкән зур таш.

Батып кергән дымлы җиргә,
Исе китми ята бер дә.
Җайлы аңа шул тау төбе,
Яшелләнеп тора мүгә.

## II. Балыкчылар жыры

Киң офыкка менгәч кояш,
Алтын нурлар кунгач тауга,
Ишкәкләрен кулга тотып,
Балыкчылар чыкты ауга.

Балалары, хатыннары
Өмет белән калды ярда.
Балыкчылар жыр башлады,
Кушылдылар дулкыннар да:

«Диңгез, диңгез, бер чакны без
Яшәрбезме уңай гына?
Балык итеп сөзсәң иде
Бәхетне дә шулай гына.

Кара болытлар йөзсә дә
Өстә, тормыш күгебездә,
Бәхетле көннәр — хыялда
Өмет сүнмәс күңелебездә!..»

## III. Сизмәделәр

Кыядагы житез лачын
Оясына бикләнмәде,
Диңгез тыныч иде аста, —
Бернәрсәдән шикләнмәде.

Шикләндеме язмышыннан
Тыныч йортлар, сулар яки,
Якты нурларда коенып,
Балкып торган Нагасаки?

Шикләндеме язмышыннан
Шаулап торган Хиросима?

«Помпей төсе керә сиңа!» —
Димәс иде оракул да, —
Белмәс иде моны ул да...

Оядагы күгәрчендәй,
Бишегендә ята сабый.
Стенада сәгать теле
Соңгы минутларны саный.

Бу тормышның капкасы бер,
Капкасының юк шул биге:
Булә алмый коймалар да
Яшәү белән Үлем чиген.

Тыныч кына оча лачын;
Балыкчылар жыры тынмый.
Шушы жырны Таш та жирнең
Күкрәгенә ятып тыңлый.

Дәртле жырның өзеләсен
Сизмәделәр шул алар да:
Корбанга һәм канга сусап,
Үлем килә очып ярга!

### IV. Уран

Сорамады: «Кемнәр бу?» — дип,
Кызганмады жирне Уран, —
Кадалды да, кинәт улап,
Күтәрелде кайнар буран.

Бер секундта булды бу хәл,
Жилләр алдан белдермәде.
Бишегендә яткан сабый
Еларга да өлгермәде.

Кая монда җир белән күк, —
Тоташ булып дөнья дөрли!
Җирнең канлы ярасыннан
Бәгырьләргә ялкын үрли.

Кем ташлады сине җиргә,
Җирнең нинди явыз улы?
Сине аткан чакта аның
Ничек тартышмаган кулы?

Кешелекне юк итәргә
Тудырдымы сине Кеше?..
Төзегәнне җимерүме,
Яндырумы аның эше? —
Шундамыни аның көче?!

### V. Таш елады

Бәрдеме диңгез төбенә
Миллион потлы тимер чүкеч, —
Нигә кинәт тетрәде җир,
Каян килгән аңа бу көч?

Төпкә китте балыкчылар,
Җирдән мәңге аерылып.
Лачын төште оясыннан,
Канатлары каерылып...

Моны күреп кеше түгел,
Таш та сыкрап сулкылдады.
Ул тетрәде газаплардан;
Таш елады,
Таш елады!..

### VI. Жыр тарала

Жыр яңгырый көнчыгышта,
Тын ярларга җәелә моңы;
Балыкчылар гына түгел,
Япон халкы жырлый моны.

Тирбәлә ул Янцзыда,
Шаулый Ганга өсләрендә.
Тынгы белми үлемсез жыр,
Көндезен дә, кичләрен дә...

Тарала жыр ачы үлем
Шәүлә булып йөрмәсен дип,
Хиросима сөремнәрен
Дөнья кабат күрмәсен дип.

Калкып чыккан яңа шәһәр
Хәрабәләр арасыннан;
Вакыт-вакыт, җилләр чыкса,
Сыкрап куя ярасыннан.

Мәрмәр тәнен дулкын юган
Таш кыялар тора сакта.
Оясына ашыга Лачын,
Көчле җилләр искән чакта...

Сарып ала балалары
Аны очып кайтуына...
Аста, яшел мүкле Таш та
Риза тыныч ятуына.

*1956*

## *Соңгы танк*

### I

Кар сулары белән шаулап
Юылгач та киң үзәннәр,
«Яшәү!» диеп атакага
Күтәрелде яшь үләннәр.

Окобыннан чыкты солдат,
Мылтыгына дары төеп,
Көнбатышка кургаш катыш
Ләгънәт узды кара көеп.

Мең каргышны төяп очты
Нәни генә шул бер кургаш.
Мең ләгънәтне күтәралмый,
Сыгылды да төште бер баш.

Кара жиргә чүкте фашист,
Үзе белән тәре төште...
Шул гынамы? Баш очында —
Ни әйтерсең? —
Тәре үсте.

* * *

Күрә кеше: туфрагымда
Яньчек гильза аунап ята.
Көнбатыштан очып килгән, —
Үз хәлен ул аңлап ята...

Ах, син, чучка! Тамгасы бар, —
Рур ягында «пешкән» икән.
Җимешнең бу тик кабыгы,
Төше кайда төшкән икән?

Баш очында бер гомернең
Тагын ниләр үскән икән?..

Шул яньчекне алып кеше
Яңгыр суын өстәде дә
Комач гөлләр өзеп куйды
Землянкасы өстәленә.

Шул гильзаны койган куллар
Күрсә әгәр бу «хөрмәтне»,
Уйлар әле: бу солдат, дип,
Ижатыма мәрхәмәтле!..

Көзге җилдә тетрәп сүнде
Землянканың соңгы уты.
Китте кеше. Гөлләр өчен
Булырмы бу соңгы йокы?

Киткән чакта, кипкән гөлне
Угалады уч төбендә.
Көзге җилдә гөлләрнең дә
Соңгы тыны очты менә.

Сәлам язган җылы куллар,
Уйламыйча, болай гына,
Гөл орлыгы сипте җиргә
Чыгып китү уңаена.

Алда — бәрелеш. Карталардан
Карандашлар аныклады:
Фәлән сәгать, фәлән үрдән
Күренмәгәе
танклары.

Калкып чыкты! Окулярда
Үрмәлиләр, зураялар.
Секунд саен нинди чиккә
Якынлаша шулай алар?!

Чиккә житте! Күтәрелеп
Корыч тауга кеше бара.
Корыч тауга якынлаша
Барган саен үсә бара!

Тәгәрмәчләр ут бөркеде,
Киерелеп тәпәләгәч.
Шәп утырды! Инде бүтән
Көнчыгышка тәгәрәмәс!

Тыныч таңда сез, кешеләр,
Сокландыгыз матурлыкка.
Танкларга каршы баса, —
Гөлләр әзер батырлыкка.

Эһ тә итми сытып узгач
Шул гөлләрне, ялкынланып,
Барган ходтан сикереп алды
Албастыдай корыч танк.

Талпынгандай булды соң кат, —
Соңгы өлеш сыртка төште.
Борылып янды көнбатышка
Яраланган сыртлан төсле.

Борылды ул аңлагандай, —
Дөрлим, имеш, кем жилендә?
Корычкамы акыл керде, —
Каберем, имеш, кем жирендә?..

* * *

Түтә белән каерып, солдат
Ватты зиндан ишекләрен.
Максатына төгәл житте,
Язмышына кичекмәде.
Тик күрмәде ул гөлләрнең
Үлемнәргә үч иткәнен:
Жир күкрәген тыңлагандай
Ятты жирдә. Тик гөлләрнең
Рәхмәтләрен ишетмәде.

Шул землянка ишегенә
Шаку белән жылы жилләр,
Яз кулыннан мәңгелеккә
Эстафета алды гөлләр.
Ничәнче ел солдат йоклый
Баш очында — кызыл гөлләр...

Ничәнче ел күзен йоммый
Кызыл гөлләр,
Кызыл гөлләр!..

Иңе төшкән карчыгадай,
Юл чатында танк тора.
Кем оныткан, шул карасын, —
Тамгалары анык тора.

Дансыз юлда танк сүнгән,
Гөлләр һаман
Янып тора!
Мәнсез корыч беләме соң
Үз язмышын алдан танып...
Булыр микән бу дөньяда
Соңгы танк,
Соң-гы танк?..

*1960*

## *Ак чәчәкләр*

Ак чәчәкләр!
Ак чәчәкләр сибелә,
гыйнвар чәчәкләре!
Ак каенның төшенә керә
җәйнең рәхәтләре!..

Пар акбүз ат чабып узды җир өстеннән,
Ак ялларын тузгып кунды яланнарга.
Ак чәчәкләр уйнап төшкән ал таңнарда,
Яшь бер сылу мохтаҗ иде сәламнәргә!

Көмешләнеп кыш чигенгәч яланнардан,
Ак чәчәкләр чыкты анда — ап-ак өмет!
Кайтырына ак чәчәкләр өзгән таңда
Ил күгенә карап ауды батыр егет.

Язгы кабыну белән сулап, соң мәртәбә
Ярсыды да Идел чыкты ярдан ташып.
Ак каенның куенына атылды кыз,
Кулындагы чәчәкләрен суга чәчеп.

Киң Иделгә ярсып төшкән кыз йөрәген
Күренә салкын дулкыннарның тибрәткәне.
Гомерендә тәүге кабат, чәчәк булып,
Агып китте кыз баланың теләкләре!..

Яшен уты күкне җиргә тоташтырды,
Киек кошлар атылып керде томаннарга.
Ак бәхетләр явар таңда, кырыс җилләр
Игълан итми басып керде урманнарга!

Киек казлар кагынып кайтты күлләренә,
Сагынып кайтты илнең батыр егетләре.
Каберендә яшь егетнең — ак чәчәкләр, —
Кыз баланың шытып чыккан өметләре!

Ак чәчәкләр ява җиргә, ак чәчәкләр! —
Кыз баланың суга киткән бәйләмнәрен
Океан суы кайтарган да болытларга,
Кыш уздыра ак чәчәкләр бәйрәмнәрен...

Салкын карлар туган җирне җылыта гына,
Истәлекләр ап-ак итә батыр юлын,
Яшь сылуның йөрәгендә җылына-җылына,
Мәңгелеккә дастаннарга кайтыр юлын!

*1962*

## *Дала хикәясе*

Әлсерәп ята комнарда
күзеңне имгән дала...
Килде дә төште далага
каладан ике бала!
Чемоданнарында — диплом,
башларында — эшләпә...
Далага карап тордылар:
— Менә язмыш нишләтә!
«Уф» дип куйды шунда берсе,
егетнең төзе иде.
Егетнең «уф» яңа җирдә
беренче сүзе иде.
Әйттеләр, имеш, бу якта
әфлисун үсә, диләр,
йөземнең дә иң затлысы,
татлысы пешә, диләр...
Зәңгәр үзәннәрне юган
дулкыннар кая икән?
Бу җирдә асыл гомернең
үткәне зая икән...

...Шаулашып чапты вагоннар
көнбатыш якка табан.
Вагонда тирбәлә егет,
башында уйлар яман.
Тирбәлеп кайта вагонда,
баш вата җавап эзләп:
«Үзем теләп бардым юкса,
бармадым савап эзләп.
Әйттеләр, имеш, ул якта
әфлисун үсә, диләр.
Дәрья суларына тиеп,
йөземнәр пешә, диләр...
Сагындым туган шәһәрем,
уйласаң, күңел тула...»
Паровоз «уф» дигән саен,
егеткә җиңел була!..

*

Аерылып якын дустыннан
далада йөргән егет,
дустының яшьле күзләрен
ерактан күргән кебек.
Берсүзсез генә адымлап,
кузгатып йөрде комны.
Тубылгы үскән әрәмә,
гөлләрнең күзе дымлы...
Хат язды утырып яланда:
«Искиткеч көннәр монда.
Күгәрчен түше шикелле
шәмәхә гөлләр монда!..»

*

Арыклар чаба ашкынып,
өр-яңа юллар эзләп;

шәмәхә гөлләр чайкала,
даланың түшен бизәп!
Йөземнәр менә сарылып
иңеңә — назлау сорый;
йөземдәй күзләр, көндәшен
күрмәгән була юри!
Айваларга алтын суы
йөгергән кебек була;
егет үзе дә, үзе дә
өлгергән кебек була:
балланып төшә түшәккә
йокысы белән бергә.
Рәхмәт пышылдый иреннәр
ганимәт биргән җиргә.
Куллары тынмый, йокыда:
йөземнәр өзә, имеш,
хезмәте белән һавага
йолдызлар тезә, имеш!..
Җил белән дала түреннән
«уф!» дигән тавыш килә.
Әйе, бу — качкан иптәше,
бу — «иске таныш» килә.
Ул бара, төнне кармалап,
билгесез сукмакларга.
Ул китә, кулын кушырып,
еракка, еракларга...
Ул эзли әзер бәхетен,
хөрмәләр үскән җирне,
авызына, балдай тамып,
йөземнәр төшкән җирне.
Әйе, бу — аның иптәше,
бу — иске таныш килә.
Җил белән дала түреннән
«уф!» дигән тавыш килә.

*

Арыклар җырлаган җирдә,
йөземнәр пешкән җирдә,
дала бизәгән дус белән
чәй эчтек икәү бергә.
Арыклар чаба ашкынып,
өр-яңа юллар эзләп,
шәмәхә гөлләр тирбәлә,
даланың түшен бизәп.
Йөземнәр менә сарылып
иңеңә — назлау сорый.
Йөземдәй күзләр, көндәшен
күрмәгән була юри!..
Дәшәргә кушты шул егет
килсен, дип, кунак булсын,
кулына урын тапмыйча,
«уф!» диеп йөргән дустын!..

*Әстерхан – Казан, 1960*

## *Янгын сүндерүче турында*

Офыкларда — ажаганнар.
Биткә черки кагылса да,
«Ут мөдире», сикереп торып,
менә иде каланчага:

«Көек исе
килә төсле, —
иснәп карый, —
нәрсә яна?..
Ажаган ла!..»

Клеверлы арба төбе —
түшәк аңа!..

Караңгыда ат пошкыра —
Байкал, әллә Алмачуар?
Сизделәрме берәр хәлне —
капка ачып, юлга чыга...

...Мөлдерәмә су чайпала,
дугаларда — кыңгыраулар!..
Түбән очта шаулый халык:
«Карап торып яндыралар!..»
Шаулый халык: «Хуҗасы кем,
бу атларны кем җигә соң?
Күрегезче,
тәгәрмәчкә
уралган ич дилбегәсе!..»

Һәм
Галәви сикереп тора,
күзен уа, исенә килеп:
яңгыр узган —
ераклаша
суы беткән
мичкә кебек,
күкрәүләре ераклаша,
китеп бара
дангыр-доңгыр!

Салкынча җил йөзне сыйпый,
чут-чут! килә
сирәк яңгыр.
— Ну үткәрде үзәгенә!
Бер булса да —
берәгәйле!

Әй сусаган иде туфрак...
Рәхәтләнде
бәрәңгеләр!..
Инде берне төрми булмый, —
махра сала янчыгыннан, —
монысы батыр калган өчен
бүләк иде карчыгымнан,
егет чакта, сабантуйда...
Чигелгән ул ука белән...
Ничәнче ел дәү абыең
алышып йөри
утлар белән!..
Утлар белән көрәшкәндә,
әле һаман батыр гына;
аргы очка, бирге очка
Галәвине чакыр гына!

* * *

Чакырдылар аны беркөн.
Ерак юлга... Тик бу юлы
арбаларсыз,
мичкәләрсез
чакырып алды
аны быргы!
Өскә шинель кидерделәр,
будырдылар билгә каеш:
«Уйнамасалар ут белән,
ни җитмәгән, панимаешь?!
Ни җитмәгән?»
Шул сораудан
Галәвинең җитди йөзе...

Стансада карап калды
Мәрфуганың
ике күзе!

Шул ике күз: «Кайт, — ди, — тизрәк!
Тизрәк сүндер янгыннарын!»
Сагыну төяп утка керә
вагоннарың,
адымнарың...
«Тизрәк сүндер янгыннары-ы-ын!» —
Бик ышана Галәвигә,
чөнки белә:
ут җиңгәне тик бер иде
әллә нигә!..
Юк,
тикмәгә кагылмады
каланчада иске плуг...
— «Ут мөдире» ятсын менә
окобында, мескен булып!..

Мал-туарлар,
каралтылар,
өйләр яна күз алдында...

Өй генәме?
Илләр яна!
Син ят, имеш, кузгалмый да!..

Мал-туарлар,
каралтылар,
алмагачлар —
чатыр-чотыр!
Дөрләп яна... «Тор, Галәви,
кешеләрне
чакыр, чакыр!..»

Алмагачлар очкын ата,
өйләр яна
күз алдында...

Өй генәме — илләр яна!
Син ят, имеш,
кузгалмый да...

Өйдә булса, оятыннан
качар иде мичкә кереп!
...Алмагачлар шартлап яна,
кыршау аткан мичкә кебек!..

Әй йөрәге кычкыра ла,
Үзе белә авыртканын:
— Әй егетләр, карап торып,
яндырабыз Европаны!

Карап торып яндырабыз,
карап торып,
нинди җаннар?!

Кагасы иде эреле-ваклы
дөньядагы бөтен чаңга!

Сикермәсен илдән илгә
«кызыл әтәч» һәр тарафка.
Тартасы иде гаеплене
гомере җитмәс штрафка!..

* * *

Күпме авыл, күпме шәһәр
янды, янды көпә-көндез...

Узды давыл. Узды да ул —
кайгыларын сүндерегез,
кайгыларын!..

Җир йөзендә нинди су бар,
Нинди дәва, нинди үлән?
Сүндерергә мөмкин микән
Кара Сыер сөте белән?

Ярый, әйтик, ут төртүче
үз утында үзе янды:
ләкин ничек кайтарырсың
җиргә килгән ул зыянны?!

* * *

Офыкларда аҗаганмы,
әллә күкрәү авышып киткән?..

Сугыш шулай көнбатышта
үлеп бара,
тавышы беткән...

Мәрфуганың тәрәзәсен
зеңләттеләр язгы җилләр...
Ил улларын барлаганда,
дәшмәгәннәр кайбер ирләр.

Ил улларын барлаганда,
исемен әйтеп, әллә нигә,
хәрбиләрчә, җәһәт кенә:
«Мин!» — димәгән
Галәви дә...

Эндәшмәде. Дымланды тик
ярым йомык керфекләре:
дөрли иде ахакланып
рейхстагның
өрлекләре...

* * *

Галәвинең оныклары
аваз бирә инде өйдә...
Төтен исе сеңеп беткән
бүреге тора көтеп чөйдә...
Аваз биреп туа кеше,
кара җирне сөрә, чәчә...
Янгыннар күп, бу дөньяда —
һәркемнең үз каланчасы!
Ул кайтмады...
Тик, «исән» дип,
юраудан да
нинди файда?..

...Йөри, диләр,
пожарларны
сүндерешеп
әллә кайда...

*1972*

## *Гармун турында баллада*

### I

Тарих мең дә тугыз йөзнең
Кырык бише маенда...
Уйнады герман гармуны
туган як тугаенда!..

...Уйный солдат: башын кырын
салып сөйкемле генә,
«эш беткәч, уйнарга ярый»
дигән шикелле генә.

Гаҗәпләнде авыл: «Моңа
сыйгандыр җирдә бар моң...»
Сугышта хуҗасы ташлап
пленга төшкән гармун
уйнады уфлап, сулкылдап,
сөйләде бөтен зарын,
тыңлап торсын аны барлык
җирдәге гармуннарың!..

Сузылды, кысылды сулап,
тартылды күрекләре! —
Биегәеп китте өйнең
матчасы, өрлекләре!

Күккә менде түшәмнәре,
җиргә иңде идәннәр.
Бу җыр — сезгә — сагынганнар,
сезгә — янып сөйгәннәр!

Йолдызлы капка төбенә
җыйналды бөтен авыл...
— Гармун белән кайткан
Гаяз,
вәт егет, ичмасам,ул!

**II**

Тынып калган иде гармун
олы сугыш кырында.
Таптылар аны якташлар
дошман блиндажында.

Дошманда җыр кайгысымы,
бер мәгънә бардыр монда —
күрәсең, җыры җырланган,
ташлаган гармунын да!

Ялтырап тора маркасы,
язылган алтын белән.
Уйнагандыр «Нах Остен»*ны
дәрт белән, ялкын белән...

— Изеп ташлыйк —
көч биргәндер —
«Убер аллес»** җырына;
кушылып уйнагандыр әле
Фашист оркестрына!
Берсе әйтә: «Егетләр, — ди, —
причем гармун монда?
Шунысы кыйммәт: гармун
инде
Уйный бит кем кулында?!»

Кушыла Гаяз: «Әйтмәсәң дә —
ни гаебе гармунның?
Кем кулында — шуны
тыңлый,
тартмасы ул бар моңның!

Аңа кирәк, якташлар, ди,
татарча өйрәтергә...»
Ала да сыза гармунны, —
телләре кылә телгә!

Моң дигәнең, ул, егетләр,
карамый бернигә дә.

Карагыз, әй, матур итеп
Әйтә безнең көйгә дә!

---

* Н а х  О с т е н — көнчыгышка.
** У б е р  а л л е с — барыннан да өстен (*фашистик Германия гимныннан*).

Биетмәкче иде фашист, —
эшләр китте тыгызга!
Инде үзен биетәбез
Үзебезнең кубызга:

— Бас, бас, басарак,
фашист-мәлгунь бик карак.
Оясында тотылган,
гармун биреп котылган.
Бирмәгән лә, ташлап
качкан!
— Котылмаган, сытылган!
— Сыздыр әле, Гаяз якташ,
«Зиләйлүк»не, «Сарман» ны,
туган яклар ишетер булсын
без ничек сагынганны!
Безнең илнең егетләре
житте Гитлер башына...
Сип әле бер моң суларын
жанның кызган ташына!

Сайрады гармун телләре,
сайлады барча көйне...
Яңгырады — тарих шаһит —
Берлинда «Арча көе»!

### III

Хәтерлим (ул еллар тәмен
еракка киткәч беләм!)
кайттылар сугыштан:
берсе —
«сугышчан иптәш» белән;

берәүләре алып кайтты
сафташын, полкташын...

Булды ул кәләш белән дә
кайтканы култыклашып;

берәүләр агач аяктан...
кайттылар зар-моң белән...
Гаязны утлар аяды —
һәм кайтты
гармун белән!..

Киереп тартса күреген,
шуннан көч алган төсле.
Калмагандыр шул гармунга
биеми калган кеше!

Ду килде сабантуйлары,
аллы-гөлле сөлгеләр!
Шул гармун моңына басты
сөлек сынлы сеңелләр!..

## IV

...Капка төбендә утыргыч.
Җәйге кич. Авыл башы...
Кырык ел гармуны белән
күрәм мин авылдашны.

Сырып ала күрше-күлән, —
кемгә урын тар монда?
Сыза Гаяз җиңү җырын
шул трофей гармунда!

Уйный гармун — агара чәч,
тын гына ага инеш.
Күпме гомерләр югалды
Яшәлми калган килеш!..

Хәтерендә салкын окоплар,
исендә җиңү маршы...
Гармуны кырык ел тоташ
җырлый сугышка каршы!

Ничәнче кат сулкылдый ул
чал ветеран кулында?
Уйный гармун — алсу гөлләр
чәчәк ата болында.

Уйный гармун — тынып тора
күңелдәге сагышлар...
Уйный гармун —
дулкынланып
серкә кага арышлар...

Уйный гармун — җырлый
солдат,
йөрәгеннән сүз алып!
Уйный гармун — пешә җиләк,
яшел тауда кызарып.

Уйный гармун — шаулый
бодай,
сайрый тургай, чөелеп!
Уйный гармун — җырлый
Йөрәк,
Тыныч таңга сөенеп!..

Уйный гармун — җырлый
солдат, —
киң офыклар яктыра!
Уйный гармун — бар илләрне
дус яшәргә чакыра!

Уйный гармун — нур өстәлә
Тынычлык кояшына,
бар халыклар йөзен бора
азатлык кыйбласына!

Уйный гармун — аяза көн!
Уйнасын, тынмасын да...
Аңа кушылып, җирдә бөтен
гармуннар уйнасын ла!

Уйнасын Тынычлык көен,
сугышлар булмасын ла!..

*1985*

## *Яралы арыслан*

### I

Буй-буй камышларга посып кына,
Күзли иде кунган кошларның
Үз телендә нидер сөйләшкәнен,
Пырхылдашып читкә очканын...

Өч сөңгедән үзе исән калды,
Ядрәләр дә үзен алмады.
Килде бер көн: джунгли ешлыгында
Канлы аягын улап ялады...

Ике күзе төнен ут шикелле
Күзли иде камыш арасын...
Ырлый-ырлый күкрәк тавышы белән,
Ялый инде канлы ярасын.

Тар сукмаклар буйлап, суга диеп,
Бәтиләрнең күлгә килгәнен
Көтә иде (бәйрәм көткән кебек!).
Гөрләп яшәү иде исәбе...

Исемен дә аның сорамады,
Сукыр ядрә екты батырны...
Ядрә түгел,
Вакыт егып салды
Җәнлекләрнең
Императорын!

## II

Йөрәк тибә! Күзләр комсыз яна!
Теләк әйди, — аяк күтәрми...
Ак бәтиләр тагын күлгә бара
Бамбук куаклары үтәли.
Су тавышы! Анда бүтән хаким,
Биләмәләр кала барысы...
Бөтен тропик аңа ачыла иде,
Күкрәү булып торды тавышы!..

Тырнакларын тартып тәпиенә,
Күпчекләргә басып сөйкемле,
Җилә иде җәйран артларыннан
Котылгысыз үлем шикелле!..

Кайчан гына аннан өркеп качкан
Җәйран бәтиләре һәммәсе
Яннан гына уза уйнаклашып...
«Ах, япь-яшь кан тибә янәшә!..»

Биешәләр алар, кылыч кебек
Мөгезләрен чарпып мөгезгә:

«Рәхмәт, вакыт! Син картайттың аны,
Юк, куркыныч түгел ул безгә!»

### III

Белмәде ул кургаш кисәгенең
Кагылып кына киткән икәнен.
Нәфрәтләде бары ядрәне ул,
Ярдәм көтте күктән, инәлеп!..

Аңа шул уй җиңелрәк тә иде —
Килер бер көн — яра төзәлер...
Вакыт-вакыт йөрәк сикереп китте,
«Картлык» дигән сүздән сискәнеп!..

### IV

Арысланнар! Джунгли корольләре!
Крокодиллар, шайтан алгыры!
Ишетәмсез? Бөтен илләрегез,
Күлләрегез дөрләп янгыры!

Тавышыгыз кайда? Әллә юкса
Мин соңгымы безнең нәселдән?
Картлык түгел, юк ла... яра екты,
Санамагыз әле көчсезгә.
Император булам мин сезгә!..

*1958*

## *Атылган кош*

Әрәмәләр өстен чуарлатып,
көзге салкын юган үләннәрдән
күтәрелде кошлар, саубуллашып,
шушы җирдән... Якын-тирәләрдә
шыелдады канат тавышлары;
кошлар белән кошлар кавышканы
күтәрелде изге сәлам булып,
чеңләп торган зәңгәр биеклеккә...
И тормышның шигъри канатлары, —
туеп булмас сөеп, сөелеп тә!..
...Кытыкланып күңеле, кыл шикелле
Бер тармакка кунды кара тургай*.
«Бәхет мине шулай җиңел итә, —
Бу тармак та чыдар», — диде бугай.
Күрмәде ул юан тирәк артын,
Ят карашның үзенә юнәлгәнен,
үлем күзе төсле кара, салкын
тимер көпшә күзенә төбәлгәнен...
...Күтәрелде шаулап кош гаскәре,
тимгелләде күлне күз яшьләре.
Ишетелде аның, өметен җуеп,
хәлсез генә «Хуш!» дип эндәшкәне.
Нәни тәне шундый авыр инде, —
тирәкләр дә тотып калалмады...
Көтү булып эзләп йөрде кошлар,
эзләделәр, —
беркем табалмады.
Эзләделәр аны, исемен әйтеп...
Калмый йөрде күңелем шул кошлардан:
«Аусам читтә, мине дә тик берәрсе
эзләп килер иде микән соң дуслардан?

---

* Сыерчыкның җирле аталышы.

Эзләп килер идең микән син дә,
яшералмый аккан яшьләреңне,
ишетер идем микән «Ташлама!» дип,
күкрәк тавышы белән дәшкәнеңне?!
Нигә бу уй?! Без соң кошлармыни?
Кавышулар, шатлык яше — алда!
Яңгыр булып та,
җил булып та
кайта алам, гөлем, синең янга.

*Билгәскән, 1959*

## *Нәни Планетам*

Кырым астрофизика обсерваториясе астрономнары үзләре ачкан 2127 нче номерлы кечкенә планетага Ленинград блокадасы кызы Таня Савичева исемен бирделәр.

Сузылып ята Тормыш юлы
Ладоганың карларында.
Ак карларны туздыра җил
туңган Нева ярларында!

Ыжгыра җил! Еллар аша
бүгенгегә килә исеп...
Ленинград! Ачлык көлә
тешсез авызын ачып
ничек!..

Бер сыныкны җидегә
бүл —
зур батырлык менә кайда!
Көнен-төнен шакый,
шакый
ишекләргә Блокада!

Каерып керә йозакларны,
чатный туңып Нева бозы...
Куеныңда, Ленинград,
өшеп утыра нәни кызың!

Газиз ана сүнеп бара,
кирәк, җаным, бәхилләргә:
зур чиләген бара сөйрәп
Невадагы бәкеләргә.

Нәни куллар кызарганнар, —
ябыштыра чиләк бавы...
Табан бозга ябышса да,
алып кайта сөйрәп аны...

Көтә иде нәни кызын...
Ул кайтуга... үлгән ана...
Төнге күккә карый бала:
Җидегән яна,
Җидегән яна!

Стенада ачыла тора
Блокада Көндәлеге;
нәни куллар яза тырышып:
«Бүген... таңда... әнкәй...
үлде...»

Стенада Көндәлеге —
үткәннәрдән калган сәлам!
Кул калтырый, кара
туңган,
язарга да базмый каләм,
язмый каләм!

Чатнап ярыла Нева бозы!
Сүнде кабат якты йолдыз.
Яна Таня берьялгызы...
Йолдызлыкта яна берсе!

Калган бары Сәгать
тавышы...
Каләмне ул тагын ала:
«Савичевлар үлеп бетте».
«Берьялгызы... Таня кала».

Димәк, Пулково күгендә
Җидегәннең берсе яна...
Берсе яна!
Җидегән йолдыз балкып
яна...
(Очар үзе беркөн анда...)
Күккә карап тын калганнар
телескоплар Пулковода.

Нәни эзләр чуарлаган
Невадагы бозның өстен...
Һәйкәл булып сафка тезелә
Невадагы тугыз йөз көн!
Тугыз йөз көн!

...Ишекләрне ачып, үзе
зур дөньяга каршы чыга.
Төнге салкын күк
астында —
Таня Савичева!

Телескоплар күрде беркөн,
галәмнәрдән тапты аны —
Җидегән йолдыз янына күчкән
Нәни генә кыз — Таняны!

«Таня» дигән планетаны!

*1966*

## *«Иркә малай» монологы*

...Төш аралаш әнкәй дәшәр иде:
«Чәй өлгерде инде, тор, улым...»
Башларымнан сыйпап сөяр иде:
«Иркә улым бит син, бер улым!..»

Чыклы болыннарга көтү кудым,
Ак чәчәкләр ердым билемнән...
Бер ул идем, шуңа иркә булдым.
...Ил чакырды — торып билне будым,
Дәрман алып Анам-Илемнән!..

...Менә бүген...
          ятам япан кырда...
Берүземә — тимер тавы булып,
Танк киләә
          үкереп
                    өстемә!..
Батырайдым, әнкәй, шунда синең
Иркәләвең искә төште дә!..

Гранаталар кысып куеныма:
— Юк, фашист, — дим, — уңмас юлың! — дим.
Танк асларына кереп киттем,
Хуш, әнкәем,
Иркә улың... мин!

*24 июнь, 1987*



## *Сарбай турында легенда*

...Очтың камыллы кырлар аша,
Үзең дә камыл төсендә —
күренмисең дә!..

Кешеләр яратуыннан,
хуҗаңның киң күңеллелегеннән
канатланып,
гомереңнең кыл түбәсендә
гүя романтик дулкынга
килеп кердең. Күтәрелдең!

Син инде Сарбай гына түгел, гүя
кучтең кешеләр даирәсенә,
яңа яшәешкә,
илһамланып!

Танавың яңа чор җилләрен тотты;
кешеләргә рәхмәтең ташып чыкты
йөрәгеңнән!
Тойдың гүя чорның яңа ачышларын,
Сарбай!..

Очтың!

Ишегалдында тәлинкәңдә
ашалмыйча калды салган ашың
(буы чыгып тора әле дә!).

Хуҗаң, сәфәр чыккан чакта,
сине уятмаска тырышты.
Ул инде үргә менеп бара.
Олы юл өстендә эленеп тора тузан.

Ә син,
сикереп коймадан,
сары йомгактай,
очтың хуҗаң артыннан,

куып җиттең,
узып киттең —
гүләп торган
олы магистраль каршына!

Чакырдылар сине кирегә:
«Борыл болыныңа,
кайт яшел ишегалдыңа,
Сарбай!» — дип ялынды барысы да...

Томырылдың
ак болытлар артына!
Берүзеңә — шундый киңлек!
Хөрлек!
Оч! Тауга мен!
Уз җилләрен!

Югал чакрымнарда,
сары нокта булып
ерак офыкларда!

Бәйдә чакта тарлыкка да күндең,
ә хөр йөрәк типте,
читлегеннән чыгар булып!
Югалдың син кереп офыкларга...

Хуҗаң синең
исемеңне әйтеп җилләргә,
чакыра сине, кырларга чыгып,
тузанлы үрләргә карый:
камыллы кырлардан,
ак болытлар яныннан
тәгәрәп кайтмыймы
Сары Йомгак?!
Сине белешеп,
күргән-белгәннәрдән сорап,
көн дә кайта урап...

Сөйлиләр төрлечә,
бәгырьне тырнап:
имеш, син чапкансың машинага өреп,
имеш, син киткәнсең урманнарга кереп,
койрыгың гына күренеп калган
тимер күпер астында...

Илләр гизәргә китүеңме
олы дөньяда,
кешедәй, күпне белеп?..
Имеш, син ятасың
кайдадыр
гудрон юл читендә...
Ап-ак җаның
киткән... Айга менеп!

Моны беркем белдермәде,
сөйләмәде соңгы хәбәрләр,
сөйләмәде җилләр...
Иң кешелекле Сарбаем,
кайда син, җүләр?!

Кеше сүзен,
хуҗаң күңелен
күздән аңлый идең син, җаным!
Космик гасырда
кайбер бәндәләрдән
кешелеклерәк иде бит җаның...
Бер генә өр,
хәбәр бир!
Бер йөгереп кайт,
хуҗаңны юат!..

* * *

Икенче көн инде эфирдан
агыла моңлы көйләр,
гүя синең хакта сөйләп.

Сине искә алган кебек
кояшлы валторналар,
Әллә кемне юксыналар
Тәрбелидә
торналар!..

Икенче көн инде... кимәнәләр,
йөрәгемә сызып кинәнәләр...
Әйтерсең лә минем хәлне белеп,
эфир тутырып
елый... Моцарт, Глюк...

Авыр да шул безгә
сине югалту...
Кайтыр, төнлә кайтыр,
капка төбендә
тавыш бирер,
диеп юату...

Моңсу тагын да...
Вакыт-вакыт, кичке җилләрдә...
син өрәсең төсле
урман ягында!..
Сарбай!
Легендага киттең
җилдәй исеп кенә...

...Ишегалдына чыгып,
күккә карыйм,
тыңлыйм җилне:
кайдадыр
төн түреннән
синең
Айга өргәнең ишетелә!..

*1984*

## *Кайдадыр зур мәйданнар...*

Роберт Әхмәтҗанов шигырьләрен тагын бер кат укып чыктым. Тагын бер кат, дим, чөнки күптән күзәтеп килөм. Таныш, ләкин шагыйрь, бергә туплангач, әйбәтрәк күренә, элек артык игътибар итеп житкермәгән яклары әйбәтрәк күренә. Бергә туплангач... Минем малайларның пыяланы кояшка куеп, нурны бер җиргә җыйганнарын карап торганым бар. Шагыйрь дә шулай нурны бер тирәгә җыя, бер тирәгә туплый. Роберт Әхмәтҗановның 1972 елда басылган «Идел-йорт» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы миндә шундый тәэсир калдырды. Үзенә күрә кечерәк бер сайланма. Шагыйрьнең шигырьләре үзе турында күбрәк сөйли. Укыдым, үз вакытында сүземне әйтмичә узганым өчен үкендем. Шагыйрьнең чын мәгънәсендәге яхшы шигырьләрен ничектер күрмәмешкә салынып үткәнмен шикеллерәк тоелды.

Без барыбыз да — Галимҗан Ибраһимовның «табигать балалары». Якын тема безгә табигать. Шагыйрьләр күңелләренә бик якын ала табигатьне. Тимер юл читләреннән, күпер асларыннан шыпырт кына агып яткан «исемсез инешләр». Шагыйрьнең сизелер-сизелмәс кенә яңа туып килгән тонык хисләре кебек алар. Туалар, көчәяләр, кайдадыр кушылалар. Кайдадыр өзелеп тә калалар. Табигатьне мәңге яшәртеп торучы шул моңсу, гөнаһсыз инешләр. Заман фәндә могҗизалар тудырган чорда, икенче планеталарга һава кораблары очырган чорда күзгә каршы болын буйлап ашыга-ашыга кайтып килүче «Җәяүле күбәләк». Шагыйрь шуны күргән, күреп алган. Шуны күргәне өчен дә шагыйрь ул. Миндә шул кечкенә җан иясе әллә ничаклы хис уятты.

*Сибгат Хәким, Татарстанның халык шагыйре*

## *Соңгарган тәбрик*

Минем утырып житкән ныклы фикеремчә, әгәр Роберт Әхмәтҗан, бүтән берни дә язмыйча, бары «Солдатлар» исемле шигырен генә биргән булса да, исеме әдәбиятыбыз тарихына кереп калыр иде. Юк, хикмәт Фәтхерахман Әхмәдиевның йөрәк түреннән сызылып чыккан гаҗәеп моңлы көйгә җырлануында гына түгел. Әйе, ул шигырь, музыка

канатларында гына күтәрелеп, сабан тургае кебек күңелләрне җилкендерә, йөрәкләрне дулкынландыра торган шигырьләрдән түгел. Р.Әхмәтҗановның «Солдатлар» шигыре мөстәкыйль әһәмияткә ия, ул үзе музыка кебек ниндидер тылсымлы аһәңгә ия. Дөрес, «Ашказар» янсә «Тәфтиләү»ләрнең тылсымлы серен сүз белән аңлатып бирү мөмкин булмаган, Тукай һәм Такташ шигырьләренең тәэсир көчен беркемнең дә сүз белән бәян итә алмаганы кебек, Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар»» шигыре дә каты чикләвек булып кала. Шулай да мин шигырьнең бер серен тотып алдым бугай. Менә ул: шигырь унтугыз яшьлек лейтенантларны, унсигез яшьлек солдатларны шинельләренә төренеп мәңгелек йокыга талган балалар дип атый. Һәм шул «балалар» дигәнне төрле мәгънәләр салып кабатлап бара. Менә шушы зур шигъри табыш әсәрне тылсымлы итә. Харап инде, дияр, бәлки, укучы, нәрсәсе табыш? Алай дип кем әйтмәс? Кабатлыйм, табыш бу! Шул балаларны, шул аналарны үлеп ярата торган олы йөрәкле шагыйрьнең генә күңеленә, башына һәм каләм очына килә ала торган табыш әнә шул лейтенантлар, шул солдатлар аналарына соңгы минутларына кадәр бала булып калачаклар ич!

*Ибраһим Нуруллин, филология фәннәре докторы*
*«Шәһри Казан», 1995*

## Каләм очында – затлы сүз

Юк, нәсел-нәсәпсез дәрвиш сыман Җир шары буйлап мәңгелек хакыйкатьләр тәкрарлап йөргән, өйдән-илдән аерылган шәхес түгел иде ул. Роберт туган җир матурлыгын «күгәрчен очып туймас күннәрдә», «күбәләк күләгәседәй мизгелләрдә», «арыш серкәләнгән туфрак белән сөйләшүче тургай йортында», «Парижга тиңләшердәй Арыш авылында», «җанның җанга, канның канга тәңгәллеге белән билгеләнгән камиллектә» күрде. Һәр шигырь саен, һәр юл саен энҗеләр сибелгән иде. Моны танымаска, аларның затлы табигатен икърар итмәскә мөмкин түгел иде. Шул ук вакытта шагыйрьгә тематик чикләнгәнлектән качарга, иҗат офыкларын киңәйтергә дә кирәк иде. Ахыр чиктә ул хаклы булып чыкты. Яңа заман чынбарлыгында безнең зәңгәр планетабыз кечерәеп калды, илләр белән илләр арасында чикләр югалды, дөньякүләм мәшәкать-борчулар гомумбәла төсен алды.

Шундый вазгыятьтә «Таш елады» балладасының, «Сонгми» поэмасының тууы бик табигый иде. Автор ерак кыйтгаларның афәт-казаларын үз якташлары язмышы белән куша алды, аларда уртаклык таба белде. Шул ук әсәрләргә «Таш аргамак», «Уйна, улым», «Йолдызстан», «Фидан», «Сәхипҗамал» килеп ялганды. Сүз уңаенда Ро-

берт Әхмәтҗанның татар шигъриятендә поэма һәм баллада кебек жанрлар мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендә зур өлеш керткәнен дә ассызыклап әйтергә кирәктер. Алар һәммәсе шагыйрьнең йөрәк каны белән сугарылган, шуңа күрә бүгенге таләпчән укучының күңел кылларына ныклап чиертә ала иде. Ул үз иҗатына таләпчәнлекне бервакытта да киметмәде, иҗат планкасын түбән төшермәде. Ни турында гына язса да, музасына тиешле яңгыраш таба алды.

*Әхмәт Рәшит, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,*
*Г.Исхакый бүләге лауреаты*
*«Ватаным Татарстан», 20 апрель, 2001*

## *Шигъри күкнең җиденче катында*

«Ятам ярда тыныч дәүләт сыман». Бу шагыйрь Роберт Әхмәтҗан. Идел-Чулман яры. «Ятам ярда». Ул шагыйрьнең үзе дә, шагыйрьнең халкы да, дәүләте дә...

Шагыйрь әнә шулай шигырьнең беренче юлыннан, беренче сулышыннан ук яшәүнең гомум бер асылын ачып ташлый. Бу нәрсәне аңа табигать биргән. Кырык ел әүвәл чыккан шигырьләрендә, «Таш елады», «Фидаи» балладаларында ук алган юлыннан ул уңга да, сулга да борылмаган — ярып барган. Безгә зәһәр җилләр дә бәрмәде түгел, исте. Кагу-сугу да булмады түгел, күп булды. Аның бәргәләнгән, чайкалган чаклары да булгандыр. Әмма ул — Роберт Әхмәтҗан сынмады, сыгылмады.

*Мөдәррис Әгъләм*

## *Шагыйрьләрегездән качмагыз*

Роберт Әхмәтҗанның шигырь стиле хакында «күбәләкле» дип тә әйтәсем килә. Һәм юкка түгел. Эчендә күбәләк тырпылдаган сыман тоелган тере җөмләләргә юлыкканың бармы? Булса, чын шигырьгә юлыккансың, димәк! Ә чын шигырьгә юлыгу — сүз һәм хис кадерен белгән кеше өчен асыл бәхет ул. Яшерен-батырын түгел, инде ничә буын шагыйрьләре Роберт Әхмәтҗанның сүз куәтен, сүз сөрешен тоеп, аңардан өйрәнеп, шигърият күгенә күтәрелде. Ул дөньяга бүләк иткән китапларның исемнәрен генә тезеп атасаң да, үзе бер гаҗәеп шигырь барлыкка килер иде. Менә шул исемнәрнең берсе: «Тургай тәрәзәсе». Шагыйрьләр, кайсыбыз үз китабына шундый исем куярга кызыкмас икән? Мин — авыл малае. Әмма килеп тәрәзә шакыган тургайны күргәнем юк. Юк андый тургай!.. Әмма ул Роберт

Әхмәтҗан шигырендә бар. Һәм... бары тик шунда гына! Чын шигъриятебезнең илаһияткә хас сыйфаты бар икән шул. Миргазиян ага Юнысның Роберт Әхмәтҗан шигырендәге кошлар хакында сүз куертуы юкка гына түгел. Ул үзе бер гаҗәеп кошлы дөньяны бар иткән!

*Зөлфәт*
*«Татарстан яшьләре», март, 2001*

## *Шагыйрьнең гомер олаулары*

Ни кызганыч, бүгенге «китап укымыйча да кеше булып була» дип йөргән яшьләребез Роберт Әхмәтҗанны шагыйрь һәм шәхес буларак бөтенләй диярлек белми кебек. Белергә кирәк иде. Чаллыда шигырь язып азапланучы бер мөтәшагыйрьдән сорагач, ул: «Роберт Әхмәтҗан... безнең гасыр кешесеме соң ул?» — дип сорау белән җавап бирде. Әйе, тугани Роберт Әхмәтҗан Болгар заманнарыннан килгән безнең гасыр кешесе. Шуңа күрә дә аның исеме — Роберт. Ул хәтта исән. Ул хәтта безнең замандашыбыз. 1960–1998 елларда аны бары тик бер фәрештә — шигърият кенә саклады һәм исән калдырды. Белмим, әгәр ул шигъри аргамакны җитәкләмәгән булса, исән калган булыр иде микән? 50 нче еллар азагы, 60 нчы еллар башында татар шигъриятенә үзенең искиткеч чиста, беренчел сафлыктагы, кабатланмас метафора-чагыштырулары, ниндидер сюрреаль образлары, реаль чынбарлыктан читтәрәк торган кебек тоелган сабыя шигырьләре, «Таш аргамак» поэмасы белән дулап килеп кергән Роберт Әхмәтҗанны елдаш-замандашлары, 30 нчы елгылар, читкә тибәрде. Аны ничәмә-ничә тапкыр ул чакта чәчкә аткан төркемчелеккә тартып карадылар. Ул бер төркемгә дә кушылмады, озак еллар китапларын чыгара алмаса да, кумирлар тудыру һәм аларны мактап, премияләр алуга юл тотмады. Әдәби түрәлек аның иң куркыныч дошманнарының берсе булды. Бу шагыйрьлек белән сугарылган шәхсән позиция-яшәеш чыганагы иде. Без, 40 нчы елгылар, барыбыз да диярлек, Роберт Әхмәтҗан шаукымында идек. Без аны хәтта табыну объекты — шагыйранә балбал, кумир ясарга да әзер идек. Әмма ул аңардан да баш тартты, хәтта мондый шаукымлы «түрәлек» — богемачылыктан да тартынды, көрәсең. Тумыштан бик тә тыйнак, ашыкмаган Роберт барыбер беркемгә дә охшамый торган үз богемасында калды. Мондый иҗади батырлык премияләр белән түгел, намуслы гомер, әрнүле язмыш белән аклана шул.

*Айдар Хәлим*
*«Мәдәни җомга», 3 июль, 1998*

## *Шагыйрь язларны ник саный?*

Язмышның нинди кинаясе булганмыдыр, мин әле әлифбаны яңа өйрәнеп, икенче класска гына күчкән елны (1958 ел) әткәем Уфага эш белән баргач, гаиләдәге алты кешегә алты кызыл алма, ә миңа (миңа алма җитмәдеме икән инде) Роберт Әхмәтҗановның «Егерменче яз» исемле шигырь китабын алып кайткан иде. Һәм мин, китап кулыма эләгүгә, татлы сутлары сыгылып торган хуш исле кызыл алма турында бөтенләй оныттым.

Бүген, әлбәттә, көлке тоелыр, әмма ул чакта мине иң гаҗәпләндергәне китапның исеме булды: бу кеше ни өчен язларны санап бара икән дә егерменче язда нәрсә булган?

Булган. Шагыйрь мине, нәкъ икенче класска кергәндә, мәхәббәт учагына ташлады. Мин ул китапны гел ераграк яшерә, аннан качып котылырга тырыша торган бер Мәҗнүн, юк, бер Ләйләгә әверелдем. Һәм... бераздан инде курку аша булса да, хакыйкатькә төшендем: мәхәббәттән качып котылып булмый.

Шушы китап, шушы вакыйга мине Такташлар, Тукайлар, Җәлилләр, Фатих Кәримнәр, Пушкин, Есенин, Һейнелар, Лоркалар дөньясына алып керде.

Мин Роберт Әхмәтҗановның башка китабы булырга мөмкин, шигырь аннан да тәэсирлерәк була дип уйлый да алмый идем. Чөнки гомер язларының санаулы гына икәнлеген, сигез генә яшьлек кешегә мәхәббәттән качып булмаганлыгын төшендергән илаһи китап булды ул миңа тугызынчы язымда. Ул миңа: «Гражданнар, яз килә!» — дип, күзләрем саргаеп сулганда да, кышларым башыма чал төшкәндә дә һаман оран салып торды һәм тора.

*Нәҗибә Сафина*
*«Шәһри Казан», апрель, 1995*

## *Төннәрне көннәр җиңә*

Узган гасырның 60 нчы елларын бездә генә түгел, бөтен ил шигърияте мондарчы күрелмәгән «шартлау»га тиңләү фарыздыр. «Халыклар атасы» Иосиф Виссарионовичка бөек гыйбадәткә охшаш көнтөн мәдхия җырлаган шагыйрьләргә алмашка яңа бер буын калкып чыкты. Урыс әдәбиятында әлеге буынны Е.Евтушенко, А.Вознесенский исемнәре белән бәйләсәк, тугандаш казакъ әдәбиятында шундый байракчыны Олҗас Сөләйманов шәхесендә күрсәк, ә безнең татар шигърияте ндә өр-яңа сулышка капка ачучы Роберт Әхмәтҗанов булды дисәк, һич тә ялгышмабыз.

Шашкын йөрәкле шагыйрь иҗаты колач җитмәслек киң һәм мул. Ул һәрвакыт заман белән янәшә атлап бара, үз чорын узып атлый дисәк тә дөреслеккә хилафлык килмәс. Мәңгелек темалар — мәхәббәт, яшәеш, кеше гомере, иминлек, тынычлык һәм көрәш аның йөрәге аша уза, баллада һәм поэмалар булып языла. Әйтик, «Кар кеше», «Уйна, улым!» һәм «Таш аргамак» кебек поэмалары әнә шундыйлардан.

*Госман Садә*
*«Мәгърифәт», 14 апрель, 2001*

## Җәяүле күбәләк

Роберт Әхмәтҗанов турында күп яздылар. Мактап яздылар, әмма... бу мактаулар аның холкына мактанчыклык, хөсетлек, көнләү, шигърияттә башкаларга урын калдырмас өчен җан ату сыйфатлары алып килмәде.

Роберт абый шигырьләрен укыганда, вакыйгалар алмашынып тора. Төштәге кебек, әллә кайдан чит эпизодлар да килеп кергәли һәм магистраль фикердә барыбер бер җепкә бәйләнә.

Минем күз алдыма килгән тасвирлар фонында һәрчак бер образ бар. Үзе тудырган хәрәкәттәге җисемнәрдән дә алгысыныбрак шагыйрь атлый. Җилкенеп-җилкенеп. Бер аягы, кыбырсынып, тагы да сикеренебрәк ала. Куллары, аяклары буташып та китә кебек. Кызгылт чәче шигырендәге җәяүле күбәләккә аны тагын да якынайта. Җәйге түгел!.. Көзге сукмакларга яткан сары яфракны урыныннан кузгатып очар күбәләк ул. Мин сине шул шигырең өчен генә дә таныр идем, Шагыйрь!!!

*Рифә Рахман*
*«Мәгърифәт», 13 май, 1995*

## Чын шагыйрь, күңел шагыйре...

Көчле шагыйрь! Аның шигырьләре хискә бай, аларда фәлсәфи тирәнлек, олы мәгънәләр ята, чөнки шигърияте күңеленнән актарылып, йөрәгеннән ташып чыга. Шигърият — аның җанында! Әнә шуннан ургыла да инде шигырьләре. «Йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә» дип юкка гына әйтми бит халык. Робертның һәр шигыре, һәр шигъри юлы кеше күңеленә үтеп керә, беркемне дә битараф калдырмый, уйландырауйлата, шатландыра йә борчуга сала. Алар хисле, анда фикерсез, кыйбласыз, егәрсез, буш шигырьләр тапмассың — һәр шигыре тыгыз һәм фикерле. Тирән фикерле, тирән мәгънәле!

*Әхәт Сафиуллин, язучы*
*«Ватаным Татарстан»*

### *Шигъри Әнкәнең сөекле улы*

Иҗатта бөек Шигырьгә тугры шагыйрь фани дөньядагы әрсез тормышыбызда үтә тыйнак холыклы. Юкса, юкса аз гына әрсезрәк булса, ул да талантлы иҗатын калкан итеп куеп, тормышта үзенә күптәннән, ким дигәндә, ышык урын яулый алыр иде. Югыйсә аннан күпкә калыш әрсез каләмдәшләре дә әллә кайчан, әллә нинди катлы-катлы эшлекләләр булып беттеләр бит инде. Ә ул болыннарда очкан күбәләкләр өчен борчылып яшәде:

И җәй җаны, күбәләгем,
кайларга юл тотасың?
Тора җилдә ефәк шавы,
күлмәгеннең укасы.
Җемелди, и лә, куркам соң
килсә дә бик тотасым!..
Коелыр укаң,
шуңа куркам,
Инде бит җәй уртасы...
Очар юлың уртасы!

Роберт Әхмәтҗанов җан елап ялварган күбәләкнең үз замандашлары булуын кайсысы аңлады икән соң? Шагыйрь аларның күңел матурлыгын саклауларын үтенгән икән ич. Күн белән тышланган ишекләрен каерып ачып, өстәлләренә сугып кисәтергә кыюлыгы булмагач, күбәләк төсле, шигырьдә бәргәләнгән. Югыйсә иҗатында Шигъри Әнкәне дөнья бәһасенә тиң итеп зурлаган шагыйрьнең үз хакын хакларга да хокукы бар иде. Ә ул?

Шагыйрь инде менә 40 елдан артык шигырьдә. Бүген инде ул әлеге илаһи иҗат дөньясында ябалак дип, сары яфрак куган сабый түгел. Һәр сүзнең егәрен Тукайча, Дәрдмәндчә, Җир-Ананың тарту көчен Ньютонча тәгәл белгән олпат шагыйрь. Сүзе кирәк чакта усал да, кыю да, җаны бишектәге сабый да, җәяүле күбәләк тә.

*Ирек Нигъмәти*

### *Җәяүле күбәләк*

Җәяүле күбәләк!..

Роберт Әхмәтҗановның күңел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, эстетик карашларын, ахыр чиктә поэтик идеалларын шушы метафорик образдан да төгәлрәк әйтеп бирергә мөмкинме соң? Дөрес, аны күпләр җилбәзәклектә гаепләргә ашыктылар, әмма бу тыштан караганда гына «дөрес» бәяләмә. Асылда исә ул бөтен җа-

ны, омтылыш-ышанычлары, бөтен вөҗүде белән шагыйрь; әрфия күбәләктәй самими, сабый җанны нишләтәсең инде аны... Ләкин онытмыйк: көндәлек ваклык-интригалар бәрелешендә баштан ук җицелергә дучар ителгән шушы күбәләк җанга — Җәяүле күбәләккә — Табигать үзе үк тулаем сыя ала, чөнки аның җаны шигырьдән тора. Ул — үзе бер шигъри дәүләт!

Шикләнми әйтергә мөмкин: Роберт Әхмәтҗановның шигырьләре күпләр өчен юлдаш булды. Чөнки ул гомере буе Матурлык турында җырлап килде. Ә Матурлык кешелекнең аерылмас юлдашы инде ул. Йә, уйлап карасаң, исәннәрдән күпме татар шагыйре үзенең иҗатында Туган як турында («Каенстан! Урман башыннан ук күренәсең — йөрәгемә матур утырган! Әнә синең яңгыр басмаларың, урамнарың — минем Нотр-Дам»), «дөрләп янган усаклар», «күгәрчен очып туймас көн», «орчык җыры», киңлек буйлап очучы пәрәвезләр («шундый көз бу, шундый киңлек бүген, — пәрәвезләр оча Әдрәнгә») хакында, гомумән, безне чолгап алган тирәлек, Туган җир, Табигать хакында Роберт Әхмәтҗанов кебек үзенчәлекле итеп, дәртләнеп, очынып, талпынып, ихлас күңелдән, күтәренке рух белән җырлый алды икән?

Андыйлар бармак белән генә санарлык.

*Наис Гамбәр*

## Чык тамчысына сыйган дөнья...

Роберт Әхмәтҗанны шәхсән үзем бер сүз белән эзләнүче-кәшфиятче шагыйрь дип атар идем. Хәер, иҗат үзе үк тынгысызлык, гомер буе иң әһәмиятле, иң мөһим, иң кирәк сүзеңне эзләү түгелмени соң! Ул сүзнең кыйммәте дә иҗади эзләнүләр, тудыру газаплары, хис-фикер, образлылык, яңалык, һичкемгә охшамыйча үзеңчә әйтә белү белән бәйләнә ич. Шагыйрь үзе дә «эзләнүләр — иҗатның гомерлек юлдашы» ди бит.

*Рафаэль Сибат*



## Эчтәлек

**Шигъри дөньям**

Мөхтәрәм укучым! . . . 5
«Бу китапның ачтым күпме битен!..» . . . 8

**Яшьлек поезды**

Балачактан килгән шигырь . . . 10
«Таң кабынды...» . . . 10
«Иртә әле...» . . . 11
Яңгырдан соң . . . 12
«Йөгереп килдең миңа...» . . . 12
Күршем нигезе . . . 13
«Бормаланган урман юлын үткәч...» . . . 14
Кар яктысы . . . 15
Язга таба . . . 16
Яшьлек поезды . . . 17
Бер хатирә . . . 18
Бер хаттан . . . 19
Бодай кыры . . . 20
Соңгы карлар . . . 21
Төнбоеклар, тынлык чәчәкләре . . . 22
Кояшка, кояшка! . . . 23
Юат әле . . . 24
Яз — мәңгелек! . . . 25
Бер очрашу . . . 26
«Бодайларны сөткә туендырып...» . . . 27
«Зәңгәр киңлек...» . . . 28
«Идел ага, ишетелми...» . . . 28
Ак юлларым . . . 29
Бүгенге көн . . . 30
Улларың кайта . . . 31
Син килгән юллар . . . 32
«Тетрәп сүнде учак...» . . . 33
Судагы бөжралар . . . 33
Көлә кызлар! . . . 34
Инеш . . . 35
Жир китабы . . . 36
Ерактагы дуска . . . 38
«Тупыллар килә Иделгә...» . . . 39
Кызыл чаган . . . 40
Романс . . . 41
Яңа елга кергәндә . . . 43
Кышкы җил . . . 44
Күңел кыры . . . 45
Диңгез буенда кыз җырлый . . . 46

Вундеркинд . . . 47
Очышка! . . . 48
Июнь иле . . . 49
Камыллар . . . 53
«Күренмәгән бер кешем...» . . . 54
«Яшел тауга яттым...» . . . 55
Зарыктырган яңгыр . . . 56
Җайдагатлар . . . 57
Таулар җилли . . . 58
Юл кендәлегеннән . . . 58
Сылу сурәте . . . 59
«Ничә чакрым куанычны...» . . . 59
Сигулда усаклары . . . 60
Ерак бер кезне сагыну . . . 61
Юрмала җиле . . . 62
«Мәхәббәт һәм гүзәл җир...» . . . 63
Тормыш арбасы . . . 64
Хаттан езек . . . 65
Чалгычылар . . . 66
«Болында — богыллар...» . . . 67
«Күңелемдә тынлык...» . . . 68
Рәхмәтле кен . . . 69
Кунак кыз . . . 69
Уяну . . . 72
«Син — Мәхәббәт республикам...» . . . 73
Авылда бер кен . . . 73
Күңелсез шигырь . . . 75
Сандугач пластинкада . . . 76
«Кырларда — җил!..» . . . 78
Җырың кайтты . . . 79
«Оныт!» димә . . . 80
Сандугачны күрдем якыннан . . . 81
Сандугач . . . 82
Бакый ага Сөембикәсе . . . 82
Ана арыслан . . . 84
Кезге якты деньяурт урт асында . . . 85
Соңгы яфрак . . . 86
Беренче кар . . . 88
Уяну . . . 89
Шагыйрь . . . 90
Иске кейгә . . . 91
«Үкен, үкен...» . . . 92
Күләгәләр . . . 93
Сабырлык хакында . . . 94
Шигъриятне чакыру . . . 95

**Тынлык ни сөйли?**

Азиядән тавыш килә . . . 98
Җыр чыкты җирне урарга . . . 99

Ут сәнгате . . . 100
Җидегән йолдыз . . . 102
Тынлык ни сөйли? . . . 104
Тыныч кояш елы . . . 106
Елъязмадан бер көн . . . 108
Ватык гильотина . . . 110
Сабый елы . . . 113
Җәллад . . . 114
Өлкән таллар урамы . . . 116
Йокысыз төн . . . 118
Татарстан туфрагы . . . 120
Сугышка экскурсия . . . 121
Фаҗиганең асылы . . . 125
Бурыч . . . 128
«Тирә-ягым ап-ак юрган...» . . . 128
«Иртүк торып...» . . . 129
Сурәт . . . 130
«Син бар ул, Айтуган...» . . . 131
Сары көчек . . . 132
Дәрдмәнд көенә . . . 133
«Үтә еллар...» . . . 134
Киткәннәргә гимн . . . 135
Ватан сугышында булганнар . . . 136
Җиңү көне . . . 138

**Тәрҗемә үрнәкләре**

*Пабло Неруда*. Чилига кайту . . . 140
*Витезслав Незвал*. Пәке йөзенә . . . 144
*Константин Ильдефонс Галчинский*. Кечке сөйләшү . . . 144
*Эдуардас Межелайтис*. Налоглар җыючы . . . 145
*Марис Чаклайс*. Кант кабере . . . 146
*Максим Танк*. «Җиргә яфрак коелганда...» . . . 148

**Поэмалар**

Зәңгәр көянтә . . . 150
Таң шәһәре . . . 153
Йолдызстан . . . 161
Уйна, улым! . . . 171
Таш аргамак . . . 179
Сонгми . . . 187
Урман җиле . . . 193
Хиросима шагыйрьләренә . . . 197
Табигатькә дүрт җыр . . . 200
Соңгы гыйнвар . . . 205
Болгар фрагментлары . . . 218
Бусага . . . 227
Сәхипҗамал . . . 232
Атлантида . . . 248

**Балладалар**

Таш елады . . . . . 256
Соңгы танк . . . . . 261
Ак чәчәкләр . . . . . 265
Дала хикәясе . . . . . 266
Янгын сүндерүче турында . . . . . 269
Гармун турында баллада . . . . . 275
Яралы арыслан . . . . . 281
Атылган кош . . . . . 284
Нәни Планетам . . . . . 285
«Иркә малай» монологы . . . . . 288
Сарбай турында легенда . . . . . 289

*Роберт Әхмәтҗан иҗаты турында каләмдәшләре* . . . . . 293

Литературно-художественное издание

*Роберт Ахметзян*
*(Ахметзянов Роберт Валеевич)*

**КАМЕННЫЙ СКАКУН**

Стихи, поэмы, баллады

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Н.Н.Фәхретдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.И.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.03.2005. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 13,30+ф.0,18. Шартлы буяу-оттиск 14,35.
Нәшер-хисап табагы 12,11+ф.0,29. Тиражы 2000 экз. Заказ А-128

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

ААЖ «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.